# Казан утлары



1

ЯНВАРЬ
1967

# КАЗАН утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

КЫРЫК АЛТЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

Республиканская библиотека
Тат. АССР
имени В. И. ЛЕНИНА

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ

ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН • ЯНВАРЬ • 1967

1

# Бу санда:


Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

М. Хәсәнов. Революция байрагы астында . . . . . 3

М. ӘМИРГӘ 60 ЯШЬ

А. Расих. Әйтәсе сүзләр күп әле . . . . . . . . . . 16
М. Әмир. Мәхәббәт хаты. Яңа әсәрдән өзек. . . . . . 18

ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ

И. Юзеев. Тынлык белән сөйләшү. Поэма . . . . . . . 30
Ә. Баянов. Яшьлегемне эзлим. Повесть . . . . . . . 46

ТАТАР ТЕАТРЫНА 60 ЕЛ

Бәйрәм белән . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
И. Илялова. Үрнәк булырлык иҗат . . . . . . . . . 80
Х. Гобәйдуллин. Эшчеләр бистәсендә спектакль. . . . 84

ХӨСӘЕН ЯМАШЕВНЫҢ ТУУЫНА 85 ЕЛ

Көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез кеби. . . . . 85

ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

Э. Мөэминова. Аңпармы ул; Туган җиргә мәхәббәтем...; Шелтә сүзе ишеткәлим; Сәер мәхәббәт; Кыз язны ашыктыра. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
К. Мостафин. Йолдыз; Тынычсызлык; Шулай була икән...; Дезертир. Һәр кешенең үз йолдызы була, диләр. Шигырьләр 88
К. Булатова. Яратаммы сине! Ялгыз каен; Вакыт үтә...; Яшьлек эзем калган... Шигырьләр . . . . . . . . 90

ВЬЕТНАМ ХИКӘЯЛӘРЕ

Фан Ты. Ике бертуган. . . . . . . . . . . . . . . 92
Мин Тхюи. Вакытлы килешү көнендә атышлар. . . . . 95

ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ЛАБОРАТОРИЯСЕННӘН

Ф. Хөсни. Урыннарындамы сүзләр-солдатлар! . . . . . 98

Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Художник Т. Хаҗиәхмәтовның «Безнең көннәр» романына ясаган иллюстрацияләре . . . . . . . . . . . . . . 102

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Дагстан — шигърият җире . . . . . . . . . . . . . 105

БИШЬЕЛЛЫК ВАХТАСЫНДА

М. Хәсәнов. Таныш булыгыз, Сәет Сәлимгәрәев . . 109

УКУЧЫЛАР СОРАВЫ БУЕНЧА

З. Мәҗитов. Хәерләре белән үссеннәр . . . . . . . 117

СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Ю. Римаренко. Дуслыкның матур үрнәге . . . . . . 122

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ БАТЫР УЛЛАРЫ

Л. Кизя. Партизан Морат. . . . . . . . . . . . . 126
С. Алишев. Пугачев полковнигы . . . . . . . . . . 131

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

Ю. Бейлькин. Җырым булсын бүләгем . . . . . . . 140

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Н. Исәнбәт. Бу шигырьнең шагыйрәсе кем! . . . . . 147

КИТАП КҮЗӘТҮ

С. Фәйзуллин. Халыклар дуслыгы турында сөйләүче китап 149
Р. Харисов. «Аңаган» . . . . . . . . . . . . . . 151
Х. Хисмәтуллин. Г. Тукай альбомы . . . . . . . . 153
Укучылар сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . . . 156

# Г. Ибраһимовның туууына 80 ел

*Мансур Хәсәнов*

# РЕВОЛЮЦИЯ БАЙРАГЫ АСТЫНДА

„Мин пролетариат революциясенең солдатымын. Бөтен үткән тормышым менә моңа хәзерләде. Үземнә үстергән, тарихы, теле туган булган татар халкының гына түгел, дөньядагы барлык изелгән миллатләрнең, сыйныфларның иҗтимагый азатлыклары пролетариат байрагы астында, ленинизм нигезләренчә көрәшкәндә генә мөмкин дип эшләүчеләрдәнмен. Мин эшче-крестьян халкына киракле әйберләр биргән булсам, моның сәбәпләре минем шәхси талантымнан гына түгел, бәлки революцияче массага бәйләнгән булуымда, бигрәк тә тарихның бердәнбер иҗади юлбашчысы, принципларыннан булган марксизм методларының биргән куәтләрендә, күрсәткән юлларында», дип язды Г. Ибраһимов 1928 елда «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясенә Ялтадан җибәргән телеграммасында.

Бу юлларда әдип тормышының мәгънәсе, аның халык арасында популярлыгының сере, язучы буларак үзенчәлеге Г. Ибраһимовның үзе тарафыннан бик ачык һәм тегәл итеп әйтеп бирелгән.

Г. Ибраһимов үзендә художниклык талантын халык бәхете өчен көрәшче, революционерлык сыйфаты белән бергә кушкан бөек шәхесләрнең берсе иде. Аны шулай итеп татар халкының XX гасыр башы иҗтимагый хәрәкәтләре тудырды, бөек Октябрь үстерде, коммунистлар партиясе чыныктырды. Әмма ул пролетариат революциясенә, марксизм-ленинизмга килгәнче зур һәм катлаулы көрәш юлы үтте, политик үсеш кичерде. Г. Ибраһимовның революция чорындагы идея-политик эволюциясен тикшерү тарих һәм әдәбият фәне алдында торган актуаль бурычларның берсе. Чөнки аның революционерлыгы, политик эволюциясенең юнәлеше әдипнең язучылык табигатенә, Октябрьдан соңгы тормышына һәм иҗатына зур йогынты ясадылар, киләчәктә аның татар әдәбиятында социалистик реализмны нигезләү өлкәсендәге зур эшчәнлегенә ныклы нигез булдылар.

## I

Г. Ибраһимов әле 1917 елга кадәр үк революцион-демократик юнәлештәге җәмәгать эшлеклесе, патша самодержавиесенә каршы актив көрәшче буларак танылган иде. 1913 елда Киевта студентларның яшерен оешмасында катнашуы өчен ул патша властьлары тарафыннан кулга алынды һәм төрмәгә ябылды. Ә аннан чыккач, 1917 елның февраль революциясенә кадәр полициянең ачык һәм яшерен күзәтүе астында яшәде.

Февраль революциясеннән соң Г. Ибраһимов бөтенләе белән революцион көрәш дәрьясына чума. Ул хәзер «Галия» мәдрәсәсен революцион җыелыш трибуналары, демонстрацияләр, сыйнфый көрәшнең кайнап торган урыннары белән алыштыра. Ул бөтенесен — каләм көчен дә, ораторлык осталыгын да, сөештыру талантын да — революция эшенә багышлый.

Ләкин революцияне күптән көтеп, аңа актив әзерләнгән, аның килүен бөтен йөрәге белән тоеп яшәгән булса да, Г. Ибраһимов бу вакыйганың асылын, февраль революциясе нәтиҗәсендә илдә барлыкка килгән политик хәлне башта бөтен тирәнлеге белән аңлый алмады. Революциянең төп мәсьәләләренә һәм перспективасына аның анык марксистик карашы булмый.

«Мин революцион марксизм-ленинизмга вак буржуаз сәзлыгы, сул народничество аша килдем,— дип язды ул соңыннан үзенең автобиографиясендә.— Революциянең беренче елларында мин сул социалист революционер-интернационалистлар партиясе члены булып тордым»[1].

Ләкин шуның белән бергә, Г. Ибраһимов политик вакыйгаларны көннән-көн тирәнрәк тоя, халык һәм революция табышын ныграк ишетә барды. Аның политик карашлары халык массаларының революцион активлыгы һәм аңы үсүе белән бергә үсте һәм тирәнәйде. Монда иң зур этәргеч көч революция үзе булды. Революциянең гаҗәеп зур тәрбияви роле турында әдип әле ул вакытта ук болай дип язган иде:

«...Революция кебек, гакыл вә фикерләрне кинәт күтәреп, ачып җибәрә торган гадәттән тыш бер дулкын булмаса, тик сөйләү, язу, әдәбият вә тәрбия юлы белән генә максатка ирешергә калса, революциянең икә айда биргән тәрәккыйсен йөз елда да ирешеп булмас иде. Революцияләрнең иске кабахәт тормышны җимерүдә генә түгел, халыкның рухын, фикерен күтәрүдә дә менә шундый зур гаҗәеп мәгънәләре бар»[2].

Февраль революциясеннән соң күп тә үтми, Г. Ибраһимов язучы Ф. Сәйфи белән берлектә «Ирек» исемле газета чыгара башлый[3].

Бу газета февраль революциясеннән соңгы беренче татар революцион матбугат органы иде. Ул беренче санынннан башлап ук революция идеясен пропагандалый, татар һәм башкорт халкын сыйнфый көрәш рухында тәрбияли, контрреволюцион татар буржуазиясенә каршы көрәш алып бара.

Г. Ибраһимов үзенең мәкаләләрендә кайбер мәсьәләләр буенча инде ул вакытта ук большевиклар карашын пропагандалый, революциянең беренче этабыннан икенчесенә күчү эшенә объектив рәвештә ярдәм итә. Ул вакытлы хөкүмәтнең халыкка каршы политикасын фаш итә, эшче-крестьян массасын аңа ышанмаучылык рухында тәрбияли.

«Ирек» кыю рәвештә «Бетсен сугыш!» лозунгысын күтәреп чыкты, сугышның империалистик характерын әйтеп, аның капитал хакына алып барылуын һәм хезмәт ияләре җилкәсенә авыр йөк булып төшүен аңлатты. Газета битләрендә аграр мәсьәләгә зур игътибар бирелә. Бу өлкәдә киң катлау крестьяннарның интересларын һәм теләкләрен чагылдырып, «Ирек» социалистик революциягә әзерлек эшенә ярдәм итә. «Ирек» асылда революцион демократия идеологиясен чагылдырып, бу газетаның күп кенә йомшак яклары һәм хаталары булуга да карамастан, хезмәт массаларын революцион рухта тәрбияләүдә, татар һәм башкорт халыклары аңына сыйнфый көрәш рухын кертүдә аның роле зур булды. Ул контрреволюцион милли буржуазиягә, аның шовинистлык омтылышларына каршы нәтиҗәле көрәш алып барды.

Февраль революциясе эшче-крестьян массасына, революцион көчләргә генә түгел, милли буржуазиягә дә киң юл ачты. Татар буржуазиясе, моннан файдаланып, үзенең политик активлыгын шактый көчәйтте. Ул үзенең ихтыярын татар хезмәт ияләренә генә түгел, Россиянең башка төрки халыкларына да көчләп тагарга омтылды. Нәкъ әнә шундый максат белән ашыгыч рәвештә «Бөтенроссия», «мөселман», «төрек-татар» шикелле төрле яңгыравык исемнәр астында милләтчел оешмалар төзи башлады.

Г. Ибраһимовның бу чордагы зур бер хезмәте милли буржуазиягә каршы көрәше булды. Ул үзенең мәкаләләрендә төп ударны татар буржуазиясенең «милли берлек» политикасына каршы юнәлдерә, аның хезмәт ияләре игътибарын сыйнфый көрәштән

---

[1] КПСС Татарстан өлкә комитеты каршындагы партия архивы. 1378 фонд, 1987 опись, 110 бәйләм, 378 эш, 122 бит.

[2] «Ирек» газетасы, 1917, 28 май.

[3] Газетаның беренче саны 1917 елның 30 мартында чыга. Анда шулай ук халык шагыйре М. Гафури да актив катнаша. Г. Ибраһимов югында ул хәтта редакторлык вазифасын да үти. (Карагыз: «Ирек»нең 1917 ел, 7 август h. б. саннарын).

читкә алып киту максаты белән уйлап чыгарылган булуын әйтә, революция үсеше өчен зарарын күрсәтә. «Халыкны саташтырмагыз» исемле мәкаләдә ул, «милли берлек» политикасы авторларын фаш итеп, болай дип яза:

«...Халыкны юк белән саташтырмагыз. Никадәр генә пәрдә астына качсагыз да, бер вакыт мөселман демократиясе сезнең, «мөселманнар, аерылмыйк!» диган матур сүз астына качып, байлар күңелен табарга тырышканлыгыгызны, шуның өчен социализм байрагы янына якын барырга теләмәгәнлегегезне аңлаячак, тарих бу эшегезне дин вә миллат исеме астына яшеренеп, буржуазия файдасын күзәтү дип атаячак»[1].

Г. Ибраһимовның милли буржуазиягә, буржуаз матбугатка каршы көрәшенең үз вакыты өчен зур тарихи әһәмияте булуын әйтү белән бергә, татар халкы арасында сыйнфый дифференциация, сыйнфый көрәш идеясен пропагандалауда аның ахыргача эзлекле булмавын да күрсәтергә кирәк. Татар буржуазиясенә кискен каршы чыккан, газета битләрендә сыйнфый көрәш идеяләрен даими рәвештә пропагандалап килгән халдә, Г. Ибраһимов февраль белән Октябрь арасындагы чорда кайбер хаталар да җибәрде. Ул, мәсәлән, эшче белән буржуазиянең милли һәм культура мәсьәләләрендә бергә берләшү мөмкинлеген инкарь итмәде. Әдип әле ул вакытта «милли-мәдәни мохтарият» лозунгысының контрреволюцион асылын аңлап җитми, аның артында нинди политик көчләр яшеренгән булуына төшенми иде. Шуңа күрә ул Казандагы берләшкән мөселман съездларының милли-мәдәни мохтарият төзү турындагы карарына уңай мөнәсәбәт күрсәтә.

Дөрес, әдипнең бу хатасы озакка бармады. Казандагы II мөселман съездыннан соң, әле Октябрьга кадәр ук, ул бу ялган идеядән кискен рәвештә баш тарта, территориаль автономия позициясенә баса.

Г. Ибраһимовның «Ирек» тәге эшчәнлеге революция үсеше өчен файдалы, ә аның үзе өчен мактаулы булды. Ул милли буржуазиянең позицияләрен какшатуга, татар халкының сыйнфый аерымлануына ярдәм итте. Газета киң катлау халык массалары арасында популярлык казана, аның тиражы 7 меңгә җитә. Бу ул чор татар матбугаты өчен күрелмәгән бер хәл иде. Шуңа күрә капиталистлар һәм алпавытлар, татар миллионерлары акчасына чыгарыла торган контрреволюцион буржуаз матбугат органнарының бөтенесе диярлек бер авыздан Г. Ибраһимов һәм аның газетасы өстенә ташлануы бер дә гаҗәп түгел.

Ләкин Г. Ибраһимовны, аның милли буржуазиягә каршы көрәшен һичкем туктата, аның ихтыярын какшата алмый. Ул горур рәвештә алга атлавын дәвам итте. Татар һәм башкорт хезмәт ияләрен революция эшен ахырынача дәвам итәргә өндәде. Ә буржуазиянең матбугат ялчыларына аның җавабы мондый иде:

«Сез халыкны мәңге хәерче булып калырга чакырасыз. Сез байлардан аерылмыйк дип, мөселман демократиясен байлар файдасына корбан итәргә телисез, шул эшкә каршы баручыларга ялган пычраклар ыргытасыз. Оятсыз рәвештә ялганлап, пәрдәләп, ярлыларны буржуазия сыйныфына корбан итәргә телисез. Җитәр, ярлы халык моңарчы бай белән түрә алдында баш иярга мәҗбүр булып килде. Моннан соң ул үзенең юлын, үзенә нинди юл файдалы икәнен беләчәк һәм шул юл белән барачак»[2].

Татар буржуаз матбугаты февраль революциясенә кадәрге чорда ук формалашып кына калмыйча, демократик һәм революцион көчләргә каршы көрәштә нык лап оешырга да өлгергән иде. Аңа каршы нәтиҗәле көрәш алып бару өчен революцион газеталарга берләшергә, бердәм демократик фронт төзергә кирәк була. «Ирек» бу өлкәдә үзеннән соң Казанда Ш. Әхмәдиев редакторлыгында чыга башлаган демократик юнәлештәге «Аваз» һәм М. Вахитов катнашы белән чыгарылган «Кызыл байрак» газетасы белән бергә хәрәкәт итә. Программаларында һәм политик платформаларында булган кайбер үзенчәлекләргә дә карамастан, бу өч газета контрреволюцион матбугатка, бөтен буржуаз милләтчелек хәрәкәтенә каршы актив көрәш җәелдерә.

«Ирек» 1917 елның көзенә кадәр чыгып килә. Сентябрь аенда ул «Солдат теләге» һәм «Авыл халкы» исемле башка ике демократик газета белән берләшә һәм на-

---

[1] «Ирек» газетасы 1917 ел, 5 июль.
[2] Шунда ук.

тиҗәдә өч газета урынына «Безнең юл» исемле яңа газета чыгарыла башлый. Аның редакторы шулай ук Г. Ибраһимов була. Газета эшендә Ф. Сәйфи, Г. Касыймов шикелле соңыннан Татарстанның күренекле җәмәгать эшлеклеләре булып җитешкән кешеләр катнашалар.

Бу газеталарның бергә кушылуы демократик журналист кадрларын милләтчел буржуазиягә һәм аның реакцион матбугатына каршы берләштерергә, аларның көчләрен политик көрәшнең төп юнәлешләренә тупларга, халыкны революцион тәрбияләү бурычларын уңышлырак хәл итәргә мөмкинлек бирде[1].

Г. Ибраһимовның февраль белән Октябрь арасындагы революцион көрәшенең төп удары контрреволюцион милли буржуазиягә, татар буржуазиясенең шовинистик омтылышларына юнәлдерелгән иде. Бу көрәш Россиянең милли районнарындагы үзенчәлекле шартларда барды. Бу турыда Г. Ибраһимов үзе менә нәрсә яза:

«Февраль революциясе чорында милләтчел буржуазиягә каршы безнең көрәш, татар тормышы шартлары таләп иткәнчә, кайбер очракларда аерым үзенчәлекле формаларда барды. Татар хезмәт массасының... сыйнфый аңын уяту өчен, аны буржуа һәм алпавытлардан, кулак һәм руханилардан аерып алу өчен тыштан «гомум мөселман», «бөтен Россия», «бөтен татар» һәм сыйнфый түгел дип аталган, ә асылда буржуаз-алпавыт җыелышларында, корылтайларда, съездларда һәм «милли мәҗлестә» катнашырга туры килде»[2].

Г. Ибраһимов Мәскәүдә һәм Казанда булып үткән мөселман съездларының икесендә дә катнаша. Ул аларда пантюркистик буржуазиягә һәм аның политик лидерларына каршы көрәш алып бара, сыйнфый көрәш һәм революция идеяләрен алга сөрә.

Дөрес, Г. Ибраһимов Мәскәүдәге мөселман съездына башта мәгълүм бер өметләр белән барды. Әмма аның составы белән танышкач, бу съездның М. Бигиев, Г. Исхакый кебек дин әһелләре, пантюркистлар тарафыннан вакытлы хөкүмәт канаты астында оештырылган булуын белгәч, аңа булган иллюзияләрдән тиз арына. Г. Ибраһимов бу съездда милләтче Г. Исхакыйны кискен тәнкыйтьләп чыга, аның буржуазия ялчысы булуын фаш итә.

Г. Ибраһимовның контрреволюцион татар буржуазиясенә каршы көрәше Казандагы 2 нче мөселман съездында да дәвам итә. Бу юлы көрәш съезд ачылганчы ук башлана. Матбугат вәкилләре киңәшмәсендә «Милли шура» әгъзасы Г. Исхакый татар газеталары өстеннән контрольлек итә торган орган төзү турында карар өстерәп кертергә тырыша. Бу барлык матбугатны буржуазия кулына бирү омтылышы иде. Г. Ибраһимов моңа катгый рәвештә каршы чыкты, буржуаз милләтченең бөтен татар матбугатын «Милли шура» контроле астына кертү омтылышын фаш итте. Нәтиҗәдә, Г. Исхакый таләбе кире кагыла.

Съездның үзендә башлыча ике политик төркем арасында көрәш бара. Аның берсе — контрреволюцион пантюркистлар, аларның башында А. Цаликов, Г. Исхакый, Ибн. Ахтямовлар торалар. Ә революцион төркем башында М. Вахитов, Г. Ибраһимов, Ш. Әхмәдиев була. Г. Ибраһимов М. Вахитов белән беренче тапкыр әнә шунда очраша. Татар халкының бу ике күренекле революционеры арасындагы дуслык һәм хезмәттәшлек шуннан башланып китә.

Көрәш съезддан соң да тукталмады. Казандагы «Кызыл байрак», «Аваз», Уфадагы «Ирек» газеталарында Г. Ибраһимов, М. Вахитов, Ш. Әхмәдиев, Ф. Сәйфи һ. б. ларның съездны оештыручыларның политик йөзен фаш иткән мәкаләләре басыла.

Г. Ибраһимовка милләтчелек һәм шовинистлык карашлары бөтенләй ят иде. Ул татар буржуазиясенең Россиянең барлык мөселманнарын бергә берләштерү хакында-

[1] «Чулпан» газетасында басылган бер мәкаләдә хәбәр ителгәнгә караганда, Г. Ибраһимов бу газетаны 1917 елның декабрь ахырларына кадәр, ягъни Петроградка учредительное собраниегә киткәнчегә кадәр, редакцияли. Шул ук мәкаләдә Г. Ибраһимов киткәч газетаның юнәлеше үзгәрүе, аннан сыйнфый көрәш рухы чыгып бетүе әйтелә. Ләкин Г. Ибраһимовның бу газетадагы эшчәнлеге әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Киләчәктә бу эшләнер дип ышанабыз. «Безнең юл» газетасы гомумән тарихчылар һәм әдәбият белгечләре тарафыннан җитди тикшерелергә, бәя алырга тиеш. Бөек Октябрьның 50 еллыгына хәзерлек уңае белән моның актуальлеге арта.

[2] КПССның Татарстан өлкә комитеты каршындагы партия архивы. 1378 фонд, 1987 опись, 110 бәйләм, 378 эш, 107 бит.

гы пантюркистик планнарына кискен каршы чыкты, аларның фәнни хата, политик зарарлы, практик перспективасыз булуын исбатлады. Әдипнең мондый реакцион омтылышларга каршы көрәше әле революциягә кадәр «Галия» мәдрәсәсендә үк башланган иде. Ә хәзер ул тагы да тирәнәйде һәм политик үткенәйде. Г. Ибраһимов кебек зур язучының һәм җәмагать эшлеклесенең бу мәсьәләләрдә принципиаль позициядә торуы татар һәм башкорт халыкларын интернациональ рухта тәрбияләүдә зур роль уйнады, хезмәт ияләренә революцион тәэсир итте.

Ниһаять, Октябрьга хәзерлек чорында Г. Ибраһимов халык массаларын турыдантуры революцион хәрәкәт эшенә тартуга зур әһәмият бирде, эшчеләр, солдатлар һәм крестьяннар арасында политик тәрбия, революцион оештыру эше алып барды. Ул солдат митингларында чыгышлар ясый, эшчеләрнең революцион кутәрелешләрендә катнаша, крестьяннар арасында революцион агитация алып бара. Г. Ибраһимов Уфа хезмәт ияләренең 1917 елгы 1 май демонстрацияләрендә актив катнаша. Башкорт халык шагыйре С. Кудашның язуына караганда, ул М. Гафури белән бергә типография эшчеләре демонстрациясе колоннасының башында бара[1].

Әдип укучы яшьләрне, мәдрәсә шәкертләрен дә онытмый. Замандашларының истәлекләренә караганда, ул мәдрәсәдә укытучылык эшен ташласа да, «Галия»гә еш килә, шәкертләрне җыеп, аларга көндәлек политик вакыйгалар һәм алда торган бурычлар турында сөйли.

Г. Ибраһимовның Октябрьга кадәрге революцион эшчәнлегенең иң югары ноктасы 1917 елның 9 октябрендә Уфада большевикларның Уфа комитеты инициативасы белән үткәрелгән массовый демонстрациядә катнашы булды. Популяр язучы-революционер урамнарда һәм мәйданнарда, мөселман солдатлары оешмасы урнашкан йортның балконыннан ялкынлы чыгышлар ясый, империалистик сугышны бетерергә чакыра, алпавыт җирләрен һич кичектергесез конфискацияләүне, капиталистларны дәүләт власте органнарыннан куып, бөтен властьны советларга бирүне таләп итә.

7—8 мең кеше катнашкан бу демонстрация халык массаларын революционлаштыруда зур роль уйнап кына калмады, Г. Ибраһимовның үзенең политик үсешенә дә гаять көчле йогынты ясады. Ул большевиклар белән идея-политик яктан торган саен ныграк якынайды. Монда, әлбәттә, иң әһәмиятлесе революциянең этәргеч көчләренә һәм максатына караш уртаклыгы иде.

## 2

Бөек Октябрь Г. Ибраһимовның идея-политик үсеше юлында зур борылыш ясады. Моннан соң аның революцион эшчәнлеге киңәеп кенә калмый, тирәнәя, тагын да югарырак баскычка күтәрелә. Ул матбугаттан, җыелышлардан һәм митинглардан файдалана, буржуазиягә каршы көрәшен дәвам итә, татар һәм башкорт хезмәт ияләрен Совет власте тирәсенә туплый.

Октябрьдан соң күп тә үтми, Уфада эчке Россия һәм Себер татарларының «милләт мәҗлесе» җыела. Ул башлыча морзалардан, эре сатучылардан, авыл кулакларыннан, дин әһелләреннән һәм татар офицерларыннан тора. Билгеле, ул реакцион була, халык интересларын чагылдыра алмый. Шуңа да карамастан, Г. Ибраһимов һәм башка революционерлар анда катнашалар. Халык алдында «милләт язмышы турында кайгыртучыларның» бу җыелышының контрреволюцион асылын ачып бирергә, милләт берлеге, «милли-мәдәни мохтарият» лозунглары белән алданып, «милләт мәҗлесе» артыннан барган, аннан үзенең милли теләкләре үтәлешен көткән татар-башкорт халкының бер өлешен аерып алырга кирәк була.

Миллэт мәҗлесендә Г. Ибраһимов, Ш. Әхмәдиев, Г. Касыймов, Октябрь революциясе платформасында торган сул көчләр исеменнән чыгыш ясап, башта ук Совет властен тану мәсьәләсен куялар. Алар башында В. И. Ленин торган Совет хөкүмәтенә — Халык Комиссарлары Советына котлау телеграммасы җибәрү турында тәкъдим кертәләр. Ләкин «миллэт мәҗлесе» күпчелек тавыш белән бу тәкъдимне кире кага, «бөек төрек-татар миллэте үзенең язмышын өч көнлек большевиклар власте белән

[1] С. Кудаш. Хәтердә калган минутлар. Казан, 1959 ел, 77 бит.

бәйли алмый»[1] дип белдерә. Җыелыш җитәкчеләре Бохара әмиренә котлау телеграммасы җибәрүне яхшырак дип табалар. Шулай итеп, «миллэт мәҗлесе» үзенең реакцион, буржуаз табигатен тулысынча ачып сала.

Г. Ибраһимов бу җыелышта гаять зур ныклык, принципиальлек һәм активлык күрсәтә. Аның ялкынлы речьләре, «миллэт мәҗлесе» бинасы стеналарын үтеп, ярлы халыкка барып җитә, аңарга көчле тәэсир ясый.

1917 елның көзендә демократик көчләр белән буржуазия арасында кискен көрәш учредительное собраниегә сайлау мәсьәләсе буенча барды. Билгеле булганча, бу сайлаулар, Октябрьдан соң булса да, бик катлаулы шартларда, Октябрьгә кадәр үк төзелгән исемлекләр буенча үткәрелә. Халыкның шактый өлеше Октябрь революциясенең әһәмиятен әле төшенеп җитмәгән, милли буржуазиянең көче җимерелмәгән иде. Боларның һәммәсеннән, әлбәттә, контрреволюцион буржуазия файдаланмакчы, тавышларны үз файдасына җыймакчы, шулай итеп учредительное собраниегә үз кешеләрен өстерәп кертмәкче була. Г. Ибраһимов «милли шура» кандидатларына каршы, эшчекрестьян һәм солдат вәкилләрен үткәрү өчен эзлекле көрәш алып барды. Ул монда Уфа белән генә дә чикләнеп калмый, губернаның башка шәһәрләрендә дә була, авылларга бара, крестьяннар арасында эшли.

Г. Ибраһимов, учредительное собрание депутаты буларак, 1918 елның 5 январенда Петроградка килә. Бу нәкъ учредительное собраниенең ачылган көне була. Әдип вокзалдан ук туп-туры Таврида сараена ашыга.

Учредительное собраниегә сайлаулардан соң инде шактый вакыт үткән иде. Г. Ибраһимов шактый политик көрәш тәҗрибәсе туплап өлгерә. Соңгы айларда булып үткән вакыйгалар күп мәсьәләләргә аның күзен ачты. Хәзер инде ул учредилканың асылда буржуазия кулындагы корал булуын, аңа таянып контрреволюциянең Совет властен бәреп төшерергә ниятләнүен яхшы аңлый. Ул шулай ук учредительное собраниегә делегат булып һәркайда уң социалистларның — буржуазия ялчыларының кул үтүен белә.

Г. Ибраһимов килүенә учредилканың мөселман депутатлары меньшевик А. Цаликов җитәкчелегендә мөселман фракциясе оештырган булсалар да, ул анда керми, сул депутатларга кушыла.

Учредилка ямышы нәкъ большевиклар көткәнчә була да. Ул үзенең контрреволюцион асылын ачып бирүне озакка сузмый. Ул Совет хөкүмәтенең декретларын танудан баш тарта һәм шуның белән үзен Совет властена һәм халыкның күпчелеге ихтыярына ачыктан-ачык каршы куя. Большевиклар һәм башка сул депутатлар собраниене ташлап чыгалар. Г. Ибраһимов та ташлап чыга. 6 январьда Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитеты декреты белән учредилка таратыла.

«Чулпан» газетасы чыга башлагач, аның беренче санында ук Г. Ибраһимов үзенең сайлаучыларына хисап рәвешендә «Мәрхүм учредительное собрание» исемле мәкалә белән мөрәҗәгать итте. Учредилканың контрреволюция кулында корал булуын әйтте. Ул учредилканың куылуы өчен байлар, алпавыт һәм буржуазиянең кан елавы, бу елауда уң социалистлардан алып Милюков — Дутов — Пуришкевичларга кадәр булган контрреволюцион көчләрнең берләшүе турында хәбәр итә.

Учредилканың элекке депутаты аның эшче һәм солдат, авыл ярлылары интересларына дошман булуын, аларның өметләрен бары тик Совет власте гына тормышка ашыра алачагын әйтә. Шуңа күрә ул аларны Совет хөкүмәте тирәсенә тупланырга чакыра:

«...безгә — эшче, солдат, ярлы авыл халкына һәм боларның файдасына тырышучыларга...— бөтен куәтебезне, бөтен өметебезне эшче, солдат һәм ярлы авыл халкы шураларына бәйләргә, шунда керергә, шунда эшләргә, шулар аркылы теләкләребезне үткәрергә тиешле буладыр... Без, ярлы халык, Октябрь революциясен көчәйтү, тирәнәйтү, моның өчен эшче, солдат вә ярлы авыл халкы шуралары тирәсенә җыелырга, буржуазия белән булган мөнәсәбәтне тәмам өзәргә, икътисади коллыктан азат ителү юлында көрәшергә тиешлебез.

Мәркәздә һәм урыннарда хакимият эшче, солдат вә авыл халкы шураларына!

---

[1] Касымов Г. Пантюркистская контрреволюция и ее агентура султангалеевщина. Рус телендә. Казан. 1931 ел, 44 бит.

Мена хәзер безнең шигаребез шул булырга тиеш» [1].

Г. Ибраһимовның бу мәкаләсе татар һәм башкорт хезмәт ияләренең учредилкага мөнәсәбәттә күзен ачуда һәм аларның өметләрен бу контрреволюцион оешмадан аерып алып, Совет власте, Совет хөкүмәте белән баглауда гаять зур роль уйнады.

Учредилканы ташлап чыккан большевиклар һәм башка сул депутатлар белән бергә, Г. Ибраһимов 1918 елның 10 январенда җыелган эшче, солдат һәм крестьян депутатлары советларының III Бөтенроссия съездында тавыш бирү хокукы белән катнаша. Ул анда Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты члены итеп сайлана.

Нәкъ менә шуннан соң Г. Ибраһимов тормышында һәм революцион эшчәнлегендә яңа, иң әһәмиятле һәм иң бай этап башлана. Ул этап турыдан-туры большевиклар партиясе, бөек юлбашчы В. И. Ленин белән, аларның политик йогынтысы һәм җитәкчелеге белән бәйләнгән. Г. Ибраһимов күренекле революционер һәм дәүләт эшлеклесе булып нәкъ әнә шул чорда җитеште дә.

Г. Ибраһимовка, дәүләт Верховный органы члены буларак, дөньядагы беренче социалистик дәүләт төзелешенең бик күп әһәмиятле мәсьәләләрен хәл итүдә катнашырга туры килә. Ул Совет властеның беренче декретларын кабул итүдә, аларны тормышка ашыруда катнаша.

1918 елның 19 январенда Совет хөкүмәтенең декреты белән (ул декретка В. И. Ленин кул куя) Милләтләр халык комиссариаты каршында Үзәк мөселман комиссариаты төзелә. Күренекле революционер М. Вахитов комиссариатның председателе, ә Г. Ибраһимов һәм Ш. Манатов аның урынбасарлары итеп билгеләнәләр. Г. Ибраһимов шулай ук Комиссариатның коллегия члены һәм төрле вакытта төрле бүлекләрнең мөдире дә була.

Үзәк мөселман комиссариатында халыкара эшчеләр хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе, Төркия коммунистлар партиясен төзүчеләрнең берсе Мостафа Сөбхи, татар большевикларыннан Н. Якубов, И. Казаков, Һ. Маликов, Н. Вахитовлар эшлиләр. Аның эшендә күренекле башкорт революционеры Ш. Ходайбердин, шулай ук И. Рахматуллин, Ш. Әхмәдиев, М. Максуд кебек соңыннан республиканың күренекле җәмәгать эшлеклеләре яки язучы булып җитешкән кешеләр актив катнашалар. Комиссариатка турыдан-туры М. Вахитов җитәкчелек итә, аның эшчәнлеге белән В. И. Ленин якыннан кызыксына, кайгыртучанлык күрсәтә.

Мөселман комиссариаты, үзәк совет дәүләт аппаратының бер кисәге буларак, Россиянең төрки-татар халыклары арасына революция нигезләрен кертү, мөселман хезмәт ияләрен Совет властена якынайту буенча зур роль уйнады. Ул үзенең эшчәнлеген В. И. Ленин һәм М. Вахитов кул куйган хөкүмәт декреты нигезендә төзелгән урыннардагы мөселман комиссариатлары аркылы башкара. Мондый комиссариатлар Мәскәү, Петербург, Казан, Уфа, Оренбург, Саратов, Астрахань, Нижний Новгород һ. б. шәһәрләрдә булалар. Алар хезмәт ияләре депутатлары Советларының тиешле җирле оешмалары составына керәләр һәм большевиклар партиясенең җирле комитетлары җитәкчелегендә эшлиләр.

Үзәк мөселман комиссариатының зур бер тарихи хезмәте милли буржуазиянең контрреволюцион милләтчел оешмаларын, аларның матбугат органнарын туздыруда булды.

Пролетариат революциясенең ярты еллык үсеш тәҗрибәсе «милли идарә», «милли шура» кебек оешмаларның контрреволюция оясы, эшче-крестьян хөкүмәтенең чараларына каршы баручы, татар, башкорт халыкларының дәүләт төзелешенә аяк чалучы көч булуын күрсәтте. Көн тәртибенә бу контрреволюцион оешмаларны бетерү бурычы килеп баса. Милләтләр халык комиссариаты һәм Үзәк мөселман комиссариатының 1918 ел 21 апрель карары нигезендә «милли идарә» бетерелә. Ә бераз элгәрәк «милли шура», «хәрби шура» һәм аларның җирле оешмалары бетерелгән була. Г. Ибраһимов һәм М. Вахитов тарафыннан Комиссариатның 1918 ел 15 апрель карары белән татар буржуазиясе газеталарының иң әшәкесе, иң контрреволюционеры булган «Ил» газетасы ябтырыла.

Совет органнарының бу карарлары татар контрреволюцион буржуазиясе тарафыннан зәһәрле ачу белән каршы алына. Үзәк мөселман комиссариатына, М. Вахитов

[1] «Чулпан» газетасы 1918, 18 январь.

һәм Г. Ибраһимовка революция дошманнарының, алар газеталарының ярсулы атакаларын кире кагарга туры килә. Комиссариат «милли идарә»нең чын йөзен, аның Советка каршы эшләгән әшәкелекләрен хезмәт ияләренә тулырак күрсәтү өчен урыннарга милли идарәнең эшчәнлеге турында хисап материалы җибәрә.

Үзәк мөселман комиссариаты Россиянең мөселман халыклары арасында Совет властеның политикасын аңлату, хезмәт массаларын эшче-крестьян хөкүмәтенең декретлары белән таныштыру буенча зур эш башкарды. Комиссариатның җитәкчеләре һәм сотрудниклары еш кына мөселман халкы яшәгән шәһәрләргә чыгалар, анда җыелышлар үткәрәләр, докладлар ясыйлар. Г. Ибраһимов апрель ахыры, май башларында Уфада була, анда татар, башкорт эшчеләренең җыелышларын уздыра. Ул Совет хөкүмәтенең эчке һәм тышкы политикасы турында доклад сөйли. Совет хөкүмәте политикасы төрле милләт хезмәт ияләре интересларын һәм омтылышларын чагылдыручы революцион политика булуын әйтеп, эшче һәм ярлы крестьяннарны аның тирәсенә тыгызрак тупланырга чакыра. 2 майда Уфада эшчеләр клубында бик күп кеше катнашы белән үткәрелгән җыелыш, Г. Ибраһимов докладын тыңлап тикшергәннән соң, Совет властен яклап, Совет хөкүмәтенең чараларын яхшы дип тапкан карар кабул итә. Анда Уфа татар-башкорт демократиясенең Совет властена һәртөрле кул сузуларга каршы чыгарга һәрвакыт әзер торуы әйтелгән[1]. Тагын шунысы әһәмиятле, җыелыш милли идарәнең бетерелүен яхшы дип таба, кадетлардан, буржуаз милләтчеләрдән торган бу контрреволюцион дошманың хезмәт халкы өчен күп явызлыклар эшләвен, демократик чараларны үткәрүдә киртә булуын, халык исеменнән сөйләгән булып, мөселман пролетариатын башка милләт эшчеләре алдында уңайсыз хәлдә калдыруын билгеләп үтә. Мондый характердагы резолюция ул вакытта Уфада Г. Ибраһимов катнашы белән үткәрелгән җыелышларның бөтенесе өчен дә хас.

Комиссариат хәрби оешмалар белән тыгыз элемтәдә була, фронтта мөселман солдатлары арасында зур политик эш алып бара. Комиссариат каршында махсус хәрби бүлек эшли, аның белән М. Вахитов җитәкчелек итә. Архив материалларыннан күренгәнчә, Г. Ибраһимов фронтларга бара, хәрби конференцияләрдә катнаша.

Октябрьдән соң татар халкының төрле сыйныфлары арасында кискен көрәш милли мәсьәлә тирәсендә барды. Үзәк мөселман комиссариатына милли проблемаларны хәл итү белән турыдан-туры шөгыльләнергә туры килә. Г. Ибраһимов, табигый, бу көрәшнең үзәгендә була. Милли мәсьәләләрне хәл иткәндә аның тар милли рамкалардан чыгып түгел, бәлки сыйнфый, революцион, интернациональ позицияләрдә торып эш итүен аеруча басым ясап әйтергә кирәк. Моны әдипнең «Идел-Урал республикасы» мәсьәләсенә карашында, контрреволюцион Болак арты «республикасы»н җимерүгә ярдәм итүендә, «Татар-башкорт республикасы» проектына карашында күрергә мөмкин.

Г. Ибраһимов Үзәк мөселман комиссариатында мәгариф, культура мәсьәләләрен хәл итүдә актив катнашты, татарлар арасында бу эшләрне советчыл нигездә оештыручыларның беренчесе булды. Ул мәгариф эшен, милли буржуазия кулыннан тартып алып, пролетариат, советлар кулына бирүдә зур роль уйнады.

Г. Ибраһимовның мөселман комиссариатында эшләгән чордагы зур тарихи хезмәте «Чулпан» газетасын оештыру, аны чыгару булды. «Чулпан» — беренче татар совет газетасы. Г. Ибраһимовның үзенең әйтүенчә[2], ул хәтта бөтен Россия төрки-татарлары арасында беренче зур официаль совет газетасы була. «Правда» аның чыгуына зур әһәмият бирә, анда «атаклы татар әдибе Ибраһимов»[3] катнашуын билгеләп үтә.

«Чулпан» башка официаль хөкүмәт газеталары белән бер рәттә йөри. Анда мәкаләләре белән М. Вахитов, Ш. Әхмәдиев, Г. Касыймов һәм башкалар актив катнашсалар да, аны чыгару нигездә Г. Ибраһимов өстендә була. Аның кайбер саннарын ул тулысынча үзе әзерли. Моның шулай икәнен Г. Ибраһимов замандашларының истәлекләре генә түгел, газетаны җентекләп өйрәнү дә раслый. Г. Ибраһимов исеме куел-

---

[1] Октябрь революциясе һәм социалистик төзелеш дәүләт архивы. 1333 фонд, 1 опись, 1 эш, 115 бит.

[2] КПССның Татарстан өлкә комитеты каршындагы партия архивы. 1378 фонд, 1987 опись, 110 бәйләм, 378 эш, 114 бит.

[3] «Правда» газетасы, 1918 ел, 23 январь.

ган зур-зур мәкаләләр генә түгел (ә алары һәрбер санында диярлек), газетаның баш мәкаләләре, авторының исеме куелмаган күп кенә материаллар Г. Ибраһимов тарафыннан язылганнар.

Кызганычка каршы, «Чулпан» әле хәзергә кадәр тиешенчә өйрәнелмәгән, үзенең лаеклы бәясен алмаган. Хәлбуки, аның революция алдында хезмәте гаять зур. Үзенең һәрбер санында диярлек, татарчага тәрҗемә итеп, Совет хөкүмәтенең әһәмиятле декретларын һәм карарларын бастырып бару үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Ә бит аларны тәрҗемә итүче дә Г. Ибраһимов үзе була. Аннан соң ул бу декретларның һәрберсе хакында диярлек махсус мәкаләләр яза, аларның эчтәлеген һәм әһәмиятен популяр рәвештә киң халык массаларына аңлата. Татар буржуаз милләтчеләре Г. Ибраһимовны большевиклар хөкүмәте белән хезмәттәшлектә гаепләделәр, буржуаз матбугатта аның турында провокацион материаллар бастырдылар. Бу пычрак язмаларында алар, әлбәттә, оригинал түгелләр иде. Алар бу өлкәдә дә, башка бик күп мәсьәләләрдәге шикелле үк, рус контрреволюциясе белән берләштеләр, үзләренең язмаларында түбәнрәк дәрәҗәдә Пуришкевич речьләрендә, Милюков газетасы «Дух» мәкаләләрендә, Каледин хатларында әйтелгән сүзләрне кабатладылар. Ләкин пролетариат революциясен күрә алмаучы мөселман контрреволюционерларының бу лыгырдаулары тарих карванын туктатырлык түгел иде.

«Теләсәгез никадәрле генә сүгенегез, теләсәгез ничаклы зәһәр чәчегез,— дип язды Г. Ибраһимов аларга җавап итеп,— боларның һәммәсе татарның эшчесе, аңлы солдаты, ярлы авыл халкы каршында сезнең кара йөрәгегезне генә ачып салачак, безнең өчен фидакярәнә башлаган бу изге тарихи эшебезгә иман куәте генә арттырачактыр»[1].

## 3

Үзәк мөселман комиссариаты татар, башкорт һәм Россиянең башка кайбер төрки халыкларына иске деньяны җимерүдә һәм яңа тормыш нигезләрен төзүдә актив ярдәм итте. Күренекле революционер-ленинчы М. Вахитов җитәкчелегендә монда эшләү Г. Ибраһимовка зур революцион чыныгу, политик үсеш мәктәбе булды. Совет хөкүмәтенең карарларын тормышка ашыру буенча практик эштән тыш, Г. Ибраһимовка монда эшләгәндә Коммунистлар партиясенең һәм Совет хөкүмәтенең күренекле эшлеклеләрен күрергә һәм тыңларга туры килә. Ул үзенең эше буенча милләтләр халык комиссариаты белән тыгыз бәйләнештә була, берничә мәртәбә аның баш коллегиясе утырышларына катнаша, комиссариат җитәкчеләре белән сөйләшә. Г. Ибраһимовның В. И. Ленинның эшләгән җире, эшче-крестьян хөкүмәте урнашкан Смольныйга керү өчен Ленин үзе кул куйган даими пропускы була. Әлбәттә, боларның һәммәсе әдипнең идея-политик үсешенә уңай йогынты ясый, аны большевиклар белән якынайта.

Г. Ибраһимов практик эшчәнлегендә большевикларга никадәр ныграк якыная барса, эсерлар идеологиясеннән шулкадәр тизрәк арынды. Әдипнең үзе язуынча[2], аның эсерлар партиясе белән каршылыклары аеруча 1918 елның февралендә кечәя.

Г. Ибраһимов сул эсерлар партиясе белән конфликтка керган моментларның берсе солых мәсьәләсе иде. Бу мәсьәләдә большевиклар белән солых договорына каршы чыккан сул эсерлар арасында кискен көрәш җәелә. Дөрес, Г. Ибраһимовның бу мәсьәләдә позициясе баштә бик ачык булмый. Ләкин Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитетында эшләү дәверендә большевиклар йогынтысында әдипнең политик карашлары бик тиз үстеләр. Ул нык рәвештә В. И. Ленин, большевиклар ягына баса. 1918 елның 23 февралендә, нәкъ Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты Германия хөкүмәтенең яңа ультиматумын тикшерергә җыелган көнне, ул «Чулпан» газетасында түбәндәге юлларны язып чыга:

«Хәзер революция язмышы картага куелды.

Мәмләкәттә азык, юл вә башка һәр көн кирәк нәрсәләр мөшкил хәлдә, һичкем сугышны теләми. Һичбер солдатның корал күтәреп сугышка барырлык куәте калмаган.

---

[1] «Чулпан» газетасы. 1918, 28 февраль.

[2] КПССның Татарстан өлкә комитеты каршындагы партия архивы. 1378 фонд, 1987 опись, 110 бәйләм, 378 эш, 122 бит.

Нинди генә чараларга керешмә, яңадан сугышны уйларга һич вә һич бертөрле юл юк. Теләсә ни генә булсын, яңадан сугыш, яңадан кан түгеш мөмкин түгел...

Россия революциясе алда бөек көрәшләргә хәзерләнү өчен, бөтен дөнья революциясе юлында зур бер куәт булып мәйданга чыгар өчен, якын киләчәкнең бөек идеалы юлында бөтен дөньяны оештыру хезмәтен алып барырлык хәлдә үзен көчәйтү өчен, вакытлыча, авыр, җан әрнеткеч солыхка имза кыйлачакмы?

Яки бөтен бәни адәмнең азатлыгы юлында көрәшерлек куәт ясау өметеннән ваз кичеп, Россиянең яңадан сугышырлык хәле калмаганлыгын игътибарга алмыйча, яңадан сугыш игълан кыйлачак, үзен һәлак итәчәкме?

Авыр, газаплы бер трагедия.

Уйлыйбыз, бәек Россия революциясе беренче юлны ихтыяр кылыр дип»[1].

Һәм шул ук көнне бу мәсьәлә Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитеты утырышында тикшерелә.

Бу утырышта В. И. Ленинга бердәнбер дөрес позицияне үткәрү өчен күп көч куярга, зур түземлелек белән солыхның котылгысызлыгын аңлатырга туры килә. Г. Ибраһимов һичбер икеләнүсез В. И. Ленин позициясенә баса, БҮБК члены буларак, солых договорын яклап тавыш бирә.

Мәгълүм булганча, бу утырышта сул эсерлар большевикларга каршы чыгалар. Алар солых договорына каршы тавыш бирәләр. Г. Ибраһимовка да көчле һөҗүмгә каршы торырга туры килә. Ләкин әдипнең ихтыяр көчен, аның ныклы большевистик позициясен эсерларның шантаж һәм яла ягулары да, партиядән чыгару белән янаулары да какшатмый. Ул большевиклар белән бер сафта революция казанышларын ныгыту юлында В. И. Ленин артыннан горур атлавын дәвам итә. Ул газета битләрендә солыхны, Совет хөкүмәтенең тынычлык политикасын яклап, сул эсерларның контрреволюцион позициясен фаш итеп, мәкаләләр яза, хезмәт иялəренә: «Россиядә революцияне саклап калу — хәзерге көндә солых ул», дип аңлата. Ул хезмәт халкына мөрәҗәгать итеп, аны, солыхның авыр шартларына карап, паникага бирелмәскә чакыра, аның вакытлыча бер чигенү, киләчәк яңа тормышка юл ачкан бер чара гына булуын күрсәтә.

1918 елның 14 мартында Мәскәүдә Советларның гадәттән тыш IV Бөтенроссия съезды җыелды. Бу вакытта Совет хөкүмәте һәм партия Үзәк Комитеты Мәскәүгә күчкән иде инде. Мөселман комиссарлары белән бергә, Г. Ибраһимов та Мәскәүгә килә.

Съезд абсолют күпчелек тавыш белән Брест солых договорын раслый. Бу мәсьәлә буенча доклад белән В. И. Ленин чыга. Съездга катнашкан Г. Ибраһимов делегатларның бөек юлбашчыны ничек каршы алуларын түбәндәгечә тасвирлый:

«...Ленин карашының дөреслеге йөрәкләргә утырган иде инде. Бу съездда пролетариат юлбашчысы тагы элеккедән дә артыграк тантана белән каршы алынды... Ленинның килеп чыгуы, сүзе тагы элеккедән дә артыграк алкыш белән каршы алына иде инде»[2].

Солых договорына съездда сул эсерлар каршы чыгалар. Алар съезд карарына протест йөзеннән Халык Комиссарлары Советы составыннан чыгуларын белдерәләр. Нәтиҗәдә, сул эсерлар белән Совет хөкүмәтендә хезмәттәшлек итү турындагы килешү юкка чыгарыла.

Эсерларның бу провокацион акты Г. Ибраһимов белән сул эсерлар партиясе арасындагы каршылыкларның тагын да көчәюенә китерде. Бу партия аның күз алдында көннән-көн ныграк контрреволюция лагеренә таба тәгәри барды.

Г. Ибраһимов эсерлар партиясе карарларына буйсынмый. Ул үз постында кала бирә, Совет властен ныгыту өлкәсендә тагын да активрак эшли.

Г. Ибраһимов белән эсерлар арасында каршылык тудырган мәсьәлә бер бу гына түгел иде. Ул аграр мәсьәләгә мөнәсәбәттә алардан принципиаль аерыла. Ә бит аграр мәсьәлә социалистик революциягә карата большевикларны һәм эсерларны принципиаль рәвештә аерган төп мәсьәләләрнең берсе иде. Г. Ибраһимов шулай ук Кызыл Армия төзү мәсьәләсендә дә эсерлар карашын урталашмый, большевиклар позициясендә тора, регуляр армия төзүгә каршы чыккан эсерларны гаепли.

[1] «Чулпан» газетасы. 1918, 23 февраль.
[2] «Кызыл Армия» газетасы. 1920, 22 апрель.

1918 елның җәендәге вакыйгалар Г. Ибраһимовны сул эсерлар белән арасын бөтенләй өзүгә китерделәр. Германия илчесе Мирбахны үтерү белән бәйләнгән провокацион авантюра һәм аның артыннан оештырылган контрреволюцион фетнә эсерләрның Совет власте дошманнары булуларын, хезмәт илләре белән һичбер бәйләнешы булмаган авантюристлар группасы икәнлеген ачып салдылар. Советларның V съезды аларның вәкилләрен Совет власте органнарыннан чыгару турында карар кабул итте.

Г. Ибраһимов хәзер контрреволюцион асылы тулысынча мәгълүм булган партия белән мөнәсәбәтен элегрәк өзмәвенә үкенә. Ул революциянең беренче көннәреннән үк большевиклар белән кулга-кул тотынып эшләсә дә, формаль рәвештә булса да сул эсерлар партиясе члены булып калуында дәвам итте. Бу Г. Ибраһимовны, әлбәттә, кыен хәлдә калдырды. Әнә шундый авыр, газаплы кичерешләр белән тулы көннәрдә ул революция юлбашчысы В. И. Ленинга мөраҗәгать итә.

Владимир Ильич аны кабул итә. Бу тарихи очрашу хакында Г. Ибраһимовның үзенең ничек сөйләве турында Г. Мөхәммәдова истәлекләрендә болай дип яза:

«Ленин мине кабул итте. Мин аңа Коммунистлар партиясенә, аның сәясәтенә, карарларына булган карашымны һәм «сул коммунист», «сул эсер»ларның оятсыз хәрәкәтләренә булган мөнәсәбәтемне, үземнең хәзер уңайсыз хәлдә калуымны — һәммәсен ачыктан-ачык сөйләп бирдем. Ленин мине бик дикъкать белән тыңлады.

Ленин миннән бу вакыткача кайда, нинди урыннарда эшләвемне сорашты, соңыннан һич шикләнмичә, икеләнмичә, миңа: «Эшегездә дәвам итегез!» дип кисеп әйтте. Пролетариат революциясенең бөек юлбашчысы булган Владимир Ильичның миңа шулай ышануы минем күңелемне күтәрде, рухландырды һәм минем бөтен киләчәк язмышымны билгеләде.

Галимҗан үзенең Ленин белән бу очрашуын бик зур бәхет дип саный, уңае туры килгәндә бу турыда һаман сөйли иде»[1].

Г. Ибраһимовта моннан соң социализм өчен ахыргача әзлекле көрәш алып баручы бердәнбер политик көч В. И. Ленин җитәкчелегендәге Коммунистлар партиясе дигән фикер тәмам ныгый. Һәм шуннан соң ул эсерлар белән организацион-идеологик элемтәсен бөтенләйгә өзә.

Элекке татар сул эсерларының киләчәктәге эше мәсьәләсе комиссариатта махсус тикшерелә. Сул эсерлар партиясенең рәсми политикасына кире мөнәсәбәтен һәм комиссариаттагы актив эшчәнлеген искә алып, Г. Ибраһимов милләтләр халык комиссары тәкъдиме белән комиссариатта калдырыла[2]. Советларның V Бөтенроссия съезды мөселман делегатларының 12 июльдә үткәрелгән киңәшмәсендә ул яңадан комиссариатның председателе урынбасары һәм коллегия члены итеп сайлап куела.

## 4

Г. Ибраһимов «Чулпан» газетасындагы мәкаләләренең берсендә:

«Революция бәйрәм генә, шатлык кына түгел. Революция һәм бәйрәм, һәм шатлык, һәм газап вә михнәт, һәм җәһәннәмдер. Революциянең бер кенә доньяны азатлык кояшы белән яктыртып, рухларны бәйрәм белән, иге-чиге булмаган шатлык белән тутырса, аның кайбер сәгате, кайбер минутлары күз ачып күз йомганчы адәмнең чәчләрен агартачак дәрәҗәдә каты газаплар, җәһәннәм газаплары китерәдер»[3], дип язган иде.

1918 елның җәендә Ватан алдына нәкъ әнә шундый көннәр килде. Советлар иле бик зур кыенлык белән ирешелгән тынычлыктан озак файдалана алмады, аңа каршы тышкы һәм эчке дошманнар сугыш башладылар. Бу вакытта партия Үзәк Комитеты һәм В. И. Ленин республиканың хәлиткеч фронты итеп көнчыгыш фронтны саналылар. «Рус революциясен генә түгел, халыкара революцияне дә коткарып калу чехословак фронтында хәл ителә», дип язды В. И. Ленин.

Ибраһимов үзе Мәскәүдә булса да, күңеле фронтта, канлы сугышлар барган җирдә иде. Аны туган җире — Башкортстан һәм Татарстанның дошман басып алган рай-

---

[1] «Совет әдәбияты» журналы. 1964 ел, 9 сан, 99 бит.

[2] Октябрь революциясе һәм социалистик төзелеш үзәк дәүләт архивы. 1333 фонд, 1 опись, 12 эш, 46 докл.

[3] «Чулпан» газетасы, 1918, 30 март.

оннарында җәфа чигүче халык язмышы борчыды. Ул бөтен йөрәге белән шунда ашкынса да, аңа комиссариатта эшен дәвам итәргә туры килә. Фронтка М. Вахитов китә, ә ул аның урынына комиссариатның җитәкчесе итеп билгеләнә.

Яшь совет республикасы өчен бик кыен көннәр иде бу! Нәкъ шушы көннәрдә мәкерле контрреволюция көчләре Совет халкына тагын бер авыр удар ясыйлар: 30 августта В. И. Ленинга һөҗүм итеп, аны каты яралыйлар.

Бөек юлбашчыга һөҗүм бөтен ил буенча көчле нәфрәт ташкыны тудырды. Бу җинаять Г. Ибраһимовны да тирән тетрәтә. Ул ашыгыч рәвештә комиссариат утырышын җыя. Комиссариат Г. Ибраһимов белдерүе буенча бертавыштан мондый карар чыгара:

«Үзәк мөселман комиссариаты коллегиясе бөтен дөнья пролетариатының юлбашчысы иптәш Ленинга җинаятьчел һөҗүм ясалуы... уңае белән революция җинаятьчеләре — үтерүчеләргә тирән нәфрәт белдерә, мөселман пролетариатын революция юлбашчысы һәм Совет власте тирәсенә тыгызрак тупланырга, аны үзенең яклавы астына алырга, контрреволюциягә каршы аяусыз көрәшкә хәзер булырга чакыра» [1].

Бу мөселман комиссариатының бөек юлбашчыга мәхәббәтен, пролетариат революциясе эшенә бирелгәнлеген күрсәтүче тарихи ант иде.

Гаять кыен шартларда Г. Ибраһимов комиссариатның өзлексез эшен дәвам итте. Аның җитәкчелегендә комиссариат фронтка ярдәм итү буенча зур оештыру һәм политик эш җәелдерә. Г. Ибраһимовка көнне төнгә ялгап эшләргә туры килә. Комиссариат фронт өчен милли частьлар һәм подразделениеләр оештыру, агитацион әдәбият чыгару буенча зур эш башкара. Аның үзенең дә күп кенә сотрудниклары фронтка китә.

Г. Ибраһимовның комиссариаттагы эшчәнлеге 1918 елның көзенә, аның авыруына кадәр дәвам итте. Бу вакытта авыр тормыш һәм киеренке көрәш нәтиҗәсендә аның сәламәтлеге шактый какшаган иде инде. Архив материалларыннан күренгәнчә, Г. Ибраһимов 17 сентябрьдән 6 октябрьгә кадәр больницада ятып чыга. Аннан соң ул үзен комиссариаттагы эштән азат итүләрен сорап гариза бирсә дә, аның үтенечә канәгатьләндерелми. Аңа сәламәтлеген ныгыту өчен бер айлык ял бирелә. Октябрь урталарында Г. Ибраһимов Казанга кайта. Аның ялы 1919 елның 1 гыйнварена кадәр озайтылып, гәрчә ул рәсми рәвештә 1919 елның башларына чаклы комиссариат әгъзасы булып саналса да, анда яңадан әйләнеп кайтмый.

Г. Ибраһимов Казанга кайткач та актив көрәштән китми. Гражданнар сугышының кызган көннәрендә, революция язмышы фронтта, сугыш кырларында хәл ителгән бер вакытта көрәшче йөрәге читтә кала алмады. Ул яңадан көрәш дәрьясына, аның да иң кыен һәм куркыныч участогына ташлана: Кызыл Армиянең махсус заданиесе белән Колчак тылына китә.

Бу Г. Ибраһимовның зур кыюлыгы һәм тәвәккәллеге, революция, халык бәхете өчен бер нәрсәсен кызганмавын, хәтта гомерен дә бирергә әзер торуын күрсәтүче факт иде.

Бу сәфәре тәмамлангач, Г. Ибраһимов яңадан Казанга кайта. Әмма ул һаман да иҗат эшенә керешми әле. Чөнки аңа революция елларында туктап торган әдәби иҗат эшчәнлеген яңадан башлап җибәргәнче, турыдан-туры әдәби әсәрләр язуга тотынганчы, кайбер әһәмиятле идеологик мәсьәләләрне хәл итәргә, үткән революцион көрәш тәҗрибәсен теория белән яктыртырга кирәк була. Һәм ул марксизм-ленинизмны махсус утырып ныклап өйрәнергә керешә.

Мәгълүм булганча, Г. Ибраһимовка Октябрьгә кадәр марксизмны ныклап өйрәнергә туры килмәде. Большевизмга ул, башка күп кенә революционерлар шикелле, революцион көрәш процессында килеп кушылды. Ул вакытта аңа теория белән шөгыльләнергә вакыт та, мөмкинлек тә юк иде. Алда күренгәнчә, ул революция көн тәртибенә куйган практик мәсьәләләрне үзенең революцион сиземләве, большевиклар белән тыгыз элемтәдә булуы аркасында уңышлы хәл итеп килде. Гражданнар сугышыннан соң, Г. Ибраһимовка, ниһаять, фәнни социализм теориясен махсус өйрәнү мөмкинлеге ачыла.

---

[1] Октябрь революциясе һәм социалистик төзелеш үзәк дәүләт архивы 1333 фонд, 1 опись, 2 эш, 109 бит.

Хәзер ул марксизм-ленинизмны, коммунистлар партиясе тарихын ныклап өйрәнә, аның төп документларын укый.

Г. Ибраһимов үзен борчыган сорауларга җавапны, ачыкланмаган мәсьәләләргә ачыклыкны В. И. Ленин әсәрләрендә тапты. Шундый мәсьәләләрнең берсе шәхеснең тарихтагы роле мәсьәләсе иде. Әш шунда ки, Г. Ибраһимов әле Октябрьдан соң да беркадәр вакыт бу мәсьәләдә иске, идеалистик карашлардан арына алмады. Ә бу Г. Ибраһимов революциянең күп кенә әһәмиятле мәсьәләләре буенча эсерлар белән конфликтта, большевиклар белән бер сафта эшләп, көрәшеп килгәндә дә дәвам итте.

Большевиклар партиясенә керүенең 1920 елга кадәр сузылуының сәбәпләрен аңлатып, Г. Ибраһимов болай дип язган иде:

«Миңа РКП(б) идеологиясе белән бәйләнгән, марксизм нигезләреннән килеп чыга торган кайбер мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк иде. Мәсәлән, яман аты чыккан ихтыяр ирегe, шәхес һәм коллективчылык мәсьәләләре һәм башка кайбер мәсьәләләр. Миңа аларны теоретик хәл итү өчен шактый вакыт кирәк булды һәм аларны хәл итмичә торып мин үземне ахыргача инанган коммунист дип саный алмадым. Бу эш шактый вакыт таләп итте, һәм минем РКП(б) сафларына керүем сузылды. Коммунистлар белән бергә милләтчелеккә һәм буржуазиягә каршы көрәшемне дәвам иткән хәлдә, мин ике елга якын бу мәсьәләләр өстендә эшләдем».

Г. Ибраһимовның В. И. Ленин әсәрләре өстендә ничек эшләве турында аның 1920 елның апрелендә бөек юлбашчының 50 еллык юбилее уңае белән язылган ике мәкаләсе[1] ачык күрсәтеп тора. Татар матбугатында мондый мәкаләләрнең басылып чыгу фактын үзе генә дә зур политик әһәмияткә ия иде. Алар бу чорда Г. Ибраһимов ачыклаган теоретик мәсьәләләрнең бөтенесен дә әчено алмасалар да, әдипнең идея-политик үсешен ачык характерлыйлар, аның вак буржуаз эсерлык идеологиясеннән арынып, гыйльми коммунизм теориясенә килүен күрсәтәләр. Г. Ибраһимов большевиклар партиясенә керү уңае белән 1920 елның 3 декабрендә Татарстан җәмәгатьчелегенә адресланган ачык хатында нәкъ әнә шул турыда язды да:

«Дүртенче елы барган революциянең һәммә дәверендә, һәммә фаҗигаләрендә коммунист иптәшләр белән бергә булганлыгым, ...фикердә һәм гамәлдә өч ел буенча бөтенләй РКП(б) белән бергә эшләмәклегем һәммә иптәшләрнең күз алдында иде.

Бу бергәлекне рәсмиләштерү өчен, үзенең идеологиясе һәм тактикасы белән камил бөлгенлеге ачылган сул социалист-революционер интернационалистлар партиясеннән чыгып, ...Россия коммунистлар (большевиклар) партиясенә керүемне эшче-крестьян иптәшләргә, фикердәшләргә рәсми рәвештә белдерәм»[2].

Г. Ибраһимов большевиклар партиясенә 1920 елның декабрендә кабул ителә. Аның партия стажы 1917 елның 15 апреленнән расланa.

Әнә шулай итеп революционер-язучы үзенең тормышын идея һәм организацион яктан коммунистлар партиясе белән бәйләде. Г. Ибраһимовның марксизм-ленинизмга килү юлы әнә шулай булды.

—✦—

[1] «Пролетариат диктатурасы һәм Ленин». («Кызыл Армия» газетасы, 1920, 22 апрель). «В. И. Ленинның әдәби хезмәтләре» («Эшче» газетасы, 1920 ел, 22 апрель).
[2] «Эшче» газетасы, 1920 ел, 3 декабрь.

# *Мирсәй Әмиргә 60 яшь*

## ӘЙТӘСЕ СҮЗЛӘР КҮП ӘЛЕ

Әгәр Мирсәй Әмир турында биографик әсәр язарга туры килсә, мин аны бер күңелсез вакыйгадан башлар идем. Салам түбәле фәкыйрь авыл өе. Өй эче тулы бала-чага. Барысы да елашалар. Германия сугыш башлаган. Мәсәлим абзый фронтка китә. Хәнифә апа елый, кызлар елаша, аларга карап бәләкәй ир балалар да, шул исәптән Мирсәяф тә елый. Бу төптән юан, түбәтәйле малай — булачак язучы; хәзергә ялан тәпиле, киндер күлмәк-ыштаннан иде. Аңа әле нибары сигез яшь. Ләкин шушы көннән соң аның көрәшләр белән тулы сыналу еллары башланачак. Аны әле алда зур тетрәнүләр, тирән тойгылар калдырырга җыенган вакыйгалар көтә.



Һәм, чыннан да, Мирсәяф үсеп өлгерми, туып-үскән Агыйдел буендагы Урал таулары белән камалган Җиргән авылында, анда гына түгел, бөтен илдә бөек революция көннәре башлана. Унтугызынчы елны инде безнең Мирсәяф РКСМга язылган яшьләр тирәсендә клубта мәйханә килеп спектакльләрдә катнашып йөри. Күп тә узмый, гражданнар сугышы Җиргәнгә дә килеп җитә. Авылны аклар ала. Халыкны олау хезмәтенә куалар. Яшүсмер Мирсәяф тә шул кешеләр арасында. Ул, алгы сызыкта хәтәр маҗаралар кичереп, кызыллар белән аклар арасында атыш барган чакта окопларга килеп эләгә, чак үлми кала. Ахырда, хәйлә корып, аклар кулыннан ычкына. Ә өендә әле күптән түгел генә сугыштан кайткан әтисе тиф чиреннән үлеп китә.

Инде сугышлар тынды дигәндә, дәһшәтле ачлык, ваба елы башлана. Мирсәяфнең өч туганы, сөекле әнисе үлеп китә. Мирсәяф, апасы һәм энесе белән, әле күптән түгел генә ачылган балалар йортына алына. Ачлыктан үләргә җиткән балаларның икесен коткаралар, ләкин иң кечкенәсе терелә алмый. Аны Мирсәяф белән Мәрьям кул чанасына салып күмәргә илтәләр.

Булачак язучыны ел азагында Әхтәм абзасы үз өенә алып кайта. Тик Мирсәяфнең өй тирәсендә чуалырга исәбе юк, аның укыйсы килә. Кечкенәдән үк укуга, белемгә булган мәхәббәт барысын да җиңә, ул Стәрлетамак җидееллык мәктәп-интернатына укырга китеп бара. Иҗат хезмәтенә җитди әзерләнү шунда башлана. Шунда ул беренче хикәясен яза. Ә ике елдан соң инде ул Мәрьям апасына күчә. Ул хәзер волость башкарма комитетында эш башкаручы, ул комсомол эшенә актив катнаша, Уфада чыга торган «Яшь юксыл» газетасының актив хәбәрчесе. Алай гына да түгел, ул авыл яшьләре белән бергәләп, үзе редакцияләп, үзе рәсемнәрен ясап, кульъязма журнал чыгара. Мирсәяф җитди рәвештә киләчәген язучылыкка, я рәссам булуга багышлау турында уйлана башлый. Ә бер елдан соң, җәе чыккач, теләген тормышка ашыру өчен Казан якларына юл тота.

Кем булырга дигән мәсьәлә Казанда хәл кылына. Мирсәяф художество училищесына керә. Димәк, киләчәк рәсем сәнгатенә багышланачак! Менә ул укый башлый. Ләкин күңел канәгать түгел. Матур әдәбиятка булган чиксез мәхәббәт кулга каләм алырга кыстый, хис-тойгыларга бай егеткә тынычлык бирми. Җитмәсә, зур-зур язучылар, әдәбиятыбызның алласы Галимҗан Ибраһимов, искиткеч шигырьләр остасы Һади Такташ яшәгән Казанда тора бит әле ул!

Һади Такташның «Авыл яшьләре» редакциясендә эшләгәне Мирсәяфкә күптән мәгълүм иде инде. Ничек кенә шул шагыйрьне күрәсе икән! Артык тәкать калма-

гач, көннәрдән бер көнне Мирсәяф тота да хикәя яза. Юк, басылып чыксынга түгел, бары атаклы шагыйрь белән очрашу өчен сылтау эзләп кенә. Ул Такташ белән очрашу бәхетенә ирешә. Шушы очрашудан соң Мирсәяф әдәбият юлына ныклап аяк баса, Мирсәй Әмиргә әверелә. Ул училищеда укуын дәвам иттерсә дә, хәзер күбрәк хикәя язу турында уйлана, эшкә редакциягә урнаша һәм, әлбәттә, Парнас биеклекләренә үрмәләү турында хыяллана. Әмма язучылык юлы такыр түгел. Мирсәй Әмирнең «Бәхет порошогы» исемле сатирик хикәясен сокланып укыгач, Кырымда авырып яткан Галимҗан Ибраһимов Гомәр Галигә «Кем соң ул! Берәр өлкән язучыдыр, бу шуның псевдонимыдыр» дип хат яза. Яшь язучы өчен сөенечле вакыйга була бу. Ләкин бераздан «Пар күгәрчен» повесте өчен тәнкыйть яшь язучыны җиңнәрен сызганып дөмбәсләргә тотына. Күтәрелүләр һәм аска тәгәрәүләр. Ләкин шулай да көчле талант иң бәйләнчек тәнкыйтьчеләрнең дә игътибарын үзенә җәлеп иттерә. Аның «Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре», «Безнең авыл кешесе» повестьларының матбугат битләрендә шаулаганын мин дә беләм.

Ниһаять, Мирсәй Әмиргә дан китергән «Агыйдел» повесте дөнья күрә. Авторны котлап язган хатында Галимҗан Ибраһимов повестька югары бәя бирә. «Бик әйбәт!» ди. Укучы исә әсәрне куанып, яратып каршы ала. Авторга рәхмәт хатлары ява башлый. Бу вакытта Мирсәй Әмир инде үсеп канатланган, җитлеккән язучы һәм җәмәгать эшлеклесе. Аны Язучылар союзының идарә җитәкчесе итеп сайлыйлар. Ләкин тиздән утыз җиденче ел башлана, уңышлар белән дәртләнеп, зур әдәби сикерешкә җыенган илһамлы язучы көннәрдән беркөнне кулга алына. Мирсәй Әмир нахактан ел ярым төрмә җәфасын чигә...

Мин аның төрмәдән котылып кайткан көннәрен ачык хәтерлим. Очрашкач күземә ташланган беренче нәрсә шул булды: язучының чәчләренә чал кергән иде. Мин исәнләшеп, язучының котылуына шатлыгымны белдердем. Ләкин Мирсәй Әмирнең күзләрендәге моңсулыкны, үз эченә китү чагылышын мин һич онытмам.

Бәлки, ул рухи сынган булгандыр! Юк, алай түгел. Моны хәзер бик ачык итеп әйтергә була. Чөнки Мирсәй Әмир тормышында булып узган бу иң зур тетрәнүфаҗигадән соң тиз айныды. Авторның сугыш елларында язган әсәрләрен, «Миңлекамал»ын хәтерләгез. «Миңлекамал» каерылган канатларның төзәлүен генә күрсәтми, авторның яңа биеклекләргә күтәрелүен раслый. Бу пьеса, минемчә, безнең сәхнә әсәрләребезнең иң яхшыларыннан. Ул характер пьесасы. Мирсәй Әмир шушы пьесасы белән безнең драматургиябезне югары күтәрде, яңа ориентир билгеләде дияр идем мин.

Шулай да Мирсәй Әмир, асылда, хикәяче. Аның сугыштан соң язган «Саф күңел» дилогиясе моның ачык мисалы. Автор бу әсәрен язып зур кыюлык күрсәтте. Әсәр сугыш еллары турындагы колачлы романнарыбызның әйбәте.

Мирсәй Әмиргә 60 яшь тулды. Алтмыш елның кырыгы әдәби иҗат эшенә багышланган. Шул елларда бик күп хикәя, повестьлар, пьесалар язылган. Бөек Ватан сугышы елларын чагылдырган иң зур әсәрләрнең берсе тудырылган.

Мирсәй Әмирнең иҗаты күп кырлы. Ул хикәяче, драматург, публицист, очеркист, ул юморист, сатирик, эпик полотнолар мастеры.

Мирсәй Әмир безнең әдәбиятыбызга үз почеркы белән килеп керде һәм һич кабатланмаган художник булып үсте. Ул чын мәгънәсендә оригинал, гыйльми тел белән әйтсәк, үз мәктәбен тудырган проза остасы.

Әйе, бу бәхәссез. Шул ук вакытта Мирсәй Әмирнең әдәбиятка килгән юлы бик күпләрнең башыннан кичкән, бик күп тапкыр кабатланган, безнең чынбарлыгыбыз өчен типик бер күренеш тә. Тарихта тиңе булмаган бөек яңару илебез халыкларының иң киң катлауларын урыкыннан кузгатты. Моңарчы йокымсыраган, чәбәләнепчәбәләнеп тә үзләренә юл таба алмыйча сүнәргә дучар ителгән талантлар шул бөек революция давылларында чыныктылар, аның шифалы яңгырларында үсеп чәчәк аттылар. Мирсәй Әмир дә шушындыйларның берсе.

Мирсәй Әмирнең дәрәҗәсе, абруе зур. Ул моңа лаеклы. Болар барысы да күркәм хезмәт, халыкка, илгә, партиягә саф күңелдән бирелгәнлек нәтиҗәсе. Ләкин мин аны шәхес буларак та беләм. Ул кече күңелле, үзенең йөрәк җылысын кеше өчен, аерата яшьләр өчен, кызганмый торган язучы. Бу салмак хәрәкәтле, тыныч табигатьле кешене авыр михнәтле, шул ук вакытта мактаулы юл канәгатьмаган, киресенчә, чыныктырган, ныгыткан, принципиаль, икейөзлеләнә белми торган кешегә әверелдергән.

Мин аның кешеләрне яраткан кебек үк табигатьне сөйгәнен дә беләм. Ул балык тотарга ярата, ул агачлар, чәчәкләр белән серләшә ала. Тик аның табигатькә булган мәхәббәте үзенчәлекле, крестьянча җитди. Бер әңгәмә корып утырганда мин аңардан:

— Сездә образлы сүз әйтү теләге кайчан һәм ничек туды, Мирсәй абый! — дип сорадым.

Мирсәй Әмир җитдиләнеп бераз уйланып торды да:

— Минем әнием китаплар укырга бик ярата иде.— диде.— китапка булган мәхәббәт, күрәсең, шуннан күчкәндер. Ләкин нидер әйтергә теләү табигать матурлыгына соклanудан.

Ул кинәт көлемсерәде.

**— Мондый бер вакыйгага истә калган. Малай чакта бик матур бер тау итәгенә тары чәчтек без. Мин шул тары җиренең матурлыгына сокланып кайттым. Кайттым да күргәннәремне бик тулы итеп әнигә сөйләдем. Бик җанлы килеп чыккандыр, ахры, әни минем хикәямне тыңлап бетерде дә: «Улым, син моны яз!» диде.**

**— Соң яздыгызмы? — дидем мин.**

**Мирсәй Әмир, гадәтенчә, башын бераз аскарак иеп, сабыр гына көлеп куйды.**

**— Яздым, ләкин берничә елдан соң, Стәрле интернатында чакны. Тукайча, шигырь итеп яздым.**

**Тары чәчелгән җир турында матур итеп сөйләп бирүгә инде илле ел вакыт узган. Шушы ярты гасыр эчендә Мирсәй Әмир үзенең әсәрләрендә бик күп нәрсәләр турында һәм бик матур итеп сөйләде. Аның китапларын укып берничә буын укучы тәрбияләнде. Аның образлы сүзе бик күпләргә җан азыгы булды, күңелләрне пакьләндерде, гүзәл эшләр башкарырга канатландырды.**

**Мирсәй Әмиргә алтмыш яшь. Әйтәсе сүзләре күп әле язучының. Без Мирсәй Әмиргә бик нык сәламәтлек, озын гомер телибез. Без аның бик күп яңа әсәрләрен укып куаначакбыз әле.**

**АТИЛЛА РАСИХ.**

*Мирсәй Әмир*

# Мәхәббәт хаты

*(Шул исемдәге яңа әсәрдән)*

## I

— Юк, Миңнегөл җаным, сәламәтлегем өчен артык исем китми. Хәтта үлем дә ул кадәр куркытмый мине...

Миңнегөл дигәне, бераз көчләнеп булса да, кычкырып көлеп җибәрде.

— Һи, һи, һи, җүләр! Җүләр дә инде син, Камилә! Үлем турында сөйләргә әле сиңа... Кит!.. — Ул, мөмкин кадәр шат һәм гамьсез күренергә тырышып, зур көзге каршына килде, бөдрәсе бетә башлаган чәчен кузгатып, кабарткалап куйды. Аннары бөтенләй җитди тонга күчеп, ахирәтен тынычландыруда дәвам итте. — Сәламәтлегең бер дә кешенекеннән ким түгел. Йөрәк? Йөрәге авыртмаган кеше бармыни хәзер?.. Берни булмас, менә күрерсең. Үтәр дә китәр. Хәзер бит инде бездә медицина да көчсез түгел...

— Юатуың өчен рәхмәт, Миңнегөл. Тик мин чынлап әйтәм. Минем өчен иң авыры Рәиснең язмышы. Шул борчый, шул үзәгемне өзә.

— Рәисеңә ни булган соң? Әйтәм бит...

— Кирәкми, Миңнегөл. Ана күңелен алдау кыен. Һәлакәткә бара Рәис. Ә гаепле — үзем. Үзем!

Ишек артында телефон шалтырады. Миңнегөл, авыру дустын борчымас өчен, үзе чыкмакчы булган иде дә, кухня якта кыштырдаучы әби трубканы алып өлгерде. Камилә белән Миңнегөл, аңа колак салып, икесе дә тын калдылар.

— Тыңлыйм, — диде әби. — Рәис өйдә юк шул. Бер дә әйтә алмыйм.

Миңнегөл акрын гына атлап, Камилә янына килде. Ярым яткан хәлдә диван почмагына сөяләп утырган дустының иңбашына кулын куйды.

— Рәисне сорыйлар.

— Кемнәр генә сорамый аны? Упкынга өстериләр баланы. Ә мин? Анасы? Тота алмыйм...

— Артык зурайтып күрәсең, Камилә, — диде Миңнегөл.— Зинһар, тынычрак бул... Ярый, мин китим инде. Борчылма, Камилә, ямә?

Камилә зур булып ачылган кара күзләрен бер ноктага текәгән килеш, бераз вакыт дәшми торды. Аннары тирән көрсенеп куйды.

— Килүеңә рәхмәт. Тагы кил. Син килсәң, миңа җиңел булып кала... Аннары, ни... ә, әйе, зинһар, шалтыратырга онытма инде, ямме?

— Онытаммы соң?..

— Бәлки, саламга тотынудыр, шулай да...

Миңнегөл китеп, биш-ун минут узуга тагын телефон шалтырады. Тагын Рәисне сорадылар.

Ана тирән көрсенеп куйды. Тагы унбиш минут чамасы узуга, Рәис үзе кайтып керде.

Ул һәрвакыттагыча бераз гына ачулы чырай белән саргылт коңгырт кашларын җыерган хәлдә, эре-эре атлап, түрге бүлмәгә узды. Диванда утырган әнисе аның гәүдәсенә килешеп торган купшы фасонлы соры пиджагының матур аркасын гына күреп калды. Улының бер генә минутка булса да тукталуын теләгән иде. Рәис үзе тукталмагач, аны дәшеп туктатасы килмәде. Ишек аша гына булса да, «улым, кайда булдың?» дип сорарга теләде ана. Тик сорамады. Сорап торудан ни файда? Рәис бары кашларын гына җыера төшәчәк тә, үпкә катыш ачулы тавыш белән:

— Мин бит инде детсад баласы түгел! — дип җавап кайтарачак.

Камиләнең хәсрәтле күзләре идәндәге хәтфә юллык өстендә торып калган юеш эзләргә төште. Ана буларак, улын әз генә шелтәлисе килде аның, аңа акыл өйрәтәсе килде. «Андый калын табанлы ботинка кигәч, һич югында, аягыңны сөртеп керә белергә кирәк иде, улым», дип әйтергә теләде ул. Ләкин тагын дәшмәде. Әйтеп ни файда?

Бала булып, үзе берәр сүз әйтсен иде Рәис, авыру анасының әз генә булса да күңелен юатырлык берәр җылы сүз тапсын иде... Кая ул! Көт син аңардан...

Әнә ул, ерак та түгел, ачык ишек аша күренеп тора. Язу өстәле тартмасыннан нидер эзли. Аның ниндидер үз эшләре, үз дөньясы бар. Һич югында берәр сорау бирсен иде. Болай, үпкәләгән кеше сыман, дәшми тормасын иде...

Чү! Әллә егет әнисенең күңелендәге зарын ишеттеме? Ул, теләмичә генә булса да, иренеп кенә, ачуланып кына булса да, мыгырдап куйды.

— Мам!

— Нәрсә, улым?

— Миңа акча кирәк.

Уф! Дәшми торуы яхшырак булган икән!

Ана йөрәге меңгә телгәләнде. «Акча юк», дип кенә җавап бирергә иде, булмый. Камиләнең акчасы бар һәм моны Рәис бик яхшы белә. Ичмасам, нигә кирәк икәнлеген әйтсен иде, анысын да әйтми бит. Сорасаң, «һәр тиенгә отчет бирергә, мин сезнең хезмәтчегезме әллә?» — диячәк. Курыкмыйсы иде. «Бирмим! — дип кырт өзәсе иде. — Тамагың тук, кияреңә бар. Азып-тузып йөрү өчен сиңа миндә бер тиен дә акча юк!» — диясе иде... Әйтеп кара!.. Бер дә каршы килмәс. Ачуланмас. Тавышын да күтәрмәс. Йөрәгенне ярырлык тынычлык белән генә җавап кайтарыр: «Ярар, — дияр. — Үземә акча табу юлын эзләргә туры килер», — дияр.

Ә улы әйтергә теләгән юлның нинди икәнлеге Камиләгә сер түгел. И тәки башсызлыгы житәр, сүзен сүз итәр.

— Ярый, улым, — диде ана. — Миңа әнә ридикюлемны алып бир әле.

Рәис, аңа бик зур бурычлык күрсәткән кыяфәттә, иренеп кенә өстәл яныннан китте. Комод өстендә яткан ридикюльны алып Камиләгә сузды.

— Күпме кирәк, улым?
— Ун.
— Бәлки, биш тә житәр?
— Сатулаш инде тагы.
— Ярый, мә. Тик зинһар...
— Лан, лан...

Бусы Рәиснең «ладно, ладно» дигән сүзе. Әнисе үгет-нәсихәт бирергә теләгән чакларда ул һәрвакыт шулай диярга ярата. Янәсе: «ярар, ярар. Күп ишеттем, әйтмәсәң дә беләм!»

Камилә әйтер сүзен әйтә алмыйча бүленеп калды. Рәис янадан түр бүлмәгә узып, язу өстәлендә актарынырга тотынды. Ләкин ана кешенең күнеле тынычлык тапмады. Аның һаман да улы белән ни турыда булса да сөйләшәсе, аның тавышын гына булса да ишетеп торасы килә иде. Ул артык түзә алмады, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып, зәгыйфь кенә тавыш белән дәште.

— Улым!

Рәис жавап кайтармады. Ишетмәгәнгә түгел, юк, ул ишетте. Әнисе, «улым» дип дәшкәнне яратмый. Җәберсенә.

— Рәис!
— Нәрсә-ә!

Теләмичә генә бирелгән шушы бер сүзлек жавапта никадәр ризасызлык, никадәр зар авазы!.. Ләкин Камилә анысына игътибар итмәскә тырышты.

— Сине телефоннан сорадылар.
— Кем?
— Кем икәнен әйтмәде, ахрысы.
— Кирәк булса, шалтыратырлар әле.

Һәм нәкъ шул минутта телефон тагын шалтырады. Ләкин Рәис чыгарга ашыкмады.

— Синадыр,— диде әнисе,— бар, ал.

Рәис үз эшеннән аерылмады.

— Алучы бар анда.

Ул арада чынлап та кухнядагы әби телефон трубкасын алып өлгергән иде инде.

— Тынлыйм... Рәис? Өйдә, хәзер әйтәм.

Рәис ашыкмый гына телефонга чыкты һәм, нәрсә сөйләшкәнне әнисе ишетмәсә дә ярар диптер инде, алгы бүлмә ишеген ныгытып ябып куйды.

Камиләнең йөрәге, пычак кадалган кебек, чәнчеп авыртып китте.

— Аһ!

Әгәр бу коточкыч авырту озаграк дәвам итсә, белмим, ни булыр иде. Бәхеткә каршы, ул тиз жибәрде. Камилә жинелрәк сулый башлады.

— Юк, юк! — диде ул, Рәис турында үзенең күнелендә куерган ямьсез уйларга каршы төшеп.— Ул андый ук түгел. Биксез яткан ридикюлендәге акчаны да сорамыйча алмый ул. Юк, юк! Рәис ерткыч хайван түгел. Аның жаны, йөрәге булырга тиеш. Күнел дигән нәрсәсе булырга тиеш. Ә соң аның жанын эретерлек, күнелен йомшатырлык бер генә чара да, бер генә сүз дә табылмас микәнни дөньяда?..

Рәис теләмичә генә телефон трубкасын алды. «Йөрисез шунда, кеше мәшәкатьләп» дигән сыман, ачулы гына тонда тавыш бирде.

— Тынлыйм.

Телефон трубкасында, ягымлы гына булып, хатын-кыз тавышы янгырады.

— Сез Рәис иптәш буласызмы?

Рәиснең тавышы бик аз гына йомшара төште.

— Әйе, мин.

— Сезнең исемгә почтада хат бар дигәннәр иде, бер буш вакытыгызда шуны барып алыгыз, зинһар. До востребования дип сорарсыз.

— Ни өчен почтага? Минем бит адресым бар.

— Күрәсең, үзегездән башка кеше кулына эләгү куркынычы булмасын дигәннәрдер. Ярый. Хушыгыз...

— Туктагыз, кем соң бу? Танымыйм.

— Бәлки, бер заман танырсыз да. Сау булыгыз. Уңыш телим...

— Туктагыз әле...

Рәис кырт бүленеп калды: телефон трубкасында еш-еш булып гудок тавышы янгырый башлады.

— Кем булды? — диде егет үзалдына. Нииндидер күнелле кызыксынудан аның ак йөзе алсуланып китте. Ярым ачылган тулы иреннәре кызарды. Яшькелт соры күзләре очкынланды. — Кем тавышы? Нәрсәседер таныш та кебек?.. Юк... хәер... — Ул игътибарсыз гына кулын селкеп куйды. Әле генә җанланып, яктырып киткән йөзе яңадан күнелсез, ачулы төскә керде. — Үзебезнең дуралардан берәрсе шаяртадыр...

Шулай да күнелендә туган кызыксыну хисе аңа тынгы бирмәде.

— Чорт с ними, — диде ул. — Ни булса да, алып карарга кирәк... Кайсы маташтыра икән?.. Кичкә кадәр өлгерәм әле.

Ул, кире эчке бүлмәгә кереп тормыйча, ишек катындагы гардеробтан зур ачык якалы, ярым кыска чабулы һәм түбән генә билбаулы итеп тегелгән соры пальтосын алып киде. Башына түбәсе яньчелгән чем яшел эшләпәсен элде дә чыгып китте.

## 2

Тышта, инде кич җиткән булуга карамастан, көн матурланып, яктырып киткән иде. Иртәдән бирле бер килеп, бер китеп явып йөргән көзге болытлар барысы да бергә кушылып, шомлы кара төскә кергәннәр дә, каядыр көнчыгышка таба шәһәр артына китеп, югалып баралар. Ә көнбатыш як — аяз. Шәһәрнең югары районыннан аермачык булып күренгән Ослан тавы артына түгәрәк күл чаклы булып зурайган алтын кояш батып бара.

— Кояш аязга бата, — дип уйлады Рәис, үзеннән-үзе кәефе ачылып. — Димәк, көннәр әйбәтләнә...

Ләкин аның яхшы кәефе бик тиз бозылды. Ишек янынннан дүртбиш адым китәргә өлгермәде, каршысына чәчәк атып утырган көнбагыш башы шикелле ялтырап, Игорь килеп чыкты. Эндәшми генә үтеп китсә бер хәл иде, эндәшми үтәме соң ул лыгырдык.

Юкка-барга көлә-көлә болай да битенең яртысыннан күбен алып торган авызы, Рәисне күргәч, бөтенләй колагына җитте.

— Нихә-әл, Рәис! — диде ул, саңгырау кеше белән сөйләшкәндәй кычкырып. — Профессор буласыңмы инде?

— Пошел ты... — диде аңа Рәис, кашларын җыерып һәм, башка бер сүз дә әйтмичә, тиз-тиз атлап, үз юлына китте.

Аның артыннан Игорьның бары аптырап: «чудак!» дигәне генә ишетелеп калды.

Рәис белән бер елны туган һәм бер үк ишек алдында аның белән бергә уйнап үскән бу беркатлы, ачык йөзле егетнең күнелендә бәлки тузан бөртеге кадәр дә әшәке уй булмагандыр. Ләкин Рәис өчен!.. Әгәр шунда Игорь аңа кирпеч ватыгы белән тондырган булса, җиңелрәк булыр иде...

Алар җиденчене бетергәнче бер класста укыдылар. Ә сигезенчедән башлап, әнисе Рәисне «А» классына күчерүгә иреште.

Чөнки ул класста Камиләгә таныш профессор балалары укый иде. Һәр хәлдә ни житте Игорьлар белән буталу түгел иде инде.

Рәиснең әтисе моңа каршы килеп: «Нигә баланы бер иләшкән иптәшләреннән аерырга?» ди башлаган иде дә, Камилә аңа авыз ачарга ирек бирмәде. Өйдә ул баш иде.

— Син педагогиканы белмисең! — диде ул иренә, кырт кисеп.— Ана бер төрле, ата икенче төрле сөйләсә, бала шуннан бозыла...

Яңа иптәшләр белән аралашуның нәтижәсе бик тиз сизелде: Рәис затлырак киемнәр, кул сәгате, магнитофон шикелле кыйммәтлерәк «уенчыклар» таптыра башлады. Монысына Камилә шат кына иде: әйдә, культурага, байлыкка, муллыкка иләшеп үссен! Тик менә егетнең уку ягыннан булган күрсәткечләре түбәнәя баруы гына Камиләнең күңеленә шомлы уйлар китерә иде. Тора-бара улы бөтенләй кулдан ычкына башлагач, кая барасын да әйтмичә, төннәр буена югалып йөри торган булып киткәч, бу шомланулар өзлексез борчылуга әверелде.

Исән-сау гына унны бетертәсе дә, тизрәк университетка урнаштырасы иде инде бу баланы.

Рәис, шактый мәшәкатьләр тудырып булса да, унынчыны бетерде бетерүен, өлгергәнлек аттестаты да алды. Ләкин университетка керә алмады. Аның үзенең моңа артык исе дә китмәгән иде. Әнә Игорь вузга керү турында уйлап та тормады, барды да эшкә урнашты. Нигә Рәискә дә шулай итмәскә? Казан тулы завод!..

Ләкин аңа тагы әнисе юл куймады.

— Җүләр, — диде, коты очып. — Тәүбә диген! Эшкә керү турында авызыңны да ачма. Университетка булмаса, берәр институтка керерсең. Быел булмаса, киләсе елга, кыш буе ныклап әзерләнерсең дә, жаның теләгәнен сайлап, отличнога биреп керерсең. Ашарыңа бар, киярең бар. Утырып эшлим дисәң, әнә кабинет, китапханә, кадерен белеп, укы да ят. Профессор булмыйча туктама...

Әнә шуннан китте инде: кем ишеттергәндер, күрше-тирәдәге танышбелешләре Рәисне «профессор» дип мыскыл итә башладылар. Ичмасам күңелендә чынлап та фән дөньясына тарта торган бер хыял булса иде. Әнисе капризы өчен бит. Профессор, имеш! Үзе кем соң? Педагог! Аның эше белемен сандыкка салып күгәрткән мещанка!.. Қ чорту!

Күңеленнән генә булса да, әнисе турында шулай хөкем йөртерлек хәлгә килгәч, Рәис тагы да ямьсезрәк төстә үзгәреп китте. Ул юри гамьсезлеккә бирелде. Шулай итеп, икенче ел да нәтижәсез узды. Хәлләр болай булып киткәч, әнисе үзе дә аны берәр эшкә урнашырга өнди башлаган иде инде. Тик Рәис аңардан көлде генә. Әйе. Рәхмәт! Хәзер инде ул эшләмичә дә күңелле яши белә... Әнә бит, университетта укымаса да, «профессор» дип йөртәләр үзен...

## 3

Рәис килеп кергәндә, почта ябылыр вакыт житкән иде инде. Сорап алучыларга адресланган хатлар бүлегенең калын пыяланы уеп ясалган кечкенә тәрәзәсе капланган, ә пыяла артында өстенә элемтәчеләр формасы кигән яшь кенә кызның, аяк өсте басып, өстәлен җыештырып торганы күренә иде.

Рәис, бер дә исе китмичә генә, тәрәзәгә капланган аяклы катыргыны кул аркасы белән бер як читкә этәреп куйды, кызның кырыс кара күзләре белән ачулы караш ташлавына каршы ягымлы елмаеп җавап бирде һәм сүзсез генә үзенең паспортын сузды.

— Соң бит инде,— диде кыз.

— Әгәр сез китеп өлгергән булсагыз, соң булыр иде.

Кыз — гомумән шулай һәркем белән исәпләшә торган олы җанлы кешеләрдән булып чыктымы, әллә егетнең ягымлы елмаю көченә җинелдеме — артык каршылык күрсәтмәде. Рәиснең паспортын карады да, өстәл каршында торган кырык тартмасыннан бер бөктәр хат чыгарып, күз иярмәслек җитезлек белән аларны берәм-берәм карарга тотынды.

«Шулкадәр тиз арада андагы фамилияләрне укып өлгерә микәнни соң ул? — дип шикләнде Рәис. — Әллә күз буяр өчен генә караган булып азапланамы? Әгәр юк дисә, кирәген бирермен мин аңа... Ә чынлап та булмаса? Теге кыз шаярып шалтыраткан булса?»

Ике-өч секунд вакыт эчендә Рәиснең башына шундый сораулар килеп, күңелендә шундый шикләр туып өлгерде. Алар әле бәлки моның белән генә дә бетмәгән булыр иде, хат табылып бүлдерде. Кыз, тоткарлануы бушка китмәгәнгә үзе дә шатлангандай, елмаеп, аны егеткә сузды.

— Рәхим итегез.

— Менә рәхмәт. Ә сез «соң» дисез. Хушыгыз.

— Сау булыгыз.

Кыз, инде кем килсә дә кабул итмим дигәндәй, тәрәзәсен ныгытып каплап куйды һәм ашыга-ашыга җыенырга тотынды.

Иң элек Рәиснең күзенә бәрелгәне — конвертның сул як яртысын алып торган көньяк күренеше булды. Рәискә күптән таныш пальмалар иде анда. Кайчандыр аның әнисе үзенең Сочидан язган хатларын шундый конвертка салып җибәрә иде. Шуңа күрә ул анысына игътибар итеп тормады, хатның кемнән икәнен белергә теләп, тизрәк адресына күз салды. Ләкин хат җибәрүче кеше үзенең исемен дә, кайдан икәнлеген дә язмаган иде. Дендрарий рәсеменә карап кына, Сочидан килгән дип булмый, әлбәттә. Мондый конвертларны хәзер үзебезнең Казанда да саталар. Билгеле, Казаннан: почта печате дә әйтеп тора. Тик кем язган? Хәрефләренә карап та чамаларлык түгел: адрес машинкада басылган.

Хәзер белербез.

Ләкин хатны ачкач та Рәис аны кем язганлыгын белә алмады. Хат имзасыз һәм тоташ машинкада басылган иде.

— Үзебезнең пижоннардан берәрсе шаяртадыр, — дигән уй килде Рәиснең башына, аның кызыксынуы кинәт сүрелгәндәй булды. — Тукта, шулай да нәрсә язарга мөмкин соң бу кадәр күп итеп? Бу кадәр тырышып?

Хат чынлап та шактый озын, һәм аның яхшы шома кәгазеннән дә, бөтен хәреф һәм юллары җыйнак итеп, җиренә җиткереп басылган булуыннан да бик зур дикъкать белән тырышып язылганлыгы күренеп тора иде. Җитмәсә сул як почмагына алсу-кызыл булып, янып торган роза чәчәге төшерелгән. Бусы инде егет кешенең йөрәген әллә нишләтеп, рәхәт дулкынландырып җибәрде. Юк, шаяртуга охшамый бу!

Һәм чынлап та бу имзасыз хат беренче юлларыннан ук Рәиснең йөрәгеннән тотып алды.

## 4

«Рәисем!

Әйе, Рәисем!

Сезнең минем өчен никадәр якын, никадәр кыйммәт, никадәр кадерле кеше икәнлегегезне аңлату өчен сезгә шулай дип мөрәҗәгать итүдән дә көчлерәк сүз таба алмадым.

«Йөрәгем!» дип карадым. Ләкин сез миңа йөрәгемә караганда кадерлерәк.

Беләм. Бу хат сезгә бик сәер тоелыр. Бәлки, минем сүзләремә ышанмассыз да. Яки мине бер акылсыз кеше дип уйларсыз. Ләкин нихәл итим. Йөрәгем бу хатны язарга куша. Әгәр язмасам, сезгә карата туган утлы хисләрем минем үземне яндырып көлгә әйләндерерләр дип куркам.

Рәисем! Болай дип, сезне үземнеке санап мөрәҗәгать итүем өчен ачуланмагыз. Чиксез күк йөзен бизәгән миллион йолдызлар арасыннан берсен, күңелемә ошаганын сайлап, «йолдызым!» дип әйтергә минем хакым бар бит. Йолдыз үзе моны белми икән — белмәсен. Ул мине барыбер үзенә ерактан карап рәхәтләнүдән, татлы-татлы хыялларга бирелүдән тыя алмый. Ә сез минем өчен ерактагы йолдыз гына түгел. Сез миңа якын. Бик якын! Сез мине белмисез. Ләкин бу миңа сезгә карап сокланырга, дөньяда сез барлыгын өзлексез тоеп торырга, кичләрен иң гүзәл шигырь урынына сезнең исемегезне кабатлап ятырга, «Рәисем» дип йокыга китәргә, төннәрен төшемдә күреп юанырга һәм иртә таң «Рәисем» дип күземне ачарга уңайсызламый. Әйе, бу дөнья миңа бары сез булганга күрә генә ямьле. Сез булмасагыз, минем өчен яшәүнең дә бернинди мәгънәсе булмас иде кебек. Кайчак үзем дә аптырыйм: дөньяда сез барлыгын белгәнгә кадәр мин ничек яшәдем икән? Күрәсең, бик бала булганмындыр. Бөтенләй сабый булганмындыр.

Ни өчен соң сез минем йөрәгемдә шул тикле кадерле урын алдыгыз икән? Мин моңа үзем дә җавап бирә алмыйм. Минем сезне «матур» дип, «матур булган өчен яратам» дип, кимсетәсем килми. Һәркем аңлый торган мәгънәдәге «матур» сүзе сезне мин күргәнчә сыйфатлау өчен бик көчсез. Шулай ук «яратам» сүзе дә минем сезгә булган тойгыларымны аңлату өчен җитми.

Юк, мин сезне киенеп-ясанып бакчага чыккан яки театрга барган чагыгызда гына күргән һәм, китаптагыча, бер күрүдән гашыйк булып акылын җуйган кыз түгел. Минем сезнең тышкы һәм эчке матурлыкларыгызны гына түгел, күпләр карамагында бик ямьсез дип йөртелә торган якларыгызны да күргәнем бар. Мин сезнең әле мәктәптә укып йөргән чагыгызда бик күп «икеле» билгесе алуыгызны да беләм. Шуның өчен сезне мәктәптә булсын, өегездә булсын, күпме битәрләгәннәрдер. Ә сезнең үзегезнең бу хәлгә бер дә артык исегез китмәве мине шатландыра гына иде.

Тугызынчыда укыган чагыгызда сез, классташ иптәшегез Галимов дигән малай белән бергә, милициягә эләктегез. Сезне караңгы төндә Школьный белән Бутлеров арасындагы проходной ишек алды аркылы узып баручы бер ялгыз хатынга һөҗүм итүдә гаепләделәр. Һәм ул гаепләү юкка түгел иде. Сез бит чынлап та ул хатынны куркытып, аның кулыннан ридикюлен тартып алган идегез. Ул вакытта бу турыда белгән яки ишеткән кешеләр сезнең бу шуклыгыгызны коточкыч җинаятькә санадылар. Ә минем өчен сез әз генә дә кадерегезне югалтмадыгыз. Йөрәгемнең түреннән төшмәдегез. Мин бары тик сезнең язмышыгыз өчен борчылдым гына. Сезне кулга алырлар, каты хөкем итәрләр, чын-чынлап күңелләре бозылган кешеләр арасына кертеп, әллә кайларга алып китәрләр, мин исә, сезне үзегезгә сиздерми генә булса да һаман күреп, сезнең ягымлылыгыгызны тоеп тору бәхетеннән мәхрүм булырмын дип курыккан идем. Бәхеткә каршы, ул вакытта сезне әтиегез йолып алды. Дөрес, үзенең фән каршында, халык каршында булган дәрәҗәсен үз семьясы интересы өчен файдалануы белән ул, бәлки сезнекенә караганда зуррак җинаять эшләгәндер. Ләкин шулай да мин аны гаепләмәдем, бәлки, мин хаксыздыр. Бәлки миңа шәхси интересым, ягъни сезгә булган мәхәббәтем гаделсезлекне күрмәскә кушкандыр. Ни булса да, ул вакытта мин сезнең әтиегезгә күңелемнән

рәхмәт укыдым. Ләкин беләм. Сез үзегез бу эш өчен әтиегезгә рәхмәт әйтмәдегез. Хәтта сезнең ана карата болай да барлы-юклы гына булган хөрмәтегез шул вакыйгадан соң тагын да кимеде. Әниегезне исә, сез бөтенләй яратмыйсыз.

Мин сезне аңлыйм. Чөнки...

Ай, ул әтиләр! Ай, ул әниләр!..

Кайда инде ул безгә алар артыннан житү! Алар бит бала чакларыннан кара ипинең тәмен белеп үскән кешеләр. Манный боткасы деликатес булган алар өчен. Безнең яшьтә чакта алар шундый коммун йөрәкле, шундый югары идеяле, сверхсознательный гражданин булганнар. Нинди генә матур нужалар күрмәгән алар: ачлык дисеңме? Ниндидер ипи карточкалары дисеңме! Ниндидер промтовар талоннары дисеңме? Сугыш афәтләре... Ягылмаган өйләрдә тору... Аларда, әлбәттә, тар чалбарлар киеп фарсит иту кайгысы булмаган... Ә хәзер, заманалар рәтләнгәч, калган гомерләрен типтереп уздырырга тырышалар икән, аларның моңа хаклары юкмыни? Хәтта кайчак арттырып та жибәрәләр икән, берни түгел, төрле жаваплы урыннарда, сәүдә органнарында аларның үзләре белән бергә нужа күреп үскән кордашлары утыра, аларга яңа квартираның да зуррагын, шәбрәген алырга, кием-салым яки мебельнең иң дефицитлыларын эләктерергә мөмкинлек бирә икән, алар гафу ителәә. Бәйрәм саен гына түгел, өйдәгеләрдән берәрсенең туган көне килгән саен үзара кунакка чакырышып, кысташа-кысташа аракы эчеп, тышкы кыяфәтләре һәм телләре белән игътибар итмәгән булып кыланса лар да, күңелләреннән байлыклары белән мактанышып яки берсенекеннән берсе көнләшеп утыралар икән, анда кемнең ни эше бар? Совет илен ныгыту һәм аны дошманнардан саклау юлында үз гомерләрендә шулкадәр күп газаплар чиккән, авырлыклар кичергән, корбаннар биргән кешеләрнең бер көн килеп, жиңү шатлыкларын татырга, дус-ишләре белән жыелып, үзара күңел ачып утырырга хаклары юкмыни?

Үз кордашлары белән ярышып, комсызланып жыйган байлыкларыннан, волейбол площадкасы зурлыгы итеп, стеналарына элеп куелган коверларыннан, обязательно чит ил маркасы сугылган мебельләреннән, патша бүләкләрен хәтерләтерлек аллы-гөлле сервизләреннән яки велюрдан да капроннан, нейлоннан да перлоннан беткән кием-салымнарыннан мещанлык исе аңкый икән, зарар юк. Аларга гафу итеlә. Алар бит күбрәк үзләре турында түгел, балалары турында кайгырталар.

Үзләре фәкыйрьлектә, нужада үскәч тә житәр. Балалары авырлык күрмәсен...

Менә бит ничек! Ә син, Рәис, жүләр малай, шуның кадерен белмисең. Әлекке квартирагызда чакта күршегез Игорьларның яки ниндидер Гамирларның, семьялары зур булуга карамастан, кечкенә бер бүлмәдә яшәүләренә, өстәвенә, кухня урынына да шул ук бүлмәдән файдалануларына, суны әллә кайдан — ерактан ташуларына, хәтта ашауэчүләре дә күбесенчә кара ипи белән бәрәңгедән ары китмәгәнгә эчен поша иде. Тиле син. Аларның әтиләре укымаган икән, үзләре гаепле. Алар да бит, синең әтиләрең шикелле, совет илендә яшиләр. Шунда үскәннәр. Аларга да бит бөтен ишекләр ачык булган, нигә укымаганнар!.. Ха-ха-ха!..

Ой, гафу итегез, зинһар, мин әллә нинди кирәкмәс ирониялэргә кереп киттем, ахрысы. Хәер, бәлки кирәктер дә. Ә бәлки минем бу хатым үзе башыннан ахырына кадәр кирәксез сүзләрдән гыйбарәттер.

Рәисем!

Әйтәсе килгәнем шул: сез нинди хәлдә булсагыз да минем өчен иң

кадерле кеше. Сезнең исерткеч эчеп, авыр хәлләргә төшкән, төрле кыяфәтләргә кергән чакларыгыз да минем өчен сер түгел. Мисал өчен берсен генә исегезгә төшерим. Сентябрьнең уноче иде. Төнге сәгать беренче яртылар тирәсендә сез Черек күл бакчасындагы бер эскәмиядә бөтенләй аңыгызны җуйган хәлдә ята идегез. Ул кичне үзегез белән бергә күңел ачып утырган иптәшләрегез сезне ни өчен шул хәлдә ташлап киткәннәрдер, белмим! (Рәиснең иптәшләре булгач, мин аларны да начар кешеләр икән дип әйтергә ашыкмыйм.) Сезне вытрезвительгә (гафу итегез, Казанда шундый урын барлыгын белүем өчен дә мин сезгә бурычлы), әйе, сезне вытрезвительгә алып китәселәр иде. Мин алып калдым. Хәзер үзем дә белмим, андый кыюлык миңа кайдан килгәндер. Ләкин бу чын дөреслек. Һәм сезнең шундый ярдәмчесез хәлдә калуыгыз турында автомат-телефон аша өегезгә хәбәр итүче кеше дә мин идем.

Сез тагы мине «шундый хезмәт күрсәтүем өчен сез миңа бурычлы» дип әйтергә тели дип уйлый күрмәгез. Һич юк. Чөнки мин ул батырлыгым өчен дөнья бәясенә торырлык бүләк алдым инде: сезне ике як битегездән дә үбеп киттем.

Ах, Рәисем! Сезнең нинди хәлгә төшкән чагыгызда да минем өчен тиңсез кадерле кеше булып калуыгызны исбат итү өчен, сезнең турыда бар белгәннәремне дә санап китсәм, алар хатка гына сыймас иде. Язган кадәресен дә укып чыга алырсызмы икән әле. Һәрхәлдә, мин хәзер хисләрем кысуыннан бераз бушанып, җиңеләеп калгандай булдым.

Бу хат бик каты ачуыгызны китерсә, гафу итегез. Мин бит сездән берни дә таләп итмим. Тик сүз азагында шуны гына әйтәсем килә: минем кем булуымны белергә теләп, баш ватмагыз. Барыбер белә алмассыз. Эзләсәгез дә, моңарчы үзегезгә таныш булган кызлар арасыннан эзләмәгез. Ихтимал, сез мине бервакыт күрерсез, бәлки танышырсыз да. Яки башка берәүне күреп, бу хатны язучы кеше шул түгел микән дип шикләнгән чагыгыз булыр. Тик, зинһар, бу турыда берәүгә дә әйтмәгез. Хәтта сезгә минем үземне күреп сорарга туры килсә дә дөрес җавап ала алмассыз. Әгәр дә мин язганлыкны сезнең бервакыт белү ихтималыгыз булса, мин аны язмаган да булыр идем. Әйе, сез мине белмисез. Мин сезгә таныш булмаган меңнәрнең берсе.

Ә мин сезне ничек бу кадәр якыннан беләм соң? Сездә, әлбәттә, шундый сорау тууы мөмкин. Ләкин мин бу сорауга ничек дип җавап бирергә белмим. Шуны гына әйтә алам: миңа мәхәббәтем булыша булса кирәк. Бәлки мин тирә-ягымдагы башка бик күп кешеләрне, башка бик күп вакыйгаларны игътибарсыз үткәрү хисабына сезне өзлексез күреп, тоеп, белеп тора торганмындыр. Кайчакларда мин сезнең хакта күңелем белән генә сизгән хәлләрнең чынлап та булганлыгын белеп, үзем хәйран калам. Кайчак миңа күргән төшем дә ярдәм итә. Мин динле түгел. Мистикага ышанмыйм. Ләкин менә төш турында Павлов аңлатмалары гына мине канәгатьләндерми. Минемчә, бу мәсьәләдә дә әлегә фән ачып җиткерә алмаган серләр булырга тиеш.

Ой, мин тагы акыл сата башладым, ахрысы. Сау булыгыз, Рәисем, исән булыгыз! Сезне яратучылар, өзелеп сөючеләр, әлбәттә, күптер. Ләкин белегез, дөньяда менә шушы Казан каласында сезне бар кешедән артык күреп, хәтта үзенең тормышыннан артык күреп яратучы, сезнең өчен кирәк булса, бөтен мәхрүмлекләргә барырга әзер торучы берәү бар. Моны белү сезне куандырырмы, борчуга салырмы, ачуландырырмы — ул турыда уйламыйм. Бәлки минем йөрәгемнән ташып чыккан бу сүзләр сезнең бер колагыгыздан кереп, икенче колагыгыздан чыгып китәр. Анысы сезнең эш. Тормышта иң югары максатыгызга ирешүегезне теләп калам».

## 5

Рәис, хатны укып бетергәч, берникадәр вакыт онытылып торды. Күңеленнән генә аның соңгы сүзләрен кабатлап куйды. «Иң югары максатыгызга ирешүегезне телəп калам»!.. Аннары ул бик зур хата эшләп ташлаган кеше сыман кинәт куркынып, айнып киткәндәй булды. Һәм шунда гына үзенең әле һаман да почта бинасы эчендә, стенага терәп ясалган биек өстәлләрнең берсенә сөялгән хәлдә торганлыгын аңлап алды. Залда электр яктысы балкый иде инде. Ашыгып ишеккә таба борылуга аның күзенә әлеге элемтәчеләр киемендәге кыз күренде. Ул Рәискә таба борылып, мәгънәле генә елмаеп куйды һәм шунда ук ялт итеп чыгып та китте.

Ник алай елмайды ул кыз? Димәк, ул Рәиснең ничек онытылып хат укыганын күреп, карап торган? Әллә бу сәер хатны язучы билгесез кыз шушы үземе?

Күңеленә мондый сорау килгәч, Рәис тагын да ныграк айный төшкәндәй булды. Үземе — түгелме, ләкин кем булса да, аның хәзер чынлап та Рәисне күреп торуы мөмкин...

Егет, үзе дә сизмәстән, гәүдәсен турайта төште, пальтосы белән эшләпәсен төзәткәләп куйды. Һәм беркемгә дә исе китмәгән вәкарьле йөреш белән ишеккә таба атлады. Урамда инде караңгы төшеп килә, ләкин күк йөзе якты, аяз иде. Рәис, уңга борылып, университет ягына таба берничә адым атлагач, үзалдына үзе: «Ерунда!» дип куйды. Шунда ук, күңелендәген болай кычкырып әйтүеннән уңайсызланып, артына борылып карады. Шикләндерерлек берни дә юк иде.

— Конешно, ерунда, — диде Рәис тагын. — Чепуха. Вздор...

Ул шулай теге имзасыз хатны онытырга, күңеленнән чыгарып ташлап, аның белән бөтенләй исәпләшмәскә, тормышында әүвәлгечә гамьсез булып калырга теләде. Адымын бераз акрынайтып, башын күтәрә төште һәм Бибиси тапшыруларыннан отып алган бер җиңел көйгә сызгырып бара башлады. Ләкин пожарниклар чатына килеп җиткәндә, ул сызгыруыннан туктаган иде инде. Ничектер үз ихтыярыннан тыш аның хәтеренә малай чагында ук ишеткән бер вакыйга килеп төште.Ниндидер учреждениедә машинистка булып эшләүче бер кыз турында сөйләгәннәр иде. Күптән үлгән әнисен төшендә күргән, имеш. Әнисе аны ялынып-ялынып үз янына чакыра, ди. Ә теге кыз, үзенең төш күрүен сизенеп, курка икән. Төштә үлгән кеше янына барсаң, аны яхшыга юрамыйлар, үзең дә үләсең, имеш, дип шикләнә, шуңа күрә әнисе янына барырга һич ризалык бирми икән. Шуннан аңа әнисе: «Ярый алайса, кызым, минем яныма килергә теләмәсәң, иртәгә көндез, нәкъ сәгать уникe утызда пожарниклар чатына кил», дигән. Кыз шунда уянып киткән. Эшләгән урынына килгәч, иптәшләренә сөйләгән бу моны. Иптәшләре дә кызыксынып киткән.

— Чынлап та барып кара әле син ул пожарниклар чатына, — дигәннәр тегеңәр, — нәкъ безнең көндезге ялга туктаган вакытка туры килә ич. Берни югалтмыйсың, — дигәннәр. Кыз киткән пожарниклар чатына, нәкъ менә шунда, әле Рәис узып барган җиргә килгән. Уникe утыз туларга ничә минут калганлыгын белергә теләп, Кремль сәгатенә карамакчы булган. Ачыграк күрү өчен, аны-моны уйламастан, урамның уртасынарак кергән. Нәкъ шул минутта икенче чаттан кызу гына борылып бер машина килеп чыккан да, кызны бәреп тә еккан, таптап та узган. Икенче көнне мескенне әнисе янына илтеп куйганнар.

— Әллә бу хәбәр чынлап та дөрес иде микән? — дип уйлады Рәис.— Төш күрү мәсьәләсендә чынлап та әлегә фән ачып җиткерә алмаган серләр булса, гаҗәпмени!..

Шулай итеп, ул, уйлары белән янадан әлеге хат эченә әйләнеп кайтканын сизми дә калды. Лобачевский урамы белән төшеп, Черек

күл бакчасы янына килеп чыккач, ул ана тагын да тирәнрәк кереп батты. Әйтерсең ул хат, бөкләп-бөкләп конверт эчендә тыгылган хәлдә куен кесәсендә яткан жиреннән, яшерен генә тавыш белән һаман аның колагына пышылдый: «Мин ул батырлыгым өчен дөнья бәясенә торырлык бүләк алдым: сезне ике як битегездән дә үбеп киттем...»

Хәзер инде Рәискә урамда очраган һәр кыз серле булып күренә башлады:

«Нигә бу кызыл беретлы кыз аңа болай туры карап узды? Әллә булмаса шул үземе?» Яки: «Бу одуванчик мине күргәч ничектер уңайсызланды бугай бит, нигәдер оялды. Хәтта абынып та китте. Бер дә юкка гына алай булыр микән?» Яки: «Нигә бу шәмәхә эшләпә миңа бөтенләй игътибар итми үтеп киткән булды соң? Әллә шул микән? Мин сизмәсен дип, юри шулай гамьсез күренгән буламы?»

Ләкин ул кызыл беретлар, шәмәхә эшләпәләр яки одуванчиклар үтеп киттеләр дә онытылдылар. Ә менә берсе...

Рәис Ленин бакчасы аша кыеклап узып, Горький урамы чатына килеп чыгуга, бөтен жирдә гөлт итеп электр лампалары кабынып китте. Егет моңа артык игътибар итмәде, ике яктан да очынып килгән машиналарга кадәр өлгерү өчен урам аркылы йөгереп узды да, Муса Җәлил исемендәге опера театры бинасы буйлап акрын гына югары таба атлады. Әнә шунда аның күзләре каршыдан килүче бер кызга төште. Башында хәзерге яшьләрдә сирәк очрый торган киң кырыйлы салам эшләпә иде аның. Ә өстендә, куян мамыгыннан калын итеп, күпертеп бәйләнгән, жылы һәм йомшак икәнлеге әллә кайдан күренеп торган ап-ак кофта иде. Рәис шуннан башкасын күреп өлгермәде, кызның йөзе аның игътибарын җәлеп итте. Ул Рәискә нидер әйтергә әзерләнгәндәй, ерактан ук аңа туры карап килде дә, якыная төшкәч, адымнарын акрынайтты һәм Рәистән күзен алмаган хәлдә оялчан елмаеп куйды. Егет ихтыярсыз тукталып калды.

— Гафу итегез, — диде кыз, оялчанлыгын жиңеп. — Миңа Щапов урамы кирәк иде, әйтә алмассызмы?

Рәискә шунда әллә ни булды. Кая китте соң аның гадәттәге шуклыгы? Таныш түгел кызлар белән очрашкандагы шаян тапкырлыгы кая югалды? Башка вакытта булса ул, әлбәттә, бу кызны бераз шаяртмый калмас иде.

Нәрсә өләшәләр ул Щапов урамында? дигән булып, мине дә алып барсагыз, өйрәтәм, дигән булып, аптыратып бетерер иде. Яки алай гына да калмас, әйтегез әле, зинһар, бу матур эшләпәне кайдан таптыгыз? Миңа да кирәк иде, әбиемнең туган көненә бүләк табалмый йөрим, әллә миңа сатасызмы? дип мыскыл итәргә керешер һәм кызны тәмам ачуландырып житкергәч кенә аның соравына кирәкле җавапны бирер һәм, кызның бәхиллеген алу өчен, матурланып елмаер иде.

Ул әле дә елмайды. Ләкин бу каушаган кешегә хас оялчан елмаю иде. Йөзенең кызаруын үзе дә сизгән хәлдә, ул мөмкин кадәр ягымлы һәм акыллы күренергә тырышып, кызга Щапов урамына ничек барырга кирәклеген әйтеп бирде.

Егетнен үзен тыныч тота алмавы кызны да әллә нишләтеп, кабындырып жибәрде. Ул Рәискә караганда да күбрәк кызарды, аңа чын күңеленнән рәхмәт әйтте һәм искиткеч нәфис, шуның белән бергә ниндидер серле елмаю бүләк итеп, үз юлына китте. Рәис, барасы юлын оныткандай, баскан урыныннан кузгалмыйча аның артыннан карап калды. Тик шунда гына ул кызның эшләпә астыннан чыгып, биленә житеп торган толымнары да барлыгын күрде: очларын төенләмичә, тасмасыз гына үреп салынган калын-калын ике коңгырт толым!..

Башкасына игътибар итмәде егет. Әгәр дә ул аның киемнәренә игътибар итеп караган булса, кызның тез тиңентен итеп тегелгән кара

юбкадан һәм гади ефәк оек өстеннән кигән микропор табанлы, уртача гына үкчәле көрән туфлидән икәнен күрер иде. Юк, ул аларына игътибар итмәде һәм гомумән бу кыз үз яшьтәшләре арасында модадан калыша икән дигән уй аның күңеленә дә килмәде. Хәтта ул аның кашлары ни төстә, авыз-борыннары нинди булуын да абайлап өлгермәде, ниндидер нәфис, җанга ягымлы, ышанычлы саф елмаю калды аның күңелендә һәм әнә шул әле һаман аермачык күренеп баручы ике зур толым... Өстәвенә тагын кызның, һәр селкенүе белән күңелне җилкендереп, җиңел-җиңел атлап баруы...

Әнә ул Горький урамына барып җитте дә ялт итеп артына борылып карады һәм, Рәисне күргәч, тагы елмайды. Рәис монысын көтмәгән иде. Ул тагы бер тапкыр үзенең гаепле кеше кебек кызарганлыгын тойды. Кыз тукталып тормады, трамвай юлын кисеп, каршы якка чыга башлады. Рәис һаман аңардан күзен алмый, урамны чыгып җиткәч, ул тагы бер борылып карар, дип өмет итә иде. Һәм аны өмете алдамады: серле кыз, чаттагы саклык кассасы ишеге турысына барып җиткәч, тагы Рәискә борылды. Бу юлы инде егет таркалып калмады, кызга озату сәламе җибәреп, кулын селекте. Кыз аңа тагын бер тапкыр елмаю белән җавап бирде һәм шунда ук Горький урамына кереп күздән югалды.

Рәис, кыз китеп югалган чатка тагын берникадәр вакыт карап торганнан соң, ашыкмыйча гына үз юлына борылды.

— Мөгаен, шул үзе, — дип уйлады ул, ләкин аңа мактап та, яманлап та бәя бирергә ашыкмады. Тик бик үк ачык төстә булмаса да, шуны тойды: кыз аның күңелендә җанга рәхәтлек бирә торган бер якты, җылы эз калдырып китте.

6

Камилә ул көнне Рәисне бөтенләй кунарга кайтмас, кайтса да төн урталарына калыр дип борчылган иде. Ун сумны яхшы ният белән сорап аламыни ул! Соңга калуы бер хәл, эштән чыгарып, исертеп кайтармасалар гына ярар иде инде. Әллә нинди бәла-казаларга очрап бетмәсә ярар иде тагы. Уф, бәхетсез ана, бүген дә йокысы йокы булмас инде...

Ләкин, гаҗәпкә каршы, Рәис кичке сигез дә тулмастан бик әйбәт кенә кайтып керде дә, беркая чыкмады, ике-өч тапкыр телефон шалтыратып чакырдылар үзен, бармады. Кемнәрдер үзен сүгеп, янап та карадылар, ахрысы, ләкин малай үз сүзендә торды. Өйдә утырган чакларында радиоалгычтан төрле чит ил тапшыруларын эзләп, үзенчә әйбәт, кызыклы тапкан инглиз җырларын магнитофонга язып алырга ярата торган гадәте бар иде. Бүген алар белән дә мавыкмады. Беркем белән дә сөйләшмичә, үз бүлмәсендә китаплар актарып, газета-журналлар карап утырды.

Иртән йокысыннан торгач, күптән ташлаган гадәтен искә төшерде: бер дә иренмичә, бөтен шартын китереп, физзарядка ясады. Аннары тагы үз бүлмәсендә көне буенча укынып-язынып утырды. Тик әнисенә шунда ник бер сүз дәшсен!

Кичкә таба ул каядыр җыена башлады. Камиләнең аңардан: «Кая җыенасың, улым?» дип сорыйсы бик килсә дә, авыз ачып сүз дәшәргә кыймый, тупас җавап ишетермен дә, йөрәгем бозылыр дип курка иде. Рәис дәшмичә генә киенде, дәшмичә генә ишеккә атлады. Шулай да нәрсәдер аңа тәэсир итте ахрысы, ул, әнисенең күңелендә янган гаҗәплы сорауга бөтенләй җавап бирмичә чыгып китәргә көче җитмәгәндәй, бер генә секундка тукталып калды, әнисенә борылып карамыйча гына гадәттәге ачулы тавыш белән мыгырдап куйды:

— Мин бокска киттем.

*Илдар Юзеев*

# ТЫНЛЫК БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

I

БАЛА

Кемдер бераү, әллә кеше,
Әллә инде төн җиле
Тәрәзәмә кагылды да
Уятып китте мине.
Кем йөри төн уртасында?
Бар табигать йоклаган...

ҖИР-АНА

Мин чакырдым сине монда,
Һич йоклый алмыйм, балам.

БАЛА

Берни дә юк. Тирә-як тын.
Нигә уяттың, анам?

ҖИР-АНА

Әллә ни булыр шикелле,
Йокың сак түгел, балам,
Яман-ямьсез төшләр күрәм,
Төнен мин ялгыз һаман.

БАЛА

Әллә нинди гамьсез бер уй
Күңелемә үрмәли.
Йокла тыныч, дөнья тыныч,
Кайгы эзләп йөрмә, ди.

ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК

Мин килдем сине алырга
Гамьсезлек дөньясына.
Батарсың, чыга алмассың,
Кермә уй дәрьясына.
Ник сиңа ятлар кайгысы,
Өеңә кер дә биклән.
Үз кайгың, үз шатлыкларың,
Үз үең белән чиклән...

БАЛА

Таңда юлга чыгасым бар,
Киттем мин, йокым кала.

ҖИР-АНА

Анаң күкрәгенә ятып,
Йөрәген тыңлап кара...
Нәрсәдер тоеп, сизенеп
Борчылам, уттай янам...

БАЛА

Синдә тынлык хөкем сөрә,
Юкка борчылма, анам.

ҖИР-АНА

Миңа берни дә кирәкми,
Хәлем бел, юат кына...

БАЛА

Ул-бу була калса әгәр,
Син мине үят кына...
Узган авыр елларыңны
Онытырга тырыш, ана.
Яраларың да төзәлгән,
Инде тынычлансана.

ҖИР-АНА

Әй бала, бала, бала...
Ул шомлы тынлык белән син
Ялгызың калып кара.

БАЛА

Кояш баешы ягыннан
Тын, уйчан җилләр исте.
Шул якларда ятып калган
Туганнар искә төште...

ҖИР-АНА

Оныта алмыйм июнь төнен,
Нәкъ шундый бер тән иде.
Күк зәңгәр... Дөнья тын иде.
Җиле анырттын иде.
Шул төнне бит иң дәһшәтле
Сугышның таңы атты.
Шул төнне бит туганыңның
Кояшы мәңге батты.
Үләр алдыннан бер минут
Ул күккә карап ятты.
Өзгәләнде: «Әле генә
Дөнья нинди тын иде...»
Талпынды нидер әйтергә,
Ләкин... соң иде.

ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК

Ку күңелеңнән ул минутны,
Уйлама, оныт кына.

БЕР МИНУТ ТЫНЛЫК

Күңеленңдә булырмын мин
Бары бер минут кына.
Килдем мәңгелек тынлыктан
Бер минут булып кына.
Җир куенында калганнардан
Мин — соңгы ядкарь булам.
Толларның һәм ятимнәрнең
Керфекләренә кунам.
Мин килсәм — бар да тыналар,
Башларын түбән иеп,
Урыннарыннан торалар:
«Бер минут тынлык...» — диеп.
Чакырсалар — бик тиз киләм,
Кусалар — китә беләм.
Насыйп булмас, ахры, миңа
Очрашу шатлык белән.
Йөрим Җир-ана буйлатып,
Уйсызларны уйлатып,
Таш бәгырьләрне елатып,
Гамьсезләрне уятып.
Мәңгегә тынлык күрмәгән
Җир-ана әле дә түзем.
Хәсрәтенең тик беразын
Күтәрче, бала, үзең.

БАЛА

Берни дә күрмим, ишетмим,
Җир һәм Галәм кап-кара.

БЕР МИНУТ ТЫНЛЫК

Анаң күкрәгенә ятып,
Йөрәген тыңлап кара.

БАЛА

Әллә кайда, бик еракта
Шартлау ишетелгән сыман?..

ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК

Тыңлама гына син аны,
Ул ерак, ерак моннан.

БАЛА

Әллә җил китерә инде
Янгын, көл, төтен исен?

ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК

Җил белән үтәр дә китәр,
Җирдә ни булмас дисең...

БАЛА

Таре тагып, барабан кагып
Солдатлар атлый төсле,
Итекләре Җир-анамның
Күкрәген таптый төсле.
Әллә инде Җир-анамның
Йөрәге дөп-дөп тибә,
Әллә инде шул шаулалар
Дөп-дөп-дөп... атлап килә?

ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК

Син ишетмә, күрмә генә,
Ташла дөнья кайгысын,
Җир-ананың миллион-миллиард
Балалары кайгырсын...

БАЛА

Күрмә, күз, ишетмә, колак,
Ул ерак әле, ерак...

ҖИР-АНА

Әй бала, бала, бала...

ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК

Ана ул гел шәфкать сорый,
Карама ла син аңа...

БАЛА

Күрмә, күз, борчылма, йөрәк,
Ул ерак моннан, ерак...

БЕР МИНУТ ТЫНЛЫК

Әллә оныттың да инде
Тып-тын курганнар барын,
Җир-әнкәңнең куенында
Күпме корбаннар барын...

ҖИР-АНА

Улларым, балаларым...
Тик үзем генә беләм мин
Күпме улларым барын...

БАЛА

Җыр тавышы килә сыман
Тирәннән, җир түреннән...

ҖИР-АНА

Алар һаман җырлап уза
Аналар күңеленнән...

БАЛАЛАР ҖЫРЫ

Әй аналар, карагыз,
Кайтып килә балагыз,
Тик өйләргә керәлмибез,
Узып кына барабыз.
Җир-ананы сакладык,
Җанны биреп якладык,
Бер минутка гына кайттык,
Бөтенләйгә кайтмадык.
Таң җилендә җилфердимә
Зәңгәр ефәк яулыгың?
Нигә офтанасың, әнкәм,
Әллә юкмы саулыгың?..
Әнкәемнең иңнәрендә
Әллә кара шәл инде?..
Яннарыңа керә алмыйм,
Белә алмыйм хәлеңне.

БАЛА

Моңача ничек күрмәдем,
Мин кара шәлең күрәм?..

ҖИР-АНА

Улларым-бәгырьләремә,
Улларым каберләренә
Куярга венок үрәм.

ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК

Нигә искә төшерүләр?..
Онытырга вакыт инде.
Җырлар гына кире кайта,
Узганнар кайтмый кире.

ҖИР-АНА

Күпме улларны тынлыкка —
Мәңгелеккә озаттым,
Иң йомшак һәм иң мөкатдәс
Туфрагым белән яптым.

БЕР МИНУТ ТЫНЛЫК

Менә мин синең яныңа
Бер минут булып кайттым.
Әйт, ана, син ул тиранны
Җир йөзенә ник таптың?!

### АНА

Ник таптым да ник бактым?!
. . . . . . . . . . .
Мин аны көткән чагымда
«Бер кеше туар», — дидем.
Тиран буласын белсәмче...
Мин аны буар идем.
Күкрәгемне телә һаман
Мәңге төзәлмәс ярам,
Аны баккан көннәрем һәм
Төннәрем булсын харам!

### ЭФИРДАН ТАВЫШ

*Бөтен җир шарын басып алырга хыялланган гитлерчы фашистлар дөнья сугышын башлап җибәрделәр.*

### БЕР МИНУТ ТЫНЛЫК

Җир йөзенә калыкты да
Ул кулын алга сузды,
Фашист явы Җир-ананың
Күкрәген таптап узды.
Аларның узган юлында
Кан иде дә күл иде.
Ул тиранны туктатырга
Мөмкинме? Мөмкин иде!
Ах син, Кеше, Җиргә басып
Нигә бер сүз катмадың?
Нигә бер сүз катмадың да
Ник аны туктатмадың?!

### ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК ҺӘМ БАЛА

Ул чагында, ул чагында...
Ул бездән ерак иде.

### ҖИР-АНА

Минем йөрәгемә ятып
Тыңларга кирәк иде.

### ЭФИРДАН ТАВЫШ

*Икенче бөтендөнья сугышы җир шарына зур һәлакәт алып килде. Бу сугышта корбан булучыларның саны 50 млн. га җитә. Совет халкы 20 млн. кешесен югалтты.*

### ҖИР-АНА

Үтте тиран, китте тиран
Яндырып, таптап, талап,
Бер сынык икмәк сорыйлар
Сабыйлар күзгә карап.
Нәниләр салкын куеныма
Керә дә «җылыт!» диләр;
Ярый әле мәрхәмәтле
Уллары онытмыйлар.

АКЫЛ ИЯСЕ

Нинди ярдәм кирәк сиңа,
Мин тыңлыйм сине, анам?

ҖИР-АНА

Сабыйларым ач-ялангач,
Хәлләрем яман, балам...
Бер ягым — боз, бер ягым —
Бер туңам да бер янам.
Синнән көтмичә ярдәмне
Көтиммени алладан?..
Балаларны яшәтерлек,
Карт анаңны яшәртерлек
Бармы бер көч?

АКЫЛ ИЯСЕ

Бар, анам!
Мин эзлим аны күп еллар,
Мин эзлим аны, табам!

БИЛГЕСЕЗ ТЫНЛЫК

Еллар, сәгатьләр, минутлар
Исәбен югалттым мин,
Акыл ияce кулында
Тып-тын озак яттым мин.
Берзаман минем эчемә
Үтте дә ни тапты ул!
Мәңге тын яткан тылсымлы
Көчемне уятты ул.
Акыл ияce түзәлми,
Шатлыктан биеп китә...
«Җир-ана, Кеше, балалар,
Сезне зур бәхет көтә!!!»
Бик якын ич чүл яшәрер
Һәм бозлар эрер көннәр,
Айга, йолдызларга басып,
Күкләрдә йөрер көннәр.
Йолдызлар җиргә сокланып,
Күрешүне көтеп яна,
Сөенечтән Җир-ананың
Күзләреннән яшь тама.

ҖИР-АНА

Озын гомерле булырсыз,
Сез бәхетле, балалар...

АТОМ ТЫНЛЫГЫ

Мине — куркыныч тынлыкны
Кая алып баралар?..

ҖИР-АНА

Кил, бәхет, тыныч картлыгым
Хакына...

Күптән китәм.
Карлыгач булып килдеңмә?
Мин сине күптән көтәм.

### АТОМ ТЫНЛЫГЫ

Кетмә син мине, Җир-ана,
Күккә карамасана...

### ЭФИРДАН СОҢГЫ ХӘБӘР

*1945 елның 6 август иртәсендә Америка бомбардировщигы япон шәһәре Хиросимага беренче атом бомбасын ташлады. Шартлау нәтиҗәсендә 78150 кеше үлде, 13983 кеше хәбәрсез югалды, 9428 кеше авыр яраланды. Өч көннән соң Нагасаки шәһәре дә шул ук язмышка дучар булды.*

### АТОМ ТЫНЛЫГЫ

Күз ачып күз йомганчы
Ут эчендә калды җир,
Янды һава, янды шәһәр,
Янды кеше, янды җир.

### ҖИР-АНА

Мин сиңа ышанган идем,
Нишләттең мине, балам?!

### АКЫЛ ИЯСЕ

Белмәдем варвар икәнен,
Ах, мин алдандым, анам,
Мәңге-мәңге онытылмаслык
Мин сабак алдым, анам.

### ХИРОСИМА ТЫНЛЫГЫ

Җир-ананың күкрәк көчен
Кемнәр кулына бирдең?
Кемнәр кулына бирдең син?
Мин сорау белән килдем.
Хиросима тынлыгы мин.
Мин сорау белән килдем.
Ник, Кеше, гамьсез йокладың,
Юлларына чыкмадың,
Шул варварның бомба тоткан
Кулларына сукмадың?!

### ҖИР-АНА

Харабәләр арасында
Йөз меңләп балам калды.

### АКЫЛ ИЯСЕ

Күкрәгеңдә, күкрәгеңдә
Төзәлмәс яраң калды.
Ничекләр итеп төзәтим
Җир-әнкәнең ярасын?

БАЛА

Кара шәлеңне ябынып,
Әнкәм, кая барасың?

ҖИР-АНА

Һаман да ышанмыйм әле,
Һаман да өмет өзмим.
Хәрабәләр арасыннан
Балаларымны эзлим...
Балаларымны эзлим мин,
Балаларымны эзлим...
Каберләрен табалмадым,
Туфрак та салалмадым.

БАЛАЛАР ҖЫРЫ

Әнкәемнең иңнәрендә
Әллә кара шәл инде?..
Яннарыңа килә алмыйм,
Белә алмыйм хәлеңне.

БАЛА

Чәчләрең ап-ак икән ич,
Әнием,ниләр күрдең?

ҖИР-АНА

Хәрабәләр арасында
Балалар эзләп йөрдем.
Кайда сез, балаларым?
Мин сезне эзләп йөрдем...

ТЫНЛЫК

Хиросима тынлыгы мин.
Мин сорау белән килдем...

II

ҖИР-АНА

Шул көннән соң иңнәремдә
Гел кара шәлем йөртәм.
Күктәге зәңгәр тынлыкка
Карыйм да... хәсрәт кәтәм.
Берзаман баксам һавага —
Ишетәм... күктән тавыш.

КҮКТӘН ТАВЫШ

Бу мин, әни, ишетәсеңме?

ҖИР-АНА

Тавышы күптән таныш...

### БАЛА

Бер дә курыкма, әнием,
Син аны тыңлап кара.
Ул — башка Акыл иясе,
Сәламнәр юллап бара.

### ЭФИРДАН ТАВЫШ

*...Советлар Союзы территориясеннән «Восток» космик корабле җибәрелде! Космик корабль белән СССР гражданины идарә итә.*

### БАЛА

Бер дә сискәнмә, анакай,
Галәмдә барган егет —
Синең балаң — алып килә
Кояш чыгышы ягыннан,
Бәхет, Ышаныч, Өмет!

### ҖИР-АНА

Кем әйтер аны бала дип,
Кара син аны, кара,
Бишегеннән сикереп чыгып,
Йолдызга китеп бара.
Кем уйлаган?.. Әй, акыллым,
Үрлә, югары үрлә!
Карт көнендә әниеңне
Онытa гына күрмә...

### КҮКТӘН ТАВЫШ

Синнән гүзәл, синнән нурлы
Изге җирне тапмадым.
Сал, әнкәм, кара шәлеңне,
Ник йөзеңне капладың?

### БАЛАЛАР ҖЫРЫ

Әниемнең иңнәрендә
Әллә кара шәл инде?
Күккә менеп күрер идем,
Белер идем хәлеңне...

### КҮКТӘН ТАВЫШ

Бер дә шикләнмә, анакай,
Күр, нинди аяз күгең...
Бар галәмгә, бар дөньяга
Сүзләр әзәтам бүген:
Без ачкан ул Атом көче
Җимерү өчен түгел!
Җир-ана, синең исемеңне
Күккә язып калдырам,
Күр әнә, синдә шифалы,
Сүнмәс утлар яндырам.

### ЭФИРДАН СОҢГЫ ХӘБӘР

*...Советлар Союзында атом көченә нигезләнгән электростанция эшли.*

*...Дөньяда беренче тапкыр Советлар Союзында төзелгән «Ленин» исемендәге атом бозваткычы Төньяк диңгез юлына чираттагы рейска китте.*

### БАЛА

Дәвалар алып килә ул —
Төзәлер яраларың...

### БЕР МИНУТ ТЫНЛЫК

Төзәлсә дә яраларың,
Кайтмаслар балаларың.

### III

### ҖИР-АНА

Бер якта зәңгәр күгемне
Улларым саклап тора.
Бер ягымны кара-шомлы
Болытлар каплап тора...

### БАЛА

Каяндыр җил алып килә
Янгын, көл, төтен исен.

### ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК

Дәһшәтле көчне сыныйлар,
Китмәсен аңа исең...

### ХИРОСИМА ТЫНЛЫГЫ

Хиросима тынлыгы мин.
Мин беләм аның көчен...

### ЭФИРДАН СОҢГЫ ХӘБӘР

*Америка Кушма Штатлары Невада штатындагы полигонда атом-төш коралы шартлатты. Бу шартлауның хәрби әһәмияте бар.*

### ҖИР-АНА

Барысы да «Тыныч кына
Йокла...» дип юаталар.
Шул дәһшәтле көчләр мине
Йокымнан уяталар.

### ЭФИРДАН СОҢГЫ ХӘБӘР

*Башка дәүләтләрнең территорияләренә дәгъва иткән Көнбатыш Германия реваншистлары, киләчәктә үз планнарын тормышка ашыру өчен, атом-төш коралына ия булырга омтылалар.*

БАЛА

Әллә кайда ишетелә
Барабан тавышлары...

ТЫНЛЫК

Дөп-дөп-дөп басып киләләр
Тиранның варислары.

ҖИР-АНА

Шул ук... шул ук адымнары,
Сүзләре, маршлары.
Бераү, гел аңа охшатып,
Кулларын алга суза.
Балалар яткан иң изге
Туфракны таптап уза.

ЭФИРДАН СОҢГЫ ХӘБӘР

*АКШта, рәсми властьларның күз алдында, үзләрен «Гитлерның варислары» дип атаган фашист өерләре ачыктан-ачык җыелышлар үткәрәләр. Неонацистлар национал-социалистик хәрәкәтнең бөтен дөньяга таралуына исәп тоталар. Нацистлар партиясе Канада илендә дә бар. Аларның «юлбашчысы» турыдан-туры Германия Федератив Республикасы белән элемтә тота.*

ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК

Анаң күкрәгенә ятып,
Ник, бала, уйга калдың?

БАЛА

Кайдадыр янгын, янгын...

БЕР МИНУТ ТЫНЛЫК

Ах, ник алдарак килмәдең,
Ах, нигә соңга калдың?

ЭФИРДАН СОҢГЫ ХӘБӘР

*АКШ хәрби-һава көчләренең самолетлары Вьетнам шәһәрләрен һәм авылларын өзлексез бомбага тоталар.*

ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК

Күрмә син аны, ишетмә...

ҖИР-АНА

Сүндер ул утны ничек тә.

ТЫНЛЫК

Сабыйлар йоклый бишектә.

ҖИР-АНА

Сабыйлар йоклый бишектә.

ХИРОСИМА ТЫНЛЫГЫ

Кичекмә!

ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК

Анаң күкрәгенә ятып,
Ник, бала, уйга баттың?

БЕР МИНУТ ТЫНЛЫК

Мин менә синең яныңа
Бер минут булып кайттым.

ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК

Әнкаңнең чал чәчләренә
Карап ник башың идең?

ХИРОСИМА ТЫНЛЫГЫ

Хиросима тынлыгы мин.
Мин сорау белән килдем...

ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК

Анда синең ни катнашың,
Кайдадыр, имеш, янгын...

ҖИР-АНА

Нигә бер сүз дә әйтмисең,
Ник, балам, уйга калдың?

БАЛА

Күпне күргән күкрәгеңә
Башымны куйдым, анам.
Йөрәгеңнең тибешләрен
Ишеттем, тойдым, анам!

ҖИР-АНА

Аңласаң иде, балам...

БАЛА

И анам, чиксез газаплар,
Хәсрәтләр күргән анам,
Дөнья кайгысын иңеңдә
Күтәреп йөргән анам.

ҖИР-АНА

Аңласаң идә, балам...

БАЛА

Мин барам, шунда барам!

ҖИР-АНА

Аңладың мине, балам...

БАЛА

Мин барам, шунда барам,
Таң белән юлга чыгам.
«Сак йоклагыз, туганнар!» дип,
Бар дөньяга чаң сугам!

ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК

Нигә юкка чаң сугарга!
Төн тыныч, аяз күгең...

БАЛА

Кит күңелемнән, гамьсез тынлык,
Син миңа юлдаш түгел,
Анам бәхетен сакларга
Мин юлга чыгам бүген.

ГАМЬСЕЗ ТЫНЛЫК

Кусаң — әллә кайгырам мы,
Бик исем китмәс әле,
Мин барында бу дөньяда
Гамьсезләр бетмәс әле...

ҖИР-АНА

Кем килә ул? Таң нурында
Чәчләре җем-җем итә...

БАЛА

Ул килә мине алырга,
Әни, мине юл көтә.

АКЫЛ ИЯСЕ

Карт анам, синең балаңны
Таңда ерак юл көтә.

ҖИР-АНА

Ул китә? Кая китә?

АКЫЛ ИЯСЕ

Барча ул һәм кызларыңа
Ул синнән хәбәр илтә.
Юл ачык, егет, әзерлән...
Сине корабың көтә.

БАЛА

Миллионнар бәхетен сакларга
Ерак сәфәргә чыгам.
Җир-әнкәнең әманәтен
Улларына тапшырам.
Минә уяткан, уйлаткан
Балалар җырын алам.

ҖИР-АНА

Ак булсын юлың, балам!

БАЛАЛАР ҖЫРЫ

Нигә өфтанасың, әнкәм,
Әллә юкмы саулыгың?..

АКЫЛ ИЯСЕ

Ябын, әнкәм, алып төштем
Күкнең зәңгәр яулыгын.

ҖИР-АНА

Зәңгәр яулык белән ябам
Ап-ак чәчемнә, балам.

БАЛА

Әманәтеңне үтәрмен.
Син шикләнмә.

ҖИР-АНА

Ышанам!

БАЛА

Тыныч йокла, әни бәгырем.

ҖИР-АНА

Хәерле юл!

БАЛА

Хуш, анам!

ҖИР-АНА

Балаларның уяулыгы —
Аналарның саулыгы.

КҮКТӘН ТАВЫШ

Бар Галәмдә җилфердәсен
Җир-әнкәнең яулыгы!

## ЖИР-АНА

Тын калган өйләргә
Кагылып үтәм мин,
Җил булып киләм дә
Тәрәзә чиртәм мин:
Дәшегез, аналар:
Уянсын балалар!

Ак болыт шикелле
Тузгыган чәчләрем,
Калмаган күзләрдән
Тамарлык яшьләрем.
Хәсрәтле йөземне
Җыерчык каплаган,
Өстемдә никадәр
Бомбалар шартлаган.
Сиздермим, сызлыйлар
Йөрәктә яралар...
Белмиләр балалар,
Әйтмиләр аналар...
Әйтегез, аналар,
Белсеннәр балалар!

Яңадан уянган
Фашистлар уяулар,
Ни булыр яңадан
Кузгалса ул яулар?!
Дәшегез, аналар,
Уянсын балалар!

Сүзем бар аларга —
Кызларга, улларга:
«Дөньяның язмышы
Бит сезнең кулларда!»
Мин йөрим әйләнеп
Бар дөнья буйлатып,
Гамьсезне уятып,
Уйсызны уйлатып.
Дәшегез, аналар,
Уянсын балалар!

Миллиард ел яшәп
Тынгылык күрмәгән
Әнкәгез чакыра,
Ак болыт шикелле
Чәчләрем хакына...
Дәшегез, аналар,
Уянсын балалар!

1966.



# Яшьлегемне эзлим

*Әхсән Баянов* — *Лирик повесть*

## Башлаганчы...

Кеше туа, беренче кабат күзләрен ача.
Күзләренә күренгән һәрнәрсә — аның өчен ачыш. Шул ук зәңгәр күк, ай, кояш, йолдызлар, чирәм, урман, су — ачыш.
Кеше үсә.
Аңа мәхәббәт килә. Ул әйтә:
— Минем кебек беркем яратмаган!
Вакыт дигән нәрсә аңа алмашчы китерә. Аның улы әйтә:
— Минем кебек беркем яратмас!
Буыннар алышына. Һәркайсы кабатлый:

> **— Минем кебек беркем яратмаган!**
> **Минем кебек беркем яратмас!**

Ачышлар күбәя тора. Фәннәр очрашкан җирдә яңа фәннәр, хәрәкәт океанында табышмаклы яңа көчләр ургыла. Алар мәхәббәткә яңалык китерәләр.

Билгеле вакытны сайлап, заказ буенча туып булмый. Яшьлек тә, мәхәббәт тә үзе туры килгән чор һавасын сулап яши. Революция, реакция, сугыш, тынычлык — һәркайсы аларга үз эчтәлеген бирә, үз пичәтен суга. Тик ни генә булмасын, соңыннан һәркем бер үк ачышны ясый:

> **— Еллар алып китте яшьлегемне,**
> **Бәрабәргә акыл бирде.**
> **Алыгыз, Еллар, биргән акылыгызны,**
> **Кайтарыгыз**
> **Яшьлегемне кире!**

Әгәр кайтарсалар, мөгаен, мин аны башкачарак үткәрер идем...

Безнең яшьлек сугыштан соңгы җимерекләкләр һәм җәфалар белән сугышты.

Бүген бөтенләй башка дөнья, башка гадәтләр. Шулай да дөньяга яшьлекнең зәңгәр күзлеге аша караган, мәхәббәтләрен әзли генә башлаган яки таба алмаган бүгенге көн геройларына безне, әлбәттә, аңларга кирәк.

Ләкин бу язмаларда мин үземнән соңгы түгел, ә башлыча үземнән алда килгән буын белән сөйләшәм, аның да мине дөрес аңлавын телим, шул мәгънәдә кайбер сүзләр әйтмәкче булам.

Дусларыма:

Бу язмаларда эзлекле сюжет үсеше тапмасагыз, гаҗәпләнмәгез, монда — минем бары тик фикерләрем, уйларым, уйлануларым һәм мин аларны сезгә тапшырам, сезнең белән уртаклашам. Алар кайбер кануннарга туры килмәсәләр, моны тәртип ихтирам итмәүдән дип түгел, ә дөреслеккә мәхәббәтемнең зуррак булуыннан, дип белерсез.

Дошманыма:

Әфәндем! Син мине мемуар язарга керешкән диярсең. Юк. Һич тә. Мин монда авылдаш дустым Әнис Бадигин язмаларыннан файдаландым. Һәм, дөреслеккә зыян китермәү нияте белән, сөйләүне беренче затта калдырам. Тик дөресен әйтим, минем үз язмышым да шушында, бәлки минеке генә дә түгел... Уртак еллар, уртак хәлләр. Шулай бит инде ул, әйдә, күңелең булсын, белеп кал: мин монда үземнең дә гадәттә автобиографиягә керми кала торган, моңарчы беркемгә дә әйтелмәгән серләремне ачам, аларның вакыты житте... Ә менә син, әфәнде, моңдый үрнәккә иярә алмас идең, чөнки синең күңел — чамадан тыш тирән кое, анда жәй көне дә бозлар баткан була, аңа көн уртасында кояш, төн уртасында ай карый алмый. Тирәндәге бозларны яктыга, кояшка чыгарыр өчен азмы-күпме батырлык, ирлек кирәк ич.

Яшьлек юлдашларыма:

Сез үзегез хакында укыганда нинди тойгылар кичерерсез икән? Сезнең алда — мин җаваплы, хәтта бераз куркыбрак та карыйм. Әгәр минем белән килешергә теләмәсәгез?! Башта ук менә нәрсә әйтәм. Сезнең хакта да нәкъ чынлыктагыча язарга тырыштым мин. Ләкин, яза башлагач, кайбер урыннарда читкәрәк тайпылырга туры килә, фотограф төгәллегенә ирешү мөмкин түгел икән. Хәер, моның хаҗәте дә юк ич, художниклар шулай диләр. Аннары, ничек кенә хәтер яхшы дисәң дә, кайбер нәрсәләр бәлки онытылган, яки алар еллар үтү белән бераз төсмерләрен үзгәрткәннәрдер. Шуңа күрә, зуррак ялгышлыклар күрсәгез, төзәтү өчен миңа хат җибәрерсез, ихтимал. Сезгә мөнәсәбәтем исә, нәкъ шушында язылганча, монда хата шиксез юк, мин сезне нәкъ шул төстә күрдем.

Үлгәннәргә:

Алар дәгъвасын турыдан-туры вөждан үзе кабул итә.

**БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК**

Мәңгелек декорация — төнлә йолдызлар, ай, карангылык. Көндез — зәп-зәңгәр күк йөзе, кояш.

Мәңгелек сәхнә — жир өсте, кышын ак, жәйгелектә яшел.

Мәңгелек спектакль — драма, комедия, трагедия.

Кешеләр моны дөнья дип атыйлар, тормыш диләр.

Декорация бер үк.

Сәхнәдә бүген мин, үзем генә.

Узган юлларыма борылып карыйм: күптән түгел генә нәрсә кичердем — драмамы, комедияме?

Декорация бер үк. Ник алыштырмыйлар, кайда режиссер? Җавап бирмиләр. Тамашачы? Ул да эндәшми. Күрәсең, дөнья — режиссерсыз һәм тамашачысыз спектакль. Ләкин миңа кемдер салкын, ваемсыз, шәфкатьсез күзләре белән карап, күзәтеп торадыр кебек.

Бүген мин бер үзем... Чиксезлек белән, Галәм белән — күзгә-күз.

Йолдызлар белән сөйләшәм...

Кайчандыр үзем утырткан бакчада, шомырт куагы астында, аякла-

ры жиргә кагып ясалган агач кровать. Шул кроватьта таралып ятам. Сагышы да, рәхәте дә бергә.

Баш өстендә генә диярлек — урам якта — күпне күргән имән. Ул да йоклый алмый сымак, мин аның тирән сулышын, ухылдап куюын ишетәм. Кеше турында әйтү кайда, имәнгә дә бәрелми калмады тормыш.

Бер елны, мин бәләкәй чакта, урмандагы барлык имәннәргә көя төште. Җәй уртасында урманның яртысы кара янып чыкты. Безнең койма янындагы шушы карт агач та бу язмыштан читтә калмады, яшь-яшь яфракларын шундый ук яшел көяләр кузгә күренеп көйдерә, ашый башладылар. Имән — безнең әтине алыштырган кинәшчебез төсле, кызганабыз, афәттән саклап калырга тырышабыз. Ничек итеп? Балта белән сугабыз агачка... Көяләр коела. Искә төшкән саен, жай чыккан саен сугабыз; озын баручы олырак агайлардан кем тели — шул имәнне тагын да ныграк «дәвалап» китә... Балта түтәсе белән. Ниятләре бик изге югыйсә, ярдәм итәргә телиләр. Әмма озак та үтмәде, каерысы кубып, имән кәүсәсендә бүрек хәтле жәрәхәт барлыкка килде. Хәзер инде, әйтә алмыйм, көядәнме, әллә шул ярадանмы күбрәк жәфа чиккәндер имән. Менә бит кайчак изге ният белән нинди кызыклар да ясап куябыз без; уйланырсың шул, иптәш.

Каршыда әлеге имәннең сеңелләре, еламсыр каеннар монаеп торалар. Алар безне үзләренең шикәрле сулары белән күпме сыйлаганнар... Без салган яра эзләре алар тәнендә һаман калган әле. Әгәр без аларны балта белән чокып елатмаган булсак, алар безнең өчен шулай мәңге онытылмаслык булып калган булырлар идеме? Гажәп нәрсә бу — ләззәт һәм яра, мәхәббәт һәм хыянәт...

* * *

Туган жир. Аның нәрсә икәнлеге аерылгач беленә. Берәүләр аны тоташ яктылыктан торган көнлекләр рәвешендә күрсә, икенчеләре, ирексездән, ямансу күкселлек, бушлык итеп хәтерлиләр... Балалык, яшьлек еллары сугыш чорына туры килгән безнең буын кешеләре туган жир күренешләрен күз алдына иртәнге алсулык кыяфәтендә генә китерми торганнардыр. Кайда гына булмасын, кайчан гына булмасын, шул ерак хатирәләр ничектер көзге жил сыман кагылып, күңелне өшетеп узалар... Моңсу да, шатлыклы да әллә нинди бер хис йөрәкне сулкылдата... Әрнүе дә, ләззәте дә бергә. Туган жир син, ах, туган жир...

Яз көне, сары яфраклар, былтыргы үләннәр түшәген аралап, ямь-яшел үлән шыта... Аксыл гына, көчсез генә... Аны йолкып алу өчен шундый ук төстәге яшькелт-сары бибиләр дә әллә ни көч куймыйлар.

Чемченәләр:

— Пип-пип, пип-пип!

Табигать алардан курыкмый.

Алар жир матурлыгын арттыралар, тулыландыралар.

Язгы салкын жилләр, кыраулар да яшь үләннәр шавын туктата алмыйлар, жиргә яшеллекне чыгармаска, аны кап-кара хәлдә тотарга тырышсан да зәгыйфь кенә сабаклар барыбер бирешмәс, ишәер, барыбер ишәер иде. Яшел ташкын бөтен жир өстен күмеп шаулый. Бәбкә үләне шыта, умырзая калка, күке башы — зәңгәре һәм чия көрәне — шытып чыга, аксыргак баш тәртә, чәчәк бөреләре ярыла, тормыш янара... Нәкъ алар кебек үк аксым дөньясы да янара, ярала... ярала. Чебиләр, бәбкәләр кәгазь калынлыгы броняны тишеп, нәни томшыкларын чыгаралар... Шундый көннәрнең берендә син дә туган жир туфрагыннан шытып чыккансың. Кырау сукса да, үскәнсең... Янадан яфрак яргансың. Тапталсаң, янадан тураеп басkансың.

Шул килеш ятып калганнар да күп булды, билгеле.

Мин кайбер җырчыларны, композиторларны, шагыйрьләрне якыннан беләм. Алар туган җир һавасының бөтен авыруларга дәва икәнен әйтәләр, мина бернинди курортларын кирәк түгел дип җырлыйлар. Әмма чак кына авырсалар, врачка чабалар, курорт карточкалары тотыра башлыйлар, поездлары туган җиргә түгел, башка якларга алып китә... Минем дә шулай... Әмма мин үзем туган җирне ял итү, дәвалану белән бәйләмим... Туган җир ул, барыннан да бигрәк, син үзен — балалыгын, яшьлеген... Менә мин туган җиргә кайттым. Дәваланырга түгел, бәлки ял итә дә алмам. Максатым ул түгел. Мине бу җиргә алып кайткан теләгемнен иң көчлесе шул — бала чагым, яшьлегем белән очрашырга, туйганчы бер сөйләшергә, уйлашырга, киңәшергә кайттым.

* * *

Кичәге көн белән бергә калган дуслар ничектер икегә аерылалар. Син аларның бүгенгесен белмисен, киләчәкләрен күрмисең, ә узган көн кыяфәтендә алар синен белән һаман сөйләшәләр. Дуслык та шулай, мәхәббәт тә.

Хәтергә сугыш еллары килә.

1944 нче ел.

Туплар гөрселдәве безгә ишетелми. Сугышны без йөзләребезнен тирән монсулыгында, балаларның житдилегендә күрәбез. Элек безнен кебек бала-чага урам бетереп шар суга, аларга кичләрен олылар да кушыла иде... Урамда хәзер шау-шу бөтенләй тынды. Кояшнын яктылыгы, җылысы күп мәртәбә кимеде. Кичләрен әллә нинди әйтеп аңлата алмаслык шомлы тынлык урнаша. Ул тынлыкны җимереп, тирә-якта әллә нинди ямьсез өннәр кузгалып китә: якында гына, сазлык артындагы басуда бүреләр улый, этләр чиный-чиный күтәрмә астына керел качалар. Мондый вакытта мин фронтка киткән абыйларымның берсе калдырган берданканы кулыма алам да белер-белмәс корам: дары, кәгазь салам, ядрә салам. Анысын нигә салганмындыр, нәрсәгә булса да ату, үтерү өчен кормыйм бит мин ул мылтыкны. Ихатага чыгам да көпшәне һавага каратып чакманы тартам — югарыга утлар оча, шартлавы бөтен авылны чайкалдырып куя. Бүреләр улавы туктала, этләр тагын качкан җирләреннән чыгалар. Мин янадан өйгә керәм, кровать астыннан шактый авыр футлярны тартып чыгарам. Футлярның төсе яшел... Шуна күрәдер инде, шушы көнгә хәтле мин яшел төсне башка төсләргә караганда һаман артыграк яратам...

Футлярны тартып чыгарам, ачам... Ә анда минем иң кадерле серем саклана — баян. Бармаклар әкрен-әкрен, аннары тизли барып, көйле тавышлар чыгара башлый. Үзем уйныйм, үзем тәрәзәгә карыйм... Кеше-кара күзгә чалынса, туктыйм, капкага якынлашсалар, баянымны тагын ашыга-ашыга сандыкка яшерәм.

Сәбәбе бик гади. Сугыш башланыр алдыннан минем бер өлкән туганым район театрында баянист булып эшләгән иде. Сугыш чыккач та, ярты ел чамасы район колхозларында концертлар, спектакльләр күрсәттеләр. Ләкин сугыш машинасы егетләрне берәм-берәм суыра торгач, коллектив кызлардан гына калгач, театр таралды. Минем абыйның өч-дүрт айга хезмәт хакы алынмый калган икән (үз исәбендә эшләүче театрның шундый хәле гаҗәп түгелдер). Тиешле җитәкчеләргә эш хакы сорап баргач, ана:

— Баянын кулында, сат та кит! — дигәннәр. Ләкин абыемның бу эшне законлы рәвешкә кертергә, язмача формалаштырырга вакыты җитмәгән, күрәсең. Ул безгә баянны калдырды да китте, фронтка. Шулай итеп, безнен кулдагы баян дәүләтнеке булып калды. Көнче холыклы кайберәүләр аны бездән алып китәргә тиешләр дип сөйләнгәнгә күрә, без баянны яшереп торырга мәҗбүр булдык. Сораучы табылса:

«Саттык», дип җавап бирдек. Әмма минем баянны саттырасым килмәде... Унөч-уналты яшьлек малай кулына баян тикле баян эләксен дә, ул аны нишләп үзеннән ычкындырырга теләсен инде! Анда уйнарга өйрәтә торган китап белән (ул минем кулга баян белән бергә эләккән иде) сөйләшә, тиргәшә торгач, музыка дигән нәрсәнең кызыктыргыч көчен дә, коточкыч рәхимсезлеген дә төшенә башладым. Ул үзенең могҗизалы серләрен тиз генә, җиңел генә ачарга теләми, минем кебек ярдәмчесе, өйрәтүчесе булмаган кешене бигрәк тә санга сукмый. Мин аңлаган һәм соныннан ятлаган һәр сүз, һәр тавыш, һәр көй күпме йокысыз төннәр, газаплар, күпме күз яшьләре белән юылган! Ә моны беркем белми, сөйләргә дә ярамый.

Миңа унҗиденче яшь бара инде. Күңел бикле, баян сандыкта. Белмим, озакмы шулай дәвам итәр.

Тагын кич җитте. Әлеге тып-тын, үксеп елыйсыны китерә торган җәйге ямансу төн. Сазлык аръягында тагын бүреләр улавы. Авыл буйлап яңгырап узган берданка тавышы. Кабалана-кабалана кровать астына сузылам, яшел футлярны тартып чыгарам. Баян минем кулда. Салмак кына көй агыла башлый, сагыш үзе чыгарган көй:

**Яңгырлы көн, караңгы төн —**
**Без аерылган көн бит ул...**

Бүреләр улавыннан соң баян моңы сәер ишетелә. Уйлар каядыр еракка китеп адаша, күңелдә кемнәндер аерылу сагышы... Бу хис ул елларда барлык кешенең уртак тойгысы, теләсән дә, теләмәсән дә аннан аерылып булмый, мөмкин түгел. Бер үк һаваны сулап яшисең... Минем дә шулай күпме туганнарым бар иде... Хәзер берсе дә янда түгел. Хәер, берәү калган икән, әниемнең энесе, Сафуан абзый, Килметов (аны, ни өчендер, авыл халкы Килмит дип кенә йөртә), хәзер колхоз председателе.

**Китсен минем кайгыларым**
**Агым су белән бергә...**

Кинәт көй өзелде, өйдә, бүлмә ишеге артында аяк тавышлары ишетеп, урынымнан тордым да баянны сандыкка салырга ыргылдым, әмма соң инде, чүгәләп торган хәлемдә аркамнан кемнеңдер йомшак кына кагуын сизеп, кергән кешегә үрелеп карадым. Төнге кунакны, караңгы булса да, бик тиз таный алдым. Өстендә бераз кысанрак китель (көндез күреп күнегелгәнлектән мин аны, ничектер, хәзер дә шул яшел төсендә күргән кебек булдым), башында шактый таушалып, уңып беткән яшел фуражка, кискенлек биреп торучы озынчарак туры борын... Тәрәзәдән әз генә яктылыкка охшаган шәүлә төшкән йөзенә карагач, аның кечкенәрәк, гадәттә кырыс күзләрендә мин ниндидер җылы очкын күреп алдым... Юка иреннәре елмаймаса да, бит алмасы турында елмаюга охшашлы хәрәкәт тә күренеп китте бугай. Әйе, бу — Сафуан абзый. Әнә, иренендә күптәннән калган җөе дә бар. Әлбәттә, шул. Кайчандыр, мин тумас борын, аның унъяк иренен эт тешләгән булган. Бала чагында кем эт белән уйнамаган. Сафуан абзый да бер телем икмәкне сындыргалап һавага чөя, эт аны сикереп, өскә ыргылып кабып йота. Шулай шактый уйнагач, ул этне шаяртмакчы була, кулына бер кисәк ипи алып чөйгән итә дә үзе авызына китереп каба, ә эт бер ымсыну белән икмәк кисәген кабам дип, Сафуан абзыйның иренен эләктерә... Иренендәге җөй караңгыда да абайларлык булгач, этнең шактый мул каптырган булуын чамаларга мөмкин. Менә бит нинди шаярулар була дөньяда.

— Курыктыңмы?

Баш өстемдә баритон белән тенор арасындагы, әмма көч, тәвәккәллек биреп торган кискен яңгырашлы тавыш ишетелде. Җае чыкканда әйтеп калыйм, бераз үсә төшкәч минем үз тавышымны да аның тавы-

шына ошата башладылар. Тик ул кичне минем тавыш ишетелер-ишетелмәс кенә янгырады шикелле.

— Мин чит кеше дип торам...

Баянны сандыкка биклэп куярга жыенуымны шәйләдеме, Сафуан абзый үзе дә минем янга иелде:

— Туктале, я, курыкма...

Ул безнең өйдә вакытта куркуның кирәге юк иде, билгеле. Тик инде гадәткә әйләнгән бер курку белән баянны алдым да еикереп тордым. Сафуан абзый да тураиды. Бер-беребезгә карашып бер минут чамасы торылгандыр. Шуннан сон Сафуан абзый кычкырып көлеп жибәрде:

— Син нәрсә, малай актыгы, саташасыңмы әллә?

Аның көлүенә ияреп, ана баянны үзем суздым:

— Мә, уйна әлсә.

Сафуан абзый баянны тыныч кына үз кулына алды да кроватька утырды. Каешын жайлап кулбашына киде. Көй эзләп клавишларга баскалады. Көен тапкач, артындагы өюле мендәрләргә ауды. Яткан килеш үзенең һәрвакытта уйный торган бер көен — халык көен уйный башлады. Ул көйне безлә «Уфа көе» дип йөртәләр. Халык аңа теләсә нинди сүзләр яраклаштыра, ә профессиональ жырчылар шундыйрак сүзләр белән жырлыйлар:

**Сандугачлар оядa лa,**
**Ояларын пыяла, шул,**
**Ояларын пыяла.**
**Сандугач кебек сайрашып,**
**Шат яшибез дөньяда.**

Патефон пластинкасыннан отып калынган тагын шундый сүзләре дә исемдә:

**Торган жирем — гөл арасы,**
**Үзем — авыл баласы.**

Бу сүзләрне шушындый чакта ишетүнең ничек мәзәк тоелуын сез аңлыйсыздыр инде. Ямансулап калуның нәрсә икәнен белми торган Сафуан абзый уйнаганда да хәзер бу көй күңелдә ниндидер ерак матурлыкны хәтерләтеп йөрәккә чәнчи.

Әле балалыктан чыгып та бетмәгән булуыма карамастан, минем инде үземә күрә сагынырлык вакыйгаларым бар. Шушы ук Сафуан абзый ун ел читтә йөргәннән сон безнең янга кунакка кайткан бер көн. Жиде балага (бөтенебез жидәү идек) берәр кат кием алып кайтып безгә тараткан иде ул. Без аны әйләнеп, сырып алганбыз. Ә ул кулына берәр нәрсә алган саен:

— Монысы кемгә? Монысы кемгә? — дип кычкыра.

Күрше-тирә, эни, әйбернең кемгә яраклы булуына карап, берәребезнең исемен әйтә. Ин сонынннан Сафуан абзый кулына тальян гармонь алды да, нәкъ шушы кровать урынындагы сәкегә утырып, әлеге көен уйный башлады. Анардан да матуррак уйнау, минемчә, мөмкин түгел иде. Ул уйнавыннан шып тукталды да тагын:

— Монысы кемгә? — дип кычкырды.

Беркем дә «мина» дип эндәшергә кыючылык итмәде. Ахырда Сафуан абзый үзе ук:

— Монысы бөтенебезгә дә. Кайсыгыз талантлы, шул уйнар, — диде.

Арттырмыйча әйткәндә, гармоньга безнең бөтенебез дә сәләтле булып чыкты. Менә хәзер баянда уйныйбыз... Сафуан абзыйга карап мин:

— Баянны алай тотмыйлар, тальян түгел ул сина, — дип сүз кушкан идем, ул кинәт урыныннан торды да инструментны мина тоттырды.

— Мәле, күрсәт әле алайса, ничек уйныйлар?

Аның каршысына, бүлмә буендагы агач эскәмиягә утырып, салмак кына, әкрен генә уйный башладым. Үзем өчен генә уйнаганда көй яңгырашына чын күңелдән, җаным белән дә, тәнем белән дә кушылам мин. Ә кеше өчен күптән инде уйнаганым юк. Бу юлы үзем өчен дә, кеше өчен дә яшим... Шуңа күрәме, башка вакыттагы бертөрлелек бүген бөтенләй юкка чыкты. Гадәттәгечә, салмак көйләрдән башланып, соңрак кыска көйләргә, аннары бию көйләренә, соңрак мажор ладка, тантаналы моңнарга тоташканымны Сафуан абзый сикереп торгач кына аңладым.

— Молодец! — диде ул кычкырып һәм, ачулангандай, миннән баянны тартып алды. — Ничек итеп шундый тавышлар чыгара аласың син, ә? Минем дә бармаклар начар түгел ләбаса! Синекеннән көчлерәк тә...

Ул тагын диссонанс яңгырашлы тавышлар чыгарып баянны тарткаларга тотынгач, минем авыздан шундый сүз ычкынды:

— Алай уйнамыйлар, Сафуан абзый...

— Эх син, очыначы! Алай уйнамыйлар... Мин бит син түгел... Ну, ярый. Шәп. Кара ничек әсәрләндерә беләсең бит, ә!

— Юк, әллә ни уйный белмим әле. Менә мәктәп булсыние ул. Музыка мәктәбе. Мин шунда укырием.

Сафуан абзый бу сүздән кычкырып көлмәде көлүен, тик караңгыда мин аның ни өчендер елмаюын күргән кебек булдым.

— Кара син, кая сикермәкче. Андый мәктәпләр, апай, шәһәрдә генә. Авылда юк.

— Ә ни өчен юк?

— Менә шулай, юк инде.

— Ә минем музыка мәктәбендә укыйсым килә. Мин шәһәр малаеннан начарракмы әллә? Ни өчен аңа бар, миңа — юк?

— «Ни өчен, ни өчен...» — диде Сафуан абзый үчекләгәндәй. Бу вакыт ул үзе дә моның гаделсезлек икәнен төшенә, ләкин аңлата алмый иде бугай. — Син ләгатькә килмәгән сораулар белән баш катырма, яме, — диде ул кискен генә.

«Ни өчен?» ачык калды. Сафуан абзый, нәрсәдер исенә төшергәндәй, шундый ук катгый формада сүзне борды:

— Житте, иптәш, иртәгәдән ук болынга, печән чабарга китәсең. Тыңласын бөтен халык, эшләсен дәртләнеп, күңел ачсын, бәйрәм итсен...

— Бәйрәм итсен!

— Бәйрәм ук булмас, конешно. Гел генә кайгырып та файда юк ласа. Бераз аны оныттырып торсаң да шәп булыр. Халыкның башы гел иелеп торса, күңеллемени? Син ярдәм ит миңа, гел приказ белән генә булмый, кушу, куркыту белән генә бармый ул.

Мин, баянны кешеләргә күрсәтергә ярамавын хәтеренә төшереп, баш тартмакчы идем дә ул кырт кисте:

— Юк, сине разе музыкадан аерырга ярый! Юк, юк, син үзең — баян. Калганы пучтәк! Шулай, товарищ, иртәгә печәнчеләрне болынга алып китәсе олау беренче булып синдә тукталыр. Чалгыңны чүкеп, әзерләп куй. Калганы ничек килеп чыгар, үзең дә шаккатырсың. Житте, йокла.

Холкы белән шактый кырыс кешенең болай әсәрләнүен күрү минем өчен мәзәгрәк тоелды. Музыка ерткычларны да юашлата дигән сүзне укыганым бар иде шул... Сафуан абзый андый ерткыч түгел, юк, юк, һич тә түгел, шулай да ул каты күңелле кеше. Ә бүген күрәм, ул әнә ничек итеп нечкәрә дә белә икән.

...Иртәгесен беренче кояш яктысы белән бергә миңе урам яктан ишетелгән тавыш, ирләр тавышы уятты:

— Трр, малкай.

Карасам, өске киемнәрне чишенмичә үк йоклап киткән икән.

* * *

Печән өсте.

Крестьян тормышының иң матур, шау-шулы, күтәренке бер бәйрәме. Озын ел уртасындагы кыска гына бу мизгел һәркем хәтерендә үзенең онытылмас вакыйгалары, иң якты кичерешләре белән гомернең ахырынача яши. Минем, әле уналты гына яшьлек малайның, печән чаба башлаганына инде өченче ел. Төрле чаклар булды. Шулай да ел бәйрәме мине һәрвакыт ашкындырып, нәрсәгәдер талпындырып, ымсындырып тора. Бервакыт, моннан ике ел элек, болынга абыемны илтергә дә шулай ат килеп төшкән иде. Яшел печән салынган мажарга (чыбык арбаны безнең якта шулай дип атыйлар) утырды да...

Хәер, сөйләүнең кирәге юк, хәзер мин үзем бөтенесен нәкъ шулай кабатлаячакмын.

Сабы чыгарылган чалгы арбада җайсызлап тормаслык итеп бәйләп куелды, бүтән вак-төяк салынды. Аннары өйгә кереп, кабаланмыйча гына яшел футлярны алдым да урамга чыктым. Чирәм өстендә футлярны ачтым. Баянның каешларын иңбашка таманлап кидем дә футлярны яптым. Ул арада ат иясе сандыкны мажарга җайлап куйды да атка эндәште:

— Әйдәгез әле, хәерле сәфәргә!

Ул арада баян сыздыра башлый, җыр белгән һәр кеше аның дәртле чакыруына кушылырга, иярергә, тыелып калмаска тиеш.

**Алма бакчасына керсәм,**
**Алма тия җилкәмә.**
**Үземә дә бик кадерле,**
**Сүз әйтмәгез иркәмә.**

Яшьлекнең мәңгелек тирәнлегеннән тибеп чыккан тылсымлы агышын тыеп буламыни! Бу җилкенү, бу ашкыну... минут эчендә бөтен авылны әйләнеп чыга. Капка төпләренә, тәрәзәләргә кара: кешеләр музыкага сузылалар, алар миңа карыйлар. Иөкле ат кайсы өйгә туктамасын, аннан чалгыларын күтәреп, яшьме, картмы, кем булса да утырмыйча калмый. Кечкенә авылның яртысын узганчы мажарга утырыр урын калмаган иде. Янадан барырга теләүчеләргә кучер агай:

— Бригадирыгызга әйтегез, яңадан ат җиктерсен. Килмит: «Кеше никадәр күбрәк барса, шул хәтле яхшы», дип әйтте,— диде.

Ул арада, аның киңәшен тотып, кайсыдыр каядыр чаба:

— Сез ат җигә торыгыз, мин бригадирга хәбәр итәм.

Менә без мажарда — күбесе яшьләр. Минем янда гына җырчы дусым — Әзһәр дигән малай, яшьтәш. Икенче якта миннән бер яшькә зуррак, сугышып ускән күрше дустым — Хәмит. Алар да бу көнгә, шау-шуга, җырга, уен-көлкегә сусаганнар. Һәркемнең йөзендә нәрсәләндер котылу, ычкыну шатлыгы, күп еллык сагышка үч итү, үч кайтару — тыелгысыз көлү, шаян сүз... Менә без авыл капкасын узабыз. Балан чәчәкләре, таллар аркабыздан сыйпап калалар. Алар да безне тыңлыйлар... Безнең җырны авыл, кыр, бөтен табигать тыңлый.

**Иркәм, иркәм дип әйтәсең,**
**Үзең иркәләмисең.**

Унҗиде яшь... Кара син, бу аз түгел икән лич инде. Без хәзер малайлар түгел, без — яшьләр! Мин шул көнне аңладым: музыканы сандыкка яшереп, озак тотып булмый икән. Мәхәббәтне дә шулай...

* * *

Агыйдел буйлары.

Ямьле Агыйдел буйлары.

Мин аларның ямансу матурлыгы, яшьлек белән генә чагыштырырга мөмкин булган гүзәллеге турында бер сүз дә әйтә алмыйм, чөнки ул сүздән файда юк. Агыйдел еллар, гасырлар буе инде ничәмә йөз жырда канатлана, тик ул жырлар да Агыйделнең әйтеп бетермәслек ямен аңлатып бирә алмыйлар әле. Агыйдел — һәр кеше гомерендә кабатлана торган үлемсез яшьлек, үлемсез мәхәббәт, ул — синең дә, минем дә мәхәббәтем. Андагы тын күлләр — туган жирнең Җидегәннәргә, Киек каз юлларына карый торган якты күзләре; андагы таң жиле белән бергә сирпелә торган, юкка гына камыш дип исәпләнгән озын керфекләре... Чакрымнарга сузылган әрәмәләр... Аларны минем башка бер жирдә дә очратканым, күргәнем булмады...

Агыйдел буена якынлашканда олаулар инде чакрым чамасы озынлыкка сузылгандыр: юл буе бүтән авыл, бүтән колхоз кешеләре дә безгә кушылдылар. Менә тигез печәнлекләр, ә еракта зәңгәр таулар... Алар да безне каршылыйлар, юкка түгел, без аларга тормыш алып киләбез.

Болын — яшел диңгез. Килеп житкәч, һәр колхоз кешеләре үз юллары белән китеп, ана төшеп югалалар. Без дә үзебезгә бүленгән жиргә життек.

Сайлаган урыныбыз — киң генә калкулык, ялан. Биегрәк жирләрдә — куаклар. Төньякка, елга буена таба урман, әрәмәлек китә. Туктаган жиребезнең көньяк төшендә озынча һәм тар гына күл... Аның янында кемнәрдер кое казырга керештеләр. Без берничә кеше куышлар ясарга тотындык. Баганалыклар, өрлекләр, түбә ябарга нәзек таллар. Мин кисәм, иптәшләр ташый. Тагы кемнәрдер кисә, тагы кемнәрдер ташый. Баш күтәрмичә шактый эшләгәннән соң бер мәлне ничектер дөнья тынып калган шикелле булып китте. Янымда гына кемдер кыштырдый. Ныклабрак карасам... Чамадан тыш гажәпләнеп, шаккаттым да калдым. Алдымда — кыз кеше, үзем кебек үк яшь кенә бер жан иясе. Кызның чибәрлегенә исем китеп, ана талпынам. Талпынам да, әдәп хисе сизеп, тыелып калам.

Күпме еллардан соң аның шул көндәге төсен хәтерләргә тырышам. Ул миңа чак кына якынлаша да тагын югала. Күкрәкне авырттырырлык дәрәжәдә көч куеп, аны бүгенге көнгә кайтарырга тырышам, ә ул аның саен ераклаша, кача. Мондый чакта аның рәсемен кәгазьдә булса да ясыйсым килә, югалмаслык әсәр итеп.

Ах, художник булсам! Бу сынны ясар өчен майлы буяулар сайламас идем мин, жинел акварель сайлар идем. Җиңел, якты, шатлыклы! Бар бит дөньяда гүзәллек! Күзләр. Алардан мәхәббәт сибелә... Яшел куак, яфраклар аркылы үзган кояш яктысыннан аз гына чагылып кысылган коңгырт күзләр. Җирдә мөмкин булган иң матур сүзне әйтергә ымсынган агымлы юка иреннәр. Мин ярата торган озынчарак йөз. Күкрәкләренә төшкән, игътибар иттерә торган, күзләре төсле үк коңгырт толым. Агыйдел кызы! Менә син нинди! Яфраклар арасында үзең сөялгән шомырт белән, куак белән, әрәмә белән, Агыйдел белән бер бөтенлек хасил итеп басып торасың син. Миңа нәрсә хакындадыр пышылдадың бугай. Юк, бу — яфраклар шыбырдавы...

Мондый чакта кызлар егетләргә караганда кыюрак була диләр, рас ахрысы. Әллә миңа караганда азрак сихерләнгәнгә күрә инде, әллә бүтән сәбәп белән, кыз чынлап та башта үзе эндәште:

— Агач житте инде. Бүтән кисмәскә була.

— Мин кискән агачларны син дә ташыдыңмы? — дидем мин моңарчы аны күрмәвемә гажәпләнеп.

— Әйе.

Шулай диде кыз. «Син бит агачларны гына күрәсең, ә кешеләрне — юк», дип өстәргә тиеш кебек иде ул, тик әйтмәде. Култыгына нечкә генә ике-өч тал кыстырды да китеп барды. Калган агачларны мин өстерәдем. Куышлар урынына җиткәнче бер сүз дә эндәшмәдек.

* * *

Куышларның ничек тиз ясалуы, печән чабып түбә ябуыбыз, ятар өчен әчке якка җайлап түшәвебез, көлешә-көлешә көндезге аш ашаулар, аннары печән чабарга керешүләр — хәтердә әкият күренешләре төсләрәк саклана. Ул күренешләр арасында син үзең дә аз гына сихергә әйләнәсең: колакта өр-яңа көйләр, мең-мең борылышлар һәм... берәүнең әкертен тавышы. Бер көй белән алга атлыйсың да атлыйсың, чалгы селтисең дә селтисең... Кытырдап үлән киселә, үлән кыштырдаганда сөекле кеше сүзләре, син ишетергә өметләнгән сүзләр һаман ишетелә... Чалгы янаган вакытта, корыч тавышы, әллә кайда еракта кыз тавышы белән кушылып, болын буйлап китә дә әйләнеп кире кайта. Атлаган саен каршыда ул басып тора кебек... Ял итәргә, сулу алырга туктыйсың, күзләр куыш ягында.

Тукталам да карашым белән бөтен болын киңлеген тагын бер кат иңли башлыйм. Мондый да яктылыкны, мондый да якты дөньяны мин беренче тапкыр күрәм. Бу дөнья синең карашыңнан балкыган бүген, Агыйдел кызы! Әй!

Печән өсте! Мине үзеңнең күренми торган дулкыннарың белән каядыр агызып киттең бугай син, яшел диңгез. Моннан гадәти тормышка, коры җиргә йөзеп чыга алырмынмы? Юк, мин синдә әллә ничек югалып калсам да, гомерлеккә батсам да риза. Бу минутта бөтен дөньяга ишетелерлек итеп: «Алып кит, агызып кит мине, яшел диңгез, тик бүгенге бәхетемнән, аның моңсу һәм ягымлы карашыннан гына аерма. Аның белән бергә мин — синең иркеңдә. Мәңге шулай булсын, булсын, мин риза!» дип кычкырасым килә. Хәер, мина кычкырырга һич тә кирәкми. Моның өчен минем бүтән юлым бар, мин бу сүзләрнең барысын, барысын җырга, музыкага тапшырачакмын, баяндагы барлык тавышлар аркылы ана ирештерәчәкмен! Ул аңлаячак. Әлбәттә, аңлаячак!

Печән өсте! Беренче мәхәббәтем төслерәк гаҗәеп мизгел! Вакыт җитә, кояш Агыйдел таулары артына төшеп бара... Тукта, шул яклап, кулына озын тәпиле сәҗин тотып кем килә? Ул бит! Ул! Ул без чапкан җирне үлчи. Башкаларның исәпләнгән инде. Хәзер безнең чират. Без күпме эшләгәнбез икән? Башкалар? Безгә аның алдында кызарырга туры килмәсме? Аннары ярату турында авыз да ачма.

Кыз безнең янда. Иреннәрендә баягы, мин әрәмәдә беренче тапкыр күргән елмаю... һәр минут, һәр секундта чыгып ычкынырга торган иң матур сүз... Ләкин ул ни өчендер, ялгышып әлбәттә, башка сүзләр әйтә. Менә ул безнең өчебезгә күпме чабылганны исәпләп чыгарды, кеше саен егерме сотый җир туры килә... Ярты көнгә. Уйлыйм: болай булгач, көненә кырыгарны чабачакбыз икән. Өлкән агайлардан калышмасак, хәтта арттырып та җибәрсәк, синең белән сөйләшеп тә карарбыз әле, Фәһимә!

Каян шундый уй? Әйтерсең, мәхәббәт гектар белән үлчәнә!

* * *

Бүтәннәр табынга җыелганнар да безне көтәләр. Ашны кем күпме тели, шулкадәр ала. Ә менә итне җирәбәгә салалар. Килеп җитүгә, мина артка борылырга, күзне капларга куштылар. Кызга:

— Каплап тор әле, Фәһимә, егетнең күзен.. Харамларлык булмасын, — диделәр.
— Харамлаша белми ул, — диде кыз, никтер каушый төшеп.
— Егетләргә ышанма...
Фәһимә кызара, уңайсызлана. Ә мин эчтән генә бу кешеләргә рәхмәт укыйм. Үзенең кыюлыгы җитәр идеме-юкмы, ә болай мине кочаклап диярлек торсын әле! Әйе, әйе, чәчәкләр өзәр өчен генә яратылган шушы кечкенә куллары белән минем күзләрне каплап тора ул. Шул кулларның сихерле жылысын тоюдан йөрәк кытыклана, артымда ишетелгән бер үк сорауга җавап бирәм:
— Монысы кемгә?
— Җәләй бабайга.
— Монысы кемгә?
— Тимербикә апага...
Тимербикә апа дигәнебез — аш пешерүче. Алар Фәһимә белән бер куышта икәү генә урнаштылар, ә безнеке бер куыш аркылы гына.
...Хәзер кичке ял житте. Фәһимә минем куыш янына килде.
— Әнис, сине көтәләр.
— Кемнәр?
— Күрәсең ич, күпме халык җыелган.
Ул, үз куышыннан алып, миңа утырыр өчен болындагы бәлки бердәнбер урындыкны китереп, «яшел өйләр» артына (куышларны шулай атавыбыз инде), тип-тигез җиргә куйды. Гадәтемчә, мин башта нинди дә булса үзем яраткан бер көй уйныйм. Монысы фәкать үзем өчен, шул уңайдан башкалар да тынлый. Аннары бию көйләре китә, бүтәннәр аерым-аерым, соңыннан кумәкләшеп үзләре белгән барлык биюләрне биеп чыгалар. «Аера» дигән тансалары бар, шуны биила́р. Краковякны да беләләр, хәер, монысында түгәрәктә азрак кеше кала. Ә менә вальс яки фокстрот уйный башласаң, Фәһимә белән аның дус кызы — укытучы кыз Гөлбстан гына кала. Танго турында әйтәсе дә юк, бу — безнең өчен иң авыр танса. Үземә калса, мин аны хәзер дә рәтләп би белмим һәм танса мәйданнарына әйтеп аңлата алмаслык көнләшү белән карап торам. Фәһимә анысын да бии... Үзе Яркәйдә урта мәктәптә укыганда өйрәнгән, мине дә өйрәтергә вәгъдә бирде. Тик өлгерә алырмы, бию белән мавыгырга вакыт юк, җәйге төн күпмегә житә ул!
Баян уйнауны авылда эшкә чутлаучы юк. Уйлап карасаң, мин монда күпме көч түгәм, аны беркем дә аңламый һәм аңларга да теләми. Җырлавың белә, уйнавың, көлүең белә. Хәер, ул вакытта мин үзем дә аңламый идем. Бигрәк тә Фәһимә янда бөтерелеп, күбәләк сыман очакуна йөргәндә. Нинди авыр эш — печән чабу — үзе дә өзлексез бәйрәмгә әверелде ләбаса! Күзләрем һаман анарда. Ашкынып-ашкынып уйный бирәм. Минем ашкыну башкаларга күчә, күрәсең. Әнә аларның да күнелләре ничек күтәренке бит, озын көн буе, кояш чыкканнан кояш батканга кадәр эшләмәгәннәр, диярсең. Халык җыела да җыела, бөтен тирә-яктан, башка колхозныкылар... Колагына музыка ишетелгән һәркем безнең тирәгә ашыга. Агыйделнең иң үзәк урыны шушында, чөнки Фәһимә шушында. Ул монда булганга күрә мин шушында. Әнә ул бии, очынып-очынып бии. Менә аны күрше колхоздан килгән бер егет «Аера»ны биергә чакырды. Фәһимә бармады. Нәрсәдер әйтеп баш тартты да миңа карады: синнән аерыласым килми, күрәсеңме, баянчы, дигәндәй тоелды. Бәлки, бөтенләй башка нәрсә әйткәндер... Минем Фәһимәм Гөлбстан белән бии, ана нидер сөйли, тегесе миңа карап елмая да күз кыскандай итә, үчекләгәндәй итә.
Һәр нәрсәнең чиге була, куллар азыртуга чыдый алмый башлагач, мин гармоньда этәч кычкыртам да җыр көенә күчеп, урыннымнан кузгалам. Башка колхоз печәнчеләрен җырлатып, шактый ара озата барам. Кабат куыш янына киләм, Фәһимә анда, Гөлбстан анда, тагын бер

егет... Юк икән, Хәмит, минем иптәш малай. Мин килеп утыру белән Гөлбстан ниндидер сәбәп тапкан булды да торып китте. Ә Хәмит дусты... Фәһимәдә аның да исәбе бар инде әллә, утыра да утыра...

Учак сүнгән диярлек. Фәһимә вак агачлар китереп салды. Алар янып бетте. Мин китереп өстәдем. Учак яна. Йөрәк яна... Нәрсәдер көтә, нидер ишетергә тели, нәрсәдер әйтергә тели... Җүләр, аның эзләгәне, көткәне — бөтенесе бар, бөтенесе шушында лабаса! Нәрсә көтәргә, ни җитми аңа тагы?! Бигрәк хәерсез яратылган бу кеше күңеле.

Өметен өзепме, йокысы килүдәнме, дустым Хәмит бер-ике тапкыр авыр сулыш алды да куышка кереп китте. Учакка тагын бераз гына чыбык өстәдем. Төтен Фәһимәнең калын толымын хәтерләтеп җилпенә. Мин аның янына, бүрәнә өстенә, якынгарак күчәм. Ул иелеп учактагы агачларны рәтләп куя. Болай, эш табып, юри генә. Ул янадан турая һәм шул арада аның калын йомшак толымы минем кулга килеп төшә — мин ул чәчләрнең рәхәт йомшаклыгын тоям. Фәһимә җыр башлый:

Таң-таң ата, чулпан калка,
Чулпан — таңнар көзгесе.
Чулпан ул таңнар көзгесе,
Минем сагыну билгесе.

Аның бу җыры, инде ничәмә еллар узса да, һаман минем колакта ишетелеп тора. Аны бары Фәһимә генә шулай матур, моңсу итеп җырлый ала. Башка кешеләр җырлаганда көйнең бернинди матурлыгы калмый, хәтта профессиональ артистлар башкарса да. Галия Гафиятуллина — нинди саф тавышлы җырчы, шулай да «Таң» көен ул да җиренә җиткереп җырлый алмый, ритмны тизләтеп, үзгәртеп җырлаганга күрә генә түгел...

Музыканың көче — композиторда, башкаручыда һәм... күбрәге тыңлаучыда. Композитор тыңлаучыда ярдәмче авторын таба яки юк. Шулай, уңа, бөек композитор да. Синә килеп житкәнче ул бөтен моның җуярга яки икеләтә көчлерәк яңгырарга мөмкин. Ничек тыңлыйсың бит. Кем тыңлый, ничек кичерә. Әйе, Фәһимә бу көйне үзенчә, салмак, шул ук вакытта артык сузмыйча да җырлый: гади көй, гади җыр булу белән генә чикләнми, минә башка күренешләр, үзебезгә уртак июнь таңы кебек якты, моңсу кичерешләр, Агыйдел суларының кичке һәм иртәнге балкышы, чакрымнарга җәелгән әрәмәләр сулавы, күл камышлары шыбырдавы, ниһаять, Фәһимә үзе — аның яшьлеге, мәхәббәте, минем мәхәббәтем... Ах, тагын, тагын нәрсәләр, нәрсәләр генә юк бу җырда!..

Мәхәббәтем шундый көчле,
Мөмкин түгел аңлату.

Әмма мин аңлыйм, җырның ни өчен, нинди хисләр белән җырланганын бик яхшы тоям. Куышыма кереп яткач, печән исенең ни өчен шушы кадәр татлы булуын, төрле яктан томаланган куышка үтәргә юл тапкан озынборыннар безелдәвенең ни өчен бу чаклы матур ишетелүен аңлыйм. Тик әле шунысын белмим: ничәмә еллардан соң мин черкиләрне дә сагыначакмын бит. Алар анда тәнне авырттырмаячак, әйтеп бетерә алмаслык рәхәтлек кенә бирәчәк. Бу минутлар мәңгелек булып сузылсын иде дә йөрәгем бөек мәхәббәт дулкыннарында, яшел диңгез иркендә мәңге чайкалсын иде. Кешеләр әйткән: мәхәббәттән дә борынгырак хис юк, дигән. Дөрес түгел, юк, һич тә дөрес түгел. Мәхәббәт — беркайчан да иске була алмый. Һәр мәхәббәт һәр яшь кеше хыялында туган иң зур ачышларның берсе ул. Яшьлек! Никадәр бәркәтле, никадәр даһи син!

Иртәнге кояш Фәһимә елмаюын тагын бөтен болынга тарата. Печәнчеләр, тастымалларын алып, күл буендагы кое янына киләләр. Мин дә

ашыгам... Тик бутэннэр кебек үзем генэ юынмыйм. Минем янга үзем тесле үк шатлыкны Фэhимэ кила: үзебез казыган коедан су ала да кулга су салып юындыра...

Бу вакыт мин бөтен тэнем белэн үзебезгэ караган дистэлэрчэ күз елмаюын сизэм.

Һэр туган көн безне иркэли. Кичлэр якты, кичлэр ямансу — әйтелмэгэн мэхэббэт кебек, безнең мэхэббэт кебек. Мондый кичлэрдэ йөрэккэ төрле икелэнүлэр килэ, сагыш керэ, йөзгэ күлэгэ төшэ. Кайчагында...

Шундый ямансу төн. Без тагы учак янында. Эллэ яктыра да башлады. Безнең икебезнең дә аерылышасы килми. Бер генэ минутка да. Берни дэ астыртын мэгънэ әйтергэ телэмичэ Фэhимэдэн сорыйм:

— Сезгэ Тимербикэ апа белэн икэү генэ йоклау куркыныч түгелме? — Минемчэ, төнге куышта ике хатын-кыз куркырга тиеш иде.

Хэзерге акылым белэн уйлап ышанам, мөгаен, Фэhимэ дэ сүзен минем кебек үк туры мэгънэсендэ әйткэндер. Үзенэ хас нэзек тавышы белэн жавап бирде ул:

— Тимербикэ апа курка...

— Ул мина да шулай дигэнне.

— Әйе шул.

Учак инде янып бетте. Хэзер кыз да чыбык салмый, мин дэ. Ерактан, Агыйдел авылларының берсеннэн, этэч тавышы ишетелэ. Эрэмэдэ меңнэрчэ кош сайрый, тартай кычкыра. Безнең өстэн генэ пар үрдэк очып бара... Югартын күк йөзе яп-якты икэн... Ике-өч сэгатьтэн — эшкэ... Икебезгэ бер сүз әйтмичэ аңлашып кузгалабыз. Фэhимэлэр куышы төбендэ туктэлабыз. Ул куыш авызындагы печэнне аралый, үзе керми, мин кергэнне көтэ бугай... Э көтмэсэ? Юк, мин керсен димэсэ, үзе кереп китэр иде дэ: «Тыныч йокла, Энис!» — дияр иде... Э бүген алай түгел. Каушавымны жиңеп, куыш ишегенэ иелэм, Фэhимэ — минем арттан. Мин аның аркама бэрелгэн кайнар сулышын тоям. Тимербикэ апа эллэ сизми, эллэ безне оялтмаска телэп, кузгалмый, эндэшми, эллэ йоклый, эллэ юк... Хэер, безгэ аның йокламавыннан нинди зыян? Ул безнең дуслыкка куана гына лабаса. Фэhимэгэ берничэ кабат әйткэн. Менэ без йомшак печэн өстендэ көндез дэ бергэ, төнлэ дэ бергэ — һэрвакыт бергэ. Безне аера торган көч юк һэм булмас та... Бу минутлар!.. Фэhимэнең сулышы битемэ бэрелэ, керфеклэре, йомшак чэчлэр битемне кытыклый. Кичтэнге арылганлык, иртэнге йокы килү исертэ, һуштан яздыра кебек. Көннэр буе йөргэн тынгысыз сүзлэр үзлэреннэн үзлэре тиберченеп чыгалар:

— Син мине генэ яратасыңмы?

Болар — жавап көтеп әйтелгэн сүзлэр түгел. Мин жавап көтмим. Аның яратканын инде бөтен тэнем белэн аңлыйм бит. Безнең табигый мэхэббэтнең бары тик сүзлэргэ эверелеше бит бу сүзлэр. Жавабы шул ахрысы: Фэhимэ иреннэрен минем иреннэргэ китерэ. Юк, бу — үбешү түгел. Соңыннан мин татыган үбешүлэрнең барысын бергэ жыйган хэлдэ дэ алардан миллион мэртэбэ татлырак булган саф якынлашу... Кабатланмас рэхэтлек, изге, чиста, гөнаhсыз лэззэт! Шул рэхэтлекне мэңге оныта алмас иткэн сүзлэр. Ярым пышылдап, ярым кычкырып әйтелгэн сүзлэр:

— Сине генэ... Мин фэкать сине генэ яратам!

* * *

Болын печэненең дэ төрле урыны була. Кулле, уйсурак урыннарда үлэн калын, чабарга жиңел. Сыртрак төшлэрдэ каты кылган чалгыга һич бирелми, башын ия дэ кала. Соңгы көннэргэ энэ шундый урыннар калган иде. Монда чапканда безне картраклар:

— Ничек, энекәш, кәҗә майларын чыгарамы? — дип үртиләр.

— Чыгара, әлбәттә, чыгара. Мондый җирне үлән яшелрәк чакта чабып калырга кирәк аны.

Минем сүз өлкәннәрне гаҗәпләндерә.

— Кара син, крестьян булып туган бу нәмәрсә. Ә безнең баш җитмәгән карт крисләрнең. Хәзерге яшьләр!..

Чалгыны күтәреп өйгә кайтып китүебездән шүрләпме, картлар безгә каты бәрелмиләр. Ә сәбәп чыкса, мондый мәлдә мин бу шитинә-кылганны калдырып китәргә дүрт куллап әзер идем.

Куыш ягыннан тарантас җиккән атлы кеше килүе күренде. Җирән айгыр — председатель аты. Сафуан абзый... Аның килүен көтеп торабыз. Ул туп-туры минем янга килде дә атын туктатты, тарантасыннан төште:

— Я, ничек? Бик кыен түгелме?

— Ул хәтле түгел.

— Ябыкккансың, малай, танырлык та түгел.

Кайсыдыр астыртын шаяртып куйды:

— Ябыкмыйча, йокламагач...

Гаҗәп бу кешеләр: мин үземдә аруга охшашлы бернәрсә сизмим, киресенчә, беркайчан да үземдә болай көч тойганым юк иде әле. Ә алар?.. Шайтан белсен.

Председатель янына тиз арада халык җыелып алды. Җәйнең матур килүенә сокланалар. Беркайчан да болай бердәм, тиз чабылганы юк иде, диләр. Килмит кемнең ничек чабуы турында Фәһимәдән мәгълүматлар алган икән. Илле яшьлек өч ир белән берррәттән, безнең — өч малайның да бу көнгә чаклы (алар да, без дә аерым, өчәр кешегә бүленеп эшләдек) бертигез чабылган. Сафуан абзыйга бу бик ошады: печән чабуда иң алдынгы иптәшләргә (ул мине дә «иптәш» дип атады) нинди дә булса бүләк биреләчәген әйтте.

— Бүген мин Әшмәнгә барам. Кайтасыңмы? Үзем белән алып кайтам... — диде ул миңа.

Председатель аты белән кайту минем өчен бәйрәм, үзе бер почет булыр иде. Шуна күрәме, әллә ни уйлап тормыйча, риза булдым һәм шул арада тарантаска чалгыны сүтеп бәйләп тә куйдым.

— Туйган икән, валлаһи туйган! — диештеләр.

— Абыйсы килеп күренгәч, түзмәде...

— Китә алмый, күрерсез, — диде тагын берсе.

Бу сүзләрнең берсенә дә колак салмаган булып тарантаска утырдым. Әйберләрне алырга куышка таба киттек.

Куыш янында безне Фәһимә, Гөлбстан һәм Тимербикә апа каршыладьы.

— Пәрәмәч, әллә китәргә җыенган инде? — диде Тимербикә апа.

Мин ни өчендер җавап бирмәдем, үземне ничектер гөнаһлы кеше сыман хис итеп аска карадым, аннары тиз генә куышка кердем, анда әйберләрне җыештыра башладым. Ул арада Сафуан абзый, карлыган капкаларга дип, кызлар белән әрәмәлеккә китте. Алар янадан чыгуга, минем әйберләр тарантаска салынган, бары китәсе калган иде. Килмит килеп җитмәс борын үк миңа эндәште:

— Әйберләренне янадан бушат инде, апай, сиңа китәргә ярамый икән.

Ни әйтергә белми гаҗәпләнем торам. Тел белән әйтелмәгән соравыма җавап та ишетәм:

— Син киткәч, кызлар да калмыйбыз диләр...

Кызларга карыйм: башларын иеп елмаялар... Ә Фәһимәнең күзләрендә үпкәләү, шелтә.

— Ахырга хәтле тор әйдә, — диде Сафуан абзый тарантасына уты-

ра-утыра,— син минем монда беренче помощник икән. Таркатмыйк эшне.

Соңыннан озак уйланып йөрдем: Фәһимәне калдырып китәргә шулай ни йөрәк белән җыенган идем соң әле мин? Яшьлек! Бер нәрсәнең дә кадерен белми торган, җаваплылыкны берничек күләмдә дә танымый торган җүләр вакыт. Анда бер нәрсә дә алдан уйлап эшләнми. Мәхәббәт бар һәм шуның белән эш тә бетә. Ул иртәгене кайгыртмый. Әллә минем күңел генә шундый булганмы? Бу җиңеллек мәхәббәттәге һәртөрле фаҗигане башы түгелме икән? — Бу сорауларга җавапны мин соңрак таптым һәм артык соңга калып таптым. Минем башка мондый сораулар чак кына алдарак килгән булса да, мәхәббәтем, хәтта киләчәгем бәлки бөтенләй икенче төрле хәл ителгән булыр иде. Әмма ул чакта мин берни дә уйлый белмәгән, бары тик дөньяда яшәвемне онытырлык дәрәҗәдә мавыга гына белгәнмен шул.

Сафуан абзый китте дә барды. Мин бер нәрсә дә кызганмыйча һәм берничә шатланмыйча печән җыярга калдым.

Кичлектә гадәттәге бәйрәм, уен-көлке, җыр, бию, мәхәббәт. Без Фәһимә белән тагын бергә. Ләкин аның күзләре ничектер бүтән төслерәк карый бүгай. Мин моны рәтләп аңлап та бетермим әле. Сизәм генә: әлек гел шатлык, гел бәхет сирпелеп торган күзләрдә хәзер сагышка ошаганрак ямансу бер күләгә барлыкка килде. Бер карасаң, ул — бик моңсу... Бер карасаң, әллә ничек, тыелып килгән тыйнак дәрте ярсыну, тәвәккәллек белән алышына. Муеныннан кысып, авырттырып кочаклый, кат-кат үбә-үбә дә кечкенә куллары белән күкрәгемне кыйнарга керешә:

— Әх, син, юньсез малай! Бер тиенлек тә акыл юк синдә. Бер тиенлек тә!

Күзләремә үпкә билгесе чыгып өлгергәнче үк яңадан тәкърарлый башлый:

— Юк, юк, син җүләр түгел, мин җүләр, мин үзем, үзем...

Кулын минем кулдан ычкындырып, ул тагын учак янына утырды. Мин басып торам, карыйм, нәрсәнедер аңларга, хәл итәргә телим. Ә Фәһимә тып-тын. Аның учак ялкыныннан тагын да алланып торган иреннәре нәрсәдер әйтергә тели, мине якынрак чакырмакчы була, ахрысы. Ә күзләрендә моң. Мин анда күз яшьләре күрергә телим, юк, яшь түгел, алай булса бәлки җиңелрәк булыр иде... Аптырау газабын җинә алмыйча, мин аның каршысына килеп иеләм дә туп-туры күзләренә карыйм:

— Нәрсә булды, ник болай син?

— Ничек?

— Ничек икәнен белмим, тик элеккечә түгел.

Фәһимә елмаеп куйгандай итте. Күреп торам, ул миннән күбрәк аңлый, күбрәк белә һәм минем төшенә алмавымны өстән күзәтә төсле.

— Әйт әле, Әнис, — диде ул бераздан, зурларча җитдилек һәм катылык белән, — син мине монда калдырып китәргә җыенганда минем хакта уйладыңмы?

Нәрсә әйтергә белми аптырап калдым.

— Ә син яшермә, дөресен әйт, — диде ул баягы җитдилек белән.

— Нәрсә әйтим инде мин...

— Менә шул шул! Уйламадың син минем хакта...

Дөрес сүзгә җавап юк. Мин гаепле. Ләкин хәзер нишли алам, нишләргә тиеш?

— Нишләргә тиешлеген әйтә алмыйм, — диде Фәһимә, — тик мин синең турыда нәрсәдер әйтергә телим...

— Әйт соң...

— Үзем дә рәтләп белмим шул әле нәрсә әйтергә икәнен... Син... — Ул урыныннан торды, күкрәгемә сарылды һәм озак вакытка тынып калды.

«Син үзең өчен изге дип саналырга тиеш әйберләрне белмисен. аларны кадерле белмисен... Син беркайчан да яңадан табылмаячак иң зур нәрсәләреңне югалтырсың дип куркам мин. Син бернәрсәнең дә кадерен белмисең. Кадерен», диярга теләгәндер Фәһимә ул минутларда.

Ләкин тагын һичнәрсә әйтмәде. Сүзсез утырудан аптырагач, баян алып чыктым да күңелгә ни килә, шуны уйнап утырдым. Күпмедер вакыттан соң Фәһимә минем янга килде:

— Нинди көйләр уйныйсың син?

— Ничек, «нинди көйләр?»

— Мин беренче кабат ишетәм. Каян алдың соң син аларны?

— Алар үзләреннән үзләре чыга, уйнаган саен...

— Яле, яле, баягысын, соңгысын уйнап күрсәт әле тагы!

Моннан берничә минут уйнаган көйне кабатларга тырышам.

— Юк, юк, башы икенче төслерәк иде, — ди Фәһимә һәм көйләп күрсәтә:

**Сөясен дә кебек, сөймисен дә,**
**Әллә ничек синең карашың.**

Инде мин гаҗәпләнәм: көйнең сүзләрен беренче ишетүем.

— Син үзең бу сүзләрне каян алдың?

Җавап урынына Фәһимә сүзләрне тәгәлләп куя:

**Шул карашың я иркәли мине,**
**Я әрнетә йөрәк ярасын.**

— Менә, икебезгә бер җыр! — диде ул шатланып. Баягы уйчанлыкның эзләре дә калмаган иде анда бу минутта.

Икебезгә бер җыр, икебезгә бер мәхәббәт!..

* * *

Иртән ап-аяз иде. Агыйдел — яп-якты. Иртәнге нур белән чык пары кушылып бу гаҗәеп киңлекне тагын да матурлый, көн буена җитәрлек шатлык бирә. Мондый вакытта күңелгә рәхәт җиңеллек, күтәренкелек ургыла. Дөнья гел шулай булган да гел шулай булачак төсле. Ләкин тормышның күбрәк күргән крестьян агайлар мондый шигъри көннәр иртәсеннән соң нинди кич киләсен алдан сизенәләр.

Бүген дә картлар иртәдән үк безне бик ашыктырырга, әйдәргә керештеләр:

— Ягез, апалар, җәтрәк кузгалыгыз. Печән бик шәп кипкән. Ярты сәгатьтән ул сына-ватыла башлар. Кибәнгә салып өлгермәсәк, эш хәтәр.

Төшкә хәтле эш әйбәт барды. Төшлекне ашап хәл алырга яткач исә, озак та үзмады, безне өлкән иптәшләребез тавышы кузгатты:

— Җәмәгать, торыгыз! Яңгыр килә.

— Яңа чапкан печәннәр бөтенесе кибәдә, харап итәбез.

Сүзләрне куәтләп кайдадыр бик якында яшен чатнады. Минут та үтмәгәндер, бөтен халык кибәннәргә таба юнәлде. Көнбатыштан төн кебек кара болытлар ишелеп ага, алардан ут бөркелә, күк күкрәгән тавышлар ишетелә.

— Тимербикә, кибәнне бүген син куясың.

Тимербикә апа чәчкабын күлмәк якасыннан эчкә кертә-кертә (эшләгәндә җайсызлап тормасын диптер инде) кылганлыкка, калкурак җиргә күрсәтте:

— Менә шушында, алай булгач.

Тырмасы белән кибән салынасы төшкә күрсәткән арада ул горизонтка карады. Минем дә күзләр шул якка юнәлде. яңгыр болытлары безне читләтебрәк үтмәкче бугай. Шулай да бер башланган ашыгу тукталыр-

лык түгел иде инде. Халык хәрәкәте шулай бит, син аны, бер кузгалса, туктатам димә.

Чүмәлә тарттырганда атка эндәшүләр, бер-берсен өйрәтү, кычкырулар, тоташ тавыш агымына әйләнеп, болын өстенә таралды.

— Кырыйгарак, кырыйгарак! — Монысы чүмәләне кибән янынарак тарттыру өчен әйтелгән сүзләр була инде.



Чак кына арттырып әйткәндә, күз ачып йомарга өлгергәнче кибән яртылаш күтәрелде. Хатын-кыз күбәләрдән чүмәлә ясый, йөкләргә төйи. Искерәк чүмәләләрне аркан белән тарттыралар, соңынтын яңаларын да, кыенлык белән булса да, өстерәтә башладылар. Чүмәлә астыннан аркан чыга да китә, чыга да китә. Ат өстендәге малайлар да, чүмәләгә аркан чалучы кызлар да чиләнеп бетә. Кайберәүләр шуңа күрә күбәләрне мажарга төйи. Ничек кенә итмәсеннәр, эш бара, безгә — кибән янына печән өзлексез агыла. Без, үз чиратыбызда, ашыга-ашыга чүмәләләргә сәнәк кадыйбыз да һавага, кибән өстенә чөябез. Яртышар чүмәлә берьюлы оча. Каян киләдер мондый көч безгә. Сәнәкләргә сәнәкләр бәрелеп чыңлап китә, ухылдау, арудан авыр сулау, әче һәм төче сүзләр, шаян сүзләр, тупас тиргәшү — бөтенесе бергә.

Кибәннәр ишәйгәннән ишәя.

Кинәт бөтен җир өстен карангылык басты. Көчле җил исеп кибәнгә бәрелүгә, өстән Тимербикә апаның кинәт кычкыруы ишетелде:

— Бәтәмәч, тотыгыз, беттем!

Ул очланып килә торган кибән өстендә егылды да чак кына җиргә килеп төшмичә калды, тырмасы минем аякка очып төште. Каяндыр Фәһимәнең куркып кычкыруын ишетеп калдым. Тимербикә ападан бигрәк ни өчендер аны кызгану йөрәкне чәнчегәнен сизеп, аяк авыртудан йөз чытып, тырманы тиз генә алдым да шундук Тимербикә апага суздым. Тимербикә апа һични булмагандай яңадан эшкә керешә.

— Ипләбрәк, тагы сугып төшерүең бар, — диде ул, печәнне саксыз ыргытканымны ошатмыйча.

Ул да булмады, шыбырдап яңгыр яварга керешә. Яшен берөзлексез ялтырап җир өстен камчылады, күк күкрәве күкне туктаусыз калтыратып тотты... Һәм ун-унбиш минуттан соң дөнья тагын тынычланды: сәнәк чыкылдавы, хатын-кыз чыр-чуы, ат пошкыруы гына тукталмый калды. Кибән очлап киләбез икән, печән юеш булса да зыянсыз, диештеләр, соңыннан тагы күз күрер, җилләтеп алырбыз, диделәр. Тагын бераз эшләгәч, еракта, бу юлы көнчыгыш яктан, янә күк күкрәве ишетелде. Күк күкрәве? Юк, күк күкрәве түгел шул, әнә самолетлар... берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, унбер...

— Сугышка!

Кемнәрдер ут эченә китеп бара. Ә без... Печән өсте, җыр, бию, көлү... Офык инде болытлардан арынган, яңадан кояшлы. Шулай да бая яңгыр койган вакытка караганда күп мәртәбә карангырак төсле булып китте...

Тимербикә апа кибән башында тырмасына таянган да биектә һәйкәл кебек басып тора. Ныклабрак уйласаң, колхозчы хатын-кызларга шушындый бер һәйкәл кирәк иде бит... Хәзергә ул хакта уйларга вакыт та юк шул әле. Самолетлар гүләве бүтән уйлар уйлата. Күктә самолетлар... Алар югарыдан күбрәк күрәләр, күбрәк беләләр, курыныччын да, киләчәк матурлыкны да. Хәтта Тимербикә апа да кибән өстендә бездән күбрәкне күрә торгандыр. Аның күзенә ераклыклар киңрәк ачыла. Ул, чынлап та, күбрәк күрәме икән, карыймы икән?

Кичен, минма шәбәреп куышка кайтып егылу белән, жанны тынгысызлап торган шул соравымны әйтергә ашыктым.

— Тимербикә апа, әйт әле, син анда кибән башында торганда күп жир, күп авыллар күрәсеңме? Нәрсәләр күрәсең, ниләр уйлыйсың?

— Ни сөйлисең син, Әнис апаем? — дип сорады ул аңламыйча.

— Син анда өстә торганда тирә-якка карыйсыңдыр ич, еракларны күрәсеңдер.

— Нинди карау ди ул? Бүтән эшем юкмы соң?.. Менә әкият.

Аңлашылды. Горизонт. Синең горизонтың, колхозчы хатын-кыз, үз торган жиреңнән башканы күрмисең, теләгең юк, омтылышың юк. Авылым, туган жирем минем. Ул вакытта син шулай идең шул, аз күрә идең, сукыр диярлек аз күрә идең. Кичләрен өйләреңдә куыксыз, бишле лампалар яна, аны тычкан уты дип бик дөрес атыйлар иде. Ә кайчак бары тик чыра сөреме жилпенә. Сукыр гына түгел син, туган жирем, ул чакларда саңгырау да идең — өйләрдә радио юк, ерак хәбәрләрне ишетмисең... Мин ул дөньядан өскә ыргылырга, сикереп чыгарга теләдем. Минем күбрәк жир күрәсем, киңрәк горизонтлар карыйсым килә иде. «Әйе, мин сикерәчәкмен бу кыргыйлыктан. Ихтимал, ул чаклы зур эш иясе була алмам. Шулай да караңгылыктан чыга алу үзе үк зур нәрсә булачак, моны бик үк күпләр эшли алмыйлар. Агыйдел, Базы елгасы, Әшмән урманнары — минем кечкенә жанымның матур әсирлеге... тып-тын...»

— Әнис, син йоклыйсыңмы?

Фәһимә!.. Ул минем нәрсә уйлаганымны белми. Нечкә бармаклары белән чәчләремне тарый.

— Мин каядыр китәчәкмен, Фәһимә.

— Кая?

— Үзем дә белмим әле. Тик барыбер китәчәкмен.

— Исәр син. Әллә ниләр сөйлисең.

— Менә күрерсең, Фәһимә.

— Син алжыгансың. Йокла, тынычлан.

Йомшак куллар башымнан сыйпый:

— Акыллым минем!

Берничә генә сәгать үтәр, безнең алда тагын яп-якты күренешләр ачылыр. Бүгенге иртә кебек. Бүгенге түгел, иртәгесе көн икән. Күреп торам: без печән чабып-жыюны тәгәлләп авылга кайтып барабыз. Атлар, арбалар алда, аларга безнең иптәшләр, әйберләр төялгән. Олаулар ераклаша, без Фәһимә белән житәкләшкән хәлдә алар артыннан атлыйбыз.

Жир. Олы жир өсте. Мин жирнең чиксез-чамасыз киңлекләре буйлап атлыйм. Юлдашым — мәхәббәт. Икәүбез. Алда безне бәхет, зәңгәр горизонт балкышы шикелле бәхет көтә, шатлыклар көтә.

Атлыйбыз.

Икәү.

Башаклары иелгән арыш басулары, сабан ашлыгы дулкыннары, үйсулык, калкулыклар, юллар, урманнар, болыннар безне каршылыйлар, озаталар, хәерле сәфәр телиләр. Кояш, жәйге ягымлы кояш, ул да безгә елмая. Жир өсте киң, шундый киң, шундый яшел, шундый якты... Ләкин анда күләгәләр дә бар бугай. Әйе, күләгәләр. Шундый якты һәм

шундый яшел жир өстенә күләгәләр төшә: бомба йөртүче самолетлар күләгәсе, кылыч шәүләсе, мылтык, штык шәүләсе. Иртәнге тыныч жил әче төтен һәм кан исе китерә.

Атлыйбыз.

Декорация бер үк: кояш, зәңгәр күк, жир өсте.

— Акыллым минем!..

* * *

Авылга кайткач, минем ваемсызлык тагын да ачыграк күренде. Соңгы сүзне Фәһимәгә әйтә белмәгәнмен: кайчан һәм ничек кушәчәгебез хакында сүз куешмаган, алдагы көннәргә берниндн дә план кормаганбыз икән. Ул үзе дә сүз кузгатмаган, аның да балалыгы минекеннән бик үк ерак китмәгән, күрәсең. Беренче мәхәббәтнең асыл гадәте шундый инде, ахрысы, ул бернәрсә дә дәгъва итми, максат куймый, ярата һәм бары шул гына. Әгәр ул нилердер таләп итсә, хәтердә болай ук матур булып калмас та иде, бәлки.

Менә шулай, печән өсте вакытының кызчан матурлыгы, яшел дулкыннар урак өсте дигән икенче бер шау-шу, өлгерү чоры белән алышынды. Бусы тагын да кызурак, тагын да катлаулырак, ул бөтен табигатьнең төсен үзгәртә, соры загар белән бизи, кешеләрнең чәчләрен, киемнәрен уңдыра, ә кичерешләр... Хәер, мин ул чакта бу мәгънәдә уйлый белми идем бит әле. Мин бит хәзер генә болай «акыллыланып» киттем. Мин үземнең рухымда нинди үзгәрешләр тоячагымны күз алдыма да китерә алмый идем. Үзем, уйларым — болын киңлегедәй яшел, тыныч, бәхетле. Фәһимәдән хат килеп тора. Ул хәзер район үзәгенә күчкән, Гособеспечение дигән бер учреждениедә эшли. Яраланып кайткан солдатларга пенсия бирә торган бугай.

Печән өстендә әйбәт эшләвемне искә алып, Килмит миңа жаваплы эш бирде — комбайннан килгән ашлыкларны ындыр табагында кабул итүче весовщик мин. Монысы да кызыклы эш: ике весовщик — берсе мин — колхоз вәкиле, икенчесе МТСныкы, миннән бер-ике яшькә өлкәнрәк кыз. Ул МТСны алдатмаска, ашлыкның исәбен күбрәк чыгарырга тырышырга тиеш диләр. Ә мин колхоз мәнфәгате сакчысы: механизаторлар ашлыкны күп күрсәтеп, колхоздан артык түләтмәсеннәр. Мин үзем, холкым-гадәтем буенча, бер якның да алданмавын теләгәнлектән, учетны мөмкин кадәр дөрес алып барырга тырыштым.

Шулай менә — урак өсте. Ындыр табагы шау-гөр килә. Комбайннан килгән ашлык бәркәү астына бушатыла, олаулар килә, килә, иртәдән карангы төшкәнче. Без һәр килгән йөкне сиртмәле үлчәгеч белән үлчибез дә, әржәгә күпме сыйганын белгәч, чама белән шул санны язып куябыз. Болай эшләү ашлык ташучыларның вакытын алмый, безнең эш тә жиңелләшә, гомумән, жайлы. Йөк санын гына бутамаска кирәк. Бездән узган ашлык жилгәргечләргә китә... Жилгәргечләр әнә тыкылдыйлар да тыкылдыйлар — тәүлекләр буе. Алардан тагын олаулар сузыла: колхоз келәтләренә, дәүләт амбарларына, сугыш кырларына. Менә без нәрсә эшлибез. Шундый горур уй белән ашлык көшеле өстендә басып торам. Кыйммәте жиңү белән үлчәнәчәк бу кадерле бөртекләрне агач көрәк белән көрим. Йөкләр килә, алар килгән саен минем блокнотта бер сызык арта. МТС весовщигы да (кызның исемен хәтерли алмыйм хәзер) шуны ук эшли. Накладнойлар язабыз, ул да, мин дә кул куябыз. Бу эш тә минем бөтен уйларымны йота, күңелле, рәхәт. Шундый минутларның берсендә безнең янга үзенең бөтен тирәяккка таныш атын жиккән Сафуан абзый килеп төште. Мин көшел түбәсеннән күзәтәм. Тарантаста аның белән бергә ике хатын-кыз да бар икән. Сафуан абзый ат алдына солы салган арада хатын-кызлар тарантастан төшеп тирә-юньне күзәтә башладылар. Таныйм: берсе — безнә

укытып чыгарган укытучы, Зәйнәп апа. Икенчесе — Лена. Ул чакта мин аның турында менә нәрсә генә беләм: ул үзе кыш көне Уфада тора, җәйгә монда кунакка кайта. Клубларда, яшьләр компаниясендә, яки болай эш белән барганда күргәнем бар, ул Фәһимәләр авылында, безнең колхоз правлениесе урнашкан үзәк авылда әнисе белән яши. Исеме русчарак булса да, үзе — татар кызы. Шәһәрдә бертуган абыйсы республика Министрлар Советында җаваплы работник. Санаулы шәхесләрнең берсе. Башкортстанда аны һәр авылда беләләр. Лена, күз җитсә, аның янына китә.

Мин көшелдән алар янынарак төштем. Ленаның авылда сирәк очрый торган кыяфәтенә игътибар иттем. Аның кулында ниндидер газета. Ялан аякларында ул чактагы авыл өчен ят, мәзәгрәк туфли. Кара чәчәкле кыска ак күлмәге ничектер көч, терелек сиздереп торучы җитез хәрәкәтенә килешеп тора. Тазалык, дәрт ташып торган сыгылмалы гәүдә, табигать-художник дөрес сайлаган ап-алсу түгәрәк йөз, өлгергән иген төсе белән яраштырылган сары чәчләр һәм кашлар да бер караудә күзгә ташланып, ничектер, үзләре сәер, үзләре бик килешле иде. Кечкенәрәк күзләре дә очраклы түгел — өлгергән иген кырын бизәп торган зәңгәр чәчәк төсле. Йөз хәрәкәтләре җитез, минутына йөз кыяфәт алмашына. Даимирәк хәле — чын күңелдән елмаю, көлеп сөйләшү. Менә бу юлы да иң якын дусларга гына бүләк итеlә торган елмаю, ачык чырай белән килде ул минем янга.

— Исәнме, Әнис! Ник безне каршыламыйсың әле син?

Аның сүзен ишетүгә минем башта туган беренче уй шул булды: «Бөтенләй Фәһимәгә охшамаган!» Ә үзенә:

— Капкабыз ачык, теләсә кай яктан керегез, — дидем.

— Сезнең монда шәп! — дип кул бирде ул. Аннары өстәде: — Син, понимаешь, чын колхозчыга әйләнеп барасың.

Бүтән сүз тапмагач, шундый җавап белән чикләндем:

— Без кемнән ким?

— Ә синең өчен кем укыр? Кая җыенасың?

Дөресен әйтим, мин бу хакта бөтенләй уйланган кеше түгел әле. Кая да булса укырга керү минем хыялда үземне белә белгәннән бирле йөрсә дә, кешенең әкият күренешләрен якын итүе төслерәк кенә бер нәрсә иде. Укуның файдасызлыгы турында өйдәге сүзләр дә мине тәмам ышандырган иде бу вакытта. Мин Ленага бер генә сүз әйтә алдым:

— Белмим.

— Менә сиңа мә! Менә сиңа отличник! — дип сүзгә катнашты укытучы апа да. Алар мине укырга китәргә димләү өчен икәүләп, сөйләшеп килгәннәр иде шикелле.

Лена нечкә, ягымлы җиз тавышы белән чын күңелдән көлде дә миңа карады:

— Әлэктеме? Поделом сиңа. Мә, газет укы, анда кая китәргә икәне язылган. Сайла.

Якында гына урман, куаклык, сазлык. Йөкләр килгәне күренмәгәч, Зәйнәп апа тәкъдиме буенча куаклыклар арасына киттек. Лена миннән болында булган хәлләр турында сораштыргач, мин бик җанланып сөйли башлаган идем, ул:

— Әх, белгән булсам, мин дә барган булыр идем, — дип куйды.

— Нәрсәне белгән булсаң?

— Син барганны...

Моннысы инде кыеклап сөйләшү. Мин алай күп дәвам итә алмыйм, газетага карыйм. Газетаның соңгы битендә белдерүләр: кайсы техникумга, кайсы институтка керергә мөмкин. Мине, җиденче класс бетергән кешене, техникумнар кызыксындыра. Менә төзелеш техникумы. Анда минем абыем барып берничә ай укып кайткан иде. Геолого-разве-

дочный, авиация, консерватория... Консерватория? Консерваториягә безнең кебек авыл малаена эләгергә буламы?

— Карагыз әле, Зәйнәп апа... Мин аңлап бетермим бугай. — Игъланнарның шул консерватория турындагы кисәген төртеп күрсәтәм.

Зәйнәп апа газетаны укыган икән, ул аны карамыйча да җавап бирде:

— Гаҗәп түгел, безнең Совет власте һәркемгә тигез хокук бирде, теләсә кая юл ачык. Телисең икән, укы консерваториядә, рәхим ит!

— Зәйнәп апа! Булды, китәм!

Лена минем янга йөгереп үк килде:

— Булдымы? Китәбезме? Икәү барабыз, мина шәһәр таныш. Килә бит бәхет бер килсә!

— Син дә барасыңмы? Миңа күрсәтерсеңме шәһәрне?

— Киттек, бергәләп. Мин нәкъ шулай булыр дип уйлаган идем,— диде Лена, ниндидер эш башкарган төсле канәгатьләнү белән.

Ләкин шундук минем башка бер сорау килде:

— Ә Сафуан абзый җибәрерме икән?

— Нишләп җибәрмәсен,— диде Зәйнәп апа,— закон шундый, мактәп тәмамлагач, кеше теләсә кая китә ала, беркем дә тота алмый.

— Нинди хикмәтле законнар бар икән дөньяда! — Бу сүзне мин әллә шаяртып әйттем, әллә чынлап. Зәйнәп апа елмаеп куйгач, мин:

— Килмит мине укыту ягында түгел... дәрескә бармаска кушып та күпме динкеттеләр, сабанга йөрттеләр...— дип өстәдем.

— Әйдә, алайса, председатель янына бергә барабыз, сөйләшәбез.

Ул вакытта мин үземнең гаҗәп дәрәҗәдә йомшак күңелле икәнлегемне белә идем. Бер вакыйгадан соң ул бөтен авылга «фаш булды». Бервакыт урманнан куян баласы тотып алып кайткан идек. Куяннар бит кызык алар: балаларын табалар да ташлыйлар (берничә ел үтәчәк, үземне дә шул куян балалары белән чагыштыра башлаячакмын), нәни җан иясе үзе теләсә нишләсен. Без аны бераз исәйгәнче дип өйгә алып кайттык та берничә тәүлек әйбәтләп асрадык. Ә бер көнне безнең өй турында эт белән уйнап йөргән малайларның берсенә шундый уй килгән:

— Карале, бу этне куян тотарга өйрәтик әле!

— Ничек?

— Хәзер,— дип, кайсыдыр безнең өйдәге теге куянны алып чыкты да аны урам уртасына җибәрде. Икенче берәү яшь этне аңа өстерде. Эт «ә» дигән арада куянны барып та тотты, селкеп тә атты. Барсы да шаркылдап көләләр, ә мин урам тутырып елап җибәрдем һәм атна буе боегып йөрдем.

Менә шуннан китте инде мине мыскыллау. Ләкин хаклы мыскыллау түгел бу, мин үземне кирәкле урында нык та тота алам. Миңа җиде яшь дигәндә әти үлде безнең. Бөтен өй эче елады, ә мин, күпме генә эчтән өзгәләнсәм дә, түздем, күздән яшь чыгармадым. Йомшак кеше шулай эшли аламыни? Ә бүтәннәр мине аңламыйлар, «сугышка алсалар, фашистны да кызганырсың син!» дип көләләр. Эшнең киресенчә торганын исбат итү өчен шактый тырышырга, сәеррәк эшләр эшләп ташларга туры килә миңа. Ындыр табагына барышлый җай чыгып, Зәйнәп апага да үземнең ныклыгымны күрсәтергә ашыктым. Куаклыкта кош оясы очрады. Балалары авызларын ачып әнкәләрен көтә. Ояны йолкып кулга алдым да Зәйнәп апага күрсәттем:

— Менә, Зәйнәп апа!

— Ай, ник тидең аларга? Мескенкәйләрем, канатлары да чыгып өлгермәгән!

— Өлгермәсә дә очалар алар, апа, карап тор!

Бер кошчыкны һавага чөйдем. Зәйнәп апа еларга җитешеп ялвара:

— Нишлисең, Әнис, акылыңа кил!

Мин тагын бер кошчыкны очырам. Анысы да җиргә «лап» итеп килеп төшә.

— Ай, миһербансыз! Ай!

Ахырда ояның үзен күккә ыргыттым да батырларча кыяфәт белән:

— Көчсезләрне рәнҗетүдән куркырга ярамый. Югыйсә үзеңне рәнҗетерләр, — дидем.

— Син каян ишеттең моны? Кем әйтте?

Ә мин җавап бирмим. Чөнки тәгаен кемнән ишеткәнемне хәтерләмим.

— Их, Әнис, Әнис, консерваториягә җыенасың бит үзең! Абыең белән сөйләшмим болай булгач, үзең сөйләш.

— Ә ул мине тота алмый, закон шундый, мәктәп тәмамлагач...

— Эх, попугай!

Зәйнәп апа чын күңелдән тиргәшә. Лена чын күңелдән эче катып көлә. Ә мин хәзер генә нишләгәнемне аңламыйча көләргә дә, үкенергә дә белми аптырап калам. Йөрәктә соңыннан озак еллар буе мине газаплаячак бер сәер ачыну күәсе кузгалганын сизеп, башым иелә.

— Хуш, Зәйнәп апа, мин анда бармыйм әле.

— Исән бул, Әнис...

— Документларыңны әзерләп бетер дә минем янга кил! — дип кычкырды Лена, шактый ераклашкач.

Алар ындыр табагына китте. Мин, гомеремдә беренче тапкыр сәбәбе аңлашылмый торган сагышка бирелеп, кош балалары янына борылдым. Тереләр иде әле. Тиз-тиз генә бөтенесен бер урынга җыйдым да ояларын куакка яңадан урнаштырдым. Бәлки, үлмәсләр. Тик әйтә алмыйм, соңыннан ничек булыр. Хәзер чак кына җил чыкса да, ояның очып төшмәве икеле бит инде.

Каты күңелле булырга тырышуның ничек кыен икәнен белсәгез икән!

Шулай күпмедер азаплангач, эш урыныма килсәм — анда әллә никадәр халык җыелган. Сафуан абзый безнең гел шулай инде ул: фронт яңалыклары турында сөйли башласа, кырда күпме кеше бар, бөтенесе җыела. Бүген дә тарантас башына менеп утырган да, бөтен әрнүен, ачуын һәм көчен төсенә чыгарып, сөйли. Шпаргалка белән түгел, үзе нәрсә белә, ничек уйлый, ничек аңлый, шулай сөйли. Ул, билгеле, үзен тыңлаучы кешеләрнең нәкъ үзләренчә уйлый һәм аның ораторлык көче, сере бәлки нәкъ шундадыр. Югыйсә, ул институт бетергән лектор түгел ич...

— Гитлерчылар үзләрен социалистлар дип атыйлар. Алар бу сүзне юри пычраталар, хезмәт кешеләре буталсын өчен шулай лыгырдыйлар. Әгәр намуслы бандит булсалар, алар үзләрен вәхшиләр дип атарга тиешләр иде. Чөнки мондый да вәхшилекне тарихның әле очратканы юк. Алар безнең тиреләребездән перчатка, оек ясап кияләр, балаларыбызны тәҗрибә җәнлекләре урынына файдаланалар, кисәләр, каннарын суыралар, үтерәләр... Алар безнең пленныйларны мичләргә ягалар, телләрен, тәннәрен кисеп җәзалыйлар, хатыннарыбызны, кызларыбызны мәсхәрәлиләр, таптыйлар, асалар... Без шуларны кырып бетерү өчен нишләргә тиешбез соң иптәшләр? Соңгы сулышыбызны алганда да постыбызда калырга, иген үстерергә, фронтка җибәрергә тиешбез. Сез шулай эшлисез дә. Мин ышанам: тырышлыкны без киметмәбез. Безнең урамда да бәйрәм булыр, туганнар! Безнекеләр туктаусыз алга баралар! Берлин ягына баралар!

Сафуан абзыйны тыңлаган көнне без гадәттә кырдан бик соң кайтабыз. Бу юлы исә ындыр табагында эш төнлә дә тукталмады. Мотор тавышы басуларны төн буе әйләнеп йөрде.

* * *

Икенче төнне мин беркайчан да онытмаячак күңелле хәл булды. Монысы инде җанга рәхәтлек бирә торган.

Үзем белән бергә эшләүче весовщик кыз минем кырыйга, көшел өстенә менеп утырды да яшьлек, мәхәббәт турында матур-матур тарихлар сөйли башлады. Психикасы нормада булган һәркем утырдашының нәрсә уйлавын, тел төбен дип әйтик инде, аның сүзләренә, күзләренә, бөтен кыланышларына карап, әллә каян сизеп тора ич. Мин дә шулай, кызның ни теләвен беләм. Берничә көн инде гел минем белән ялгыз калырга тырыша ул, елмая, ике мәгънәле сүзләр куша... Мин аңламаганга салышам, сүзне икенчегә борам. Үземә кирәкмәгәнрәк сүз булса, мин гел шулай аңламыйчарак азапланам, яисә ишетмим. Ә сүзләрнең ияләре моның өчен мине ваемсыз, игътибарсыз дип гаеплиләр. Бу кызның да ачуы килә, күңеле сүрелә. Аннары бер читкә китә дә җырларга тотына.

Безнең сөйләшүдән бу юлы да рәт чыкмады.

— Әллә нәмәдәй егет син, — диде кыз ачынып һәм бераз сәерсенеп. Мөгаен, ул эчтән генә: «Минем кебек кыз да ярамагач, сиңа кем кирәк, харап, үзенне әллә кемгә куйган буласың тагы!» дип уйлый торгандыр. Ул үпкәләп бер читкә, куак янына килеп басты. Минем истә аның Фәһимәнекен хәтерләтә торган зифа сыны: әлинур күлмәк аркылы беленеп торган нечкә биле, Фәһимә чәчләренә бөтенләй охшамаган чем-кара кыска чәчләре. Җыйнак итеп җилкә турысында киселгән ул чәчләрне кичке җил шаярта, чуалта...

Кыз шул килеш калды, мин киттем.

Кая киткәнемне белмим дә икән әле. Ләкин менә барам, олы юлга, телеграм баганалары тезелеп киткән олы юлга таба барам. Мин анда, мөгаен, Фәһимәне очратачакмын. Мин ничектер инде көн буе шулай булыр төсле тоеп йөрдем бит. Әллә сагынам инде, әллә сагынудан шулай инде.

Олы юл тып-тын. Элек моннан тыз да быз автомашиналар уза иде... Хәзер аларның эзләрен җәяүле кеше эзләре таптап бетергән. Атлы арба эзләре дә сирәк. Ә бүген исә җәяүле дә күзгә чалынмый. Соң шул инде, кояш байый бит әнә, соңгы минутлары, кып-кызыл. Ул байый, мин аңа каршы атлыйм, кояшны түгел, Фәһимәне күрергә теләп атлыйм. Хәзер менә шушында мин язучы фантазиясе, матур ялган дип бәяләнергә тиешле хәл турында сөйлим. Күпме барганмындыр, чынлап та кояш батты, аның урынынаерактан таныш гәүдә күренде. Менә ул якынлаша, мин аңа каршы барам. Ул килә минем каршыга. Нәкъ җырдагы шикелле. Менә инде күлмәгенең төсе дә, чәчләр, йөреш гадәтләре дә ачык күренә башлады. Ул бит, ул бит бу! Фәһимә. Ул минем каршыга йөгерә, мин аңа таба. Ах, йөрәгем, бу нинди әкият! Бу нинди бәхетле, гүзәл әкият! Фәһимә! Син! Син дә ничек шатлачып кочагыма атылдың! Менә мин синең күкрәкләреңң җылысын, йөрәк сикерүеңне сизеп торам. Минем дә йөрәк дөп-дөп тибә, сизәсеңме син бу ярсынуны?

Кешеләр теләсә генә нәрсә әйтсеннәр, мин сизенү дигән бер хискә ышанам. Минем моңа дәлилләрем бар. Алдан һичбер хәбәрсез килеш кемне дә булса күреремә ышансам, ашкынсам, мин аны чыннан да күрәм. Сагынган кешем ярсынуымны сизә бугай, мин уйлаган җирдә булып чыга. Соңгы вакытта, ничектер, мондый хәлләргә очраганым юк, туры килгәне юк. Ахрысы, элекке кебек өзгәләнеп кемне дә эзләмим инде булса кирәк. Газеталарда галимнәр нинди дер телепатия дигән фән туу мөмкинлеге хакында бәхәсләшәләр. Миңа бәхәс кирәкми: мин бу фәннең барлыкка киләчәгенә, искитәргеч ачышлар китерәчәгенә ул чакта Фәһимәмне күрәчәгемә ышанган кебек ышанам.

Фәһимә! Синең кочагыңның бу чаклы да рәхәт, иреннәреңнең бу хәтле дә кайнар икәнлеген, кулларыңның бу кадәр дә йомшак, назлы икәнлеген мин әле белмәгәнмен икән! Әгәр бүген очрашмаган булсак, шушы рәхәт тойгы бәхетеннән мәхрүм булыр идем. Никадәр бәхетсез булыр идем!

Күктә инде йолдызлар җемелдәшә.

Кузгалабыз.

Җитәкләшеп юлсыз басу буйлап атлыйбыз.

— Күрәсезме, мин кем белән! — дип кычкырасым килә кешеләргә.

Бөркәү янында кешеләр сирәгәйгән. Калганнары ни өчендер безне күрмәмешкә салыналар, игътибар итмәгәндәй кыланалар. Ә минем белән эшләгән баягы кыз ындыр табагында безне күрүгә каядыр китте дә югалды. Нишләсен, хәерле булсын. Йөкләр санын без Фәһимә белән исәплибез, накладнойлар язабыз. Төн яртысы авышкач, йөкләр килүе тукталгач, озын-озын салам өемнәре янына киләбез. Саламны йолкып мин анда ике кеше сыярлык куыш ясыйм. Чакырганны да көтмичә, куыш әзер булуга, Фәһимә анда кереп, үзе миңа эндәшә:

— Белсәң, ничек шәп! Безгә өй дә кирәкми икән! Шушында гына тора алабыз!

— Мин сине хәзер моннан бер җиргә дә җибәрмим!

— Ә мин беркая да китмим, кусаң да!

Юрган урынына салам ябынып ятабыз. Һавадагы иң якты йолдыз, Сириус дигән йолдыз бугай, безгә карый. Яңа салам исе борыннарны кытыклый. Юк, салам исе түгел, Агыйдел болыннарында без чабып җыйган яшь үлән исе...

— Һавадагы иң якты йолдыз...

* * *

Лена белән кайчан ничек китәргә сүз куешуыбызны, ничек юлга чыгуыбызны һәм юлда баруыбызны хәтерләмим. Сәбәбен шуннан күрәм: бу вакыт һәркайчан Фәһимә хакында уйлану аркасында дөнья хәлләре минем хискә кагылмый узганнар. Ә менә Уфада йөри башлагач, ят обстановка булгангадыр күрәсең, күцел бераз үзгәрде һәм анда күргән кайбер нәрсәләр, сөйләшкән сүзләр хәтергә дә кереп калганнар.

Уфа. Пушкин урамы. Уң якта бөтен кварталны биләп торган соры йорт. Министрлар Советы бинасы, дип аңлатты Лена.

— Минем абыем шунда эшли.

Сул якта кечкенә сары йорт. Без шул йортка якынлашабыз.

Лена шәһәргә килгәч тагын да җыйнакланып, чибәрләнеп китте. Аягында замша туфли, өстендә алтын сыман һәм бераз яшькелтрәк, сирәк бизәкле күлмәк... Һәм үзен ул һәр җирдә өйдәге шикелле иркен тота. Аның белән рәттән атлаганда мин гаҗәпләнәм: шушындый чибәрлеге, чисталыгы белән, нинди иркен тормышы белән бу чатнап торган шәһәр кызы ничек минем белән йөри соң әле?

Сары йорт ишеге төбенә килеп җиттек. Лена ишек ачканда гына эчке яктан бер ир кеше күренде. Кеше ишекне ачты да Ленага карап тик тора. Ишек бит йөрер өчендер инде, карашып торыр өчен түгелдер? Уйлана торсыннар әле дидем дә, ир кеше ачкан ишектән ялт итеп узып та киттем. Әлеге кеше миңа баш чайкады:

— Эх, егет кеше, мин бит кыз кеше узып китсен дигән идем.

Лена үзенең җиз тавышы белән аны җөпләгәндәй итсә дә, мине хур итмәскә тырышты булса кирәк:

— Ул андыйны белми әле, шәһәрдә беренче көнне... Икенче тапкыр менә күрерсез... — диде.

«Нәрсәсен беләсең инде аның? — дип гаҗәпләндем мин.— Әллә нинди мәзәк кешеләр болар». Туп-туры коридор буйлап киттем: «Гаризалар кабул итү бүлмәсе» дип, коридорга аркылы кызыл комач элеп куйганнар.

Кердек. Ачык чырай белән урын тәкъдим иттеләр. Гаризаларны яшь кенә бер егет алып утыра. Күп булса, миннән биш-алты яшькә зуррактыр. Гаризаны ул миңа әйтеп торып яздырды. Башта Мәскәү дәүләт консерваториясе исеменә язарга кушты. Мин гаҗәпләнеп, «Свердловск консерваториясе түгелмени?» — дип сорагач, «Барыбер инде ул».— дип куйды. Мәскәү консерваториясе дә ул чакта Свердловскига күчкән иде булса кирәк. Гаризаның яртысын язгач, кайсы специальностька керергә теләвемне сорады.

— Баян буенча, — дидем мин.

Шул сүзне ишетүгә, безнең яндарак торучы бер өлкән агай мине труба классына керергә үгетли башлады. «Баян бит авыл клублары өчен генә, ә сез шәһәрдә дә эшли алыр идегез», — ди бу. Авыл дигәннән, музыка өчен авылдан да кулайрак урын бармыни ул... Дөнья яңгыратып тартып торып бер уйнап җибәрәсең. Юк, баяннан да әйбәт инструмент буламыни, бу кеше мине юри үрти ул.

— Мин бүтәнгә теләмим. Баянга языгыз.

Бәхәс бүтән дәвам итмәде. Гариза яздык. Бер атнадан имтиханга килергә куштылар. Бер атна өчен авылга кайтып торуның кирәге юк, көтәргә булдык. Лена үзе дә укырга керә икән, документларын геологик-разведка техникумына биргән, сынаусыз гына керә, авылдан отличник документлары табып килгән. Бүтән предметлардан минем дә имтихан тапшырасы юк, кулда «Мактау грамотасы». Тик консерваториягә, башка фәннәрдән имтихан бирмәсәң дә, музыкага сәләтеңне тикшерәләр, аңсыз алмыйлар.

Лена мине көтәргә булды һәм без аның белән көннәр буе шәһәр гизәргә керештек. Аларның абыйлары зур кеше булганлыктан, миңа аларга барырга ярамый. Көн саен иртән Лена минем янга (квартирны да минем өчен ул эзләп тапты) үзе килә торган булды. Олы бер шәһәрдә бүтән таныш кешем булмаганлыктан, мин аны көн саен көтеп алам. Килмирәк торса, зарыга башлыйм.

Уфаның Демьян Бедный урамы, ярый әле, авыл урамын хәтерләтә. Бер катлы агач өйләр, бакчалар. Коймa янында утыргыч та бар икән. Мин шунда утырып көтәм. Каршыда шәһәр паркы бугай. Анда репродуктордан җыр яңгырый. Лемешевның лирик теноры үзәкләргә үтә.

**Куда ни поеду, куда ни пойду,**
**А к ней загляну на минутку.**

Кич.

Кичке эңгер-меңгердә мин үземне шул җырдагы ямщик шикелле ялгыз хис итәм. Нишләп, ичмасам, килми тизрәк бу Лена! Аннан башка беркемем юк... Ул минем өчен бердәнбер дус һәм киңәшче. Чиксез далада икәүдән икәү калсаң, төнге куркыныч алдында әллә нинди чит кешеләр дә дуслаша бит. Ә без чит түгел, без бер үк җирдән, танышлар, танышлар гына да түгел, дуслар. Чөнки дус итмәсә, минем өчен болай йөрер идемени ул?

Ах, Лемешев, Лемешев! Син минем нәрсә турында уйланып утыруымны беләсеңме әллә? Югыйсә, минем кичерешләр турында бу кадәр дөрес итеп ничек җырлый алыр идең син! Мәнә син сөекле кызың белән булачак очрашуга канатланып очасың. Синең белән мин дә талпынам. Алда мәхәббәт мине дә һәрвакыт көтә, аның төсе үзгәрергә мөмкин, ләкин барыбер бер үк нәрсә ул — мәхәббәт. Әллә килмәс ди-

сенме? Әнә ул, бәлки... Тукта әле, мин арттырыбрак җибәрәм бит. Лена белән минем арада нинди мәхәббәт булсын! Әллә?.. Артык уйланырга вакыт юк, әнә ул үзе килә, Лена. Елмая. Һәрвакыттагы табигый, чын елмаюы белән елмая. Ап-ак туфли, аксыл ефәк күлмәк! Кулында — кулъяулык. Ул аны кичә миннән алган иде, юып китерә. Мин аның каршысына атлыйм, кулъяулык юган кулларын кысам, ул минем кулларны ычкындырмый, җитәкләшеп атлыйбыз. Соңрак шулай да мин кулны алгач, ул үпкәләгәндәй әйтеп куя:

— Минем белән йөрү сиңа күңелле түгел, әйеме?

— Таптың сүз! Мин сине көтеп алам.

— Шулай булгач, култыкла мине. Әнә тегеләр кебек. Күрәсеңме? Шәһәрдә шулай йөрергә кирәк.

— Мин шәһәр кешесе түгел бит.

— Барыбер өйрәнергә кирәк, югыйсә, соңыннан үзеннән көләрләр.

Шәһәрчә икән, шәһәрчә. Миңа сине култыклап йөрү үзе бер бәхет.

— Авыл малае белән култыклашып йөрүеңә кимсенмисеңме соң? Көлмәсләрме?

— Берни аңламыйсың син...

Шәһәрчәлекнең бөтен ягы килсен дип, аякларны да аның җаена (Лена кушканча) атларга көйлим, барып чыкмый. Ленаның вак адымына яраклаша алмыйм, аныңча атласаң, биегән төсле килеп чыга. Кызлар белән йөрим дип, кала буйлап биеп йөрер хәл юк әле. Үз белгәнемчә атлыйм.

Бакчаларга кердек, миңа таныш булмаган урамнар буйлап үтәбез, киноны керәбез. Кинотеатрның исеме дә хәтердә калган—«Октябрь».

Икенче көнне концерт.

Тып-тын.

Сәхнәдән акрын гына уйчан моңнар агыла башлады. Кичке караңгылык төсе белән бизәлгән бу тавышлар кабатлана-кабатлана нәрсәдер эзли. Аларга нәзек һәм үткен авазлар килеп кадала да фикер сыкраныш туктала һәм күп тә үтми яңадан кузгала, баягыдан да ярсыныбрак, үзенә ачык юл эзли. Баштагы үсүзле сорау хәл итүне көтә, таләп итә һәм газаплы уйлар упкынына ыргыла. Тик, харап булды дигәндә, кире чигенә: аңа уенчак, беркатлы якты көйләр каршы төшә. Болар — күптән түгел генә булган шатлыклы, аяз көннәр, күңелле дә, моңсу да. Агыйдел истәлекләре шикелле... Алар — хәтердә. Күңелдәгеләр телгә кайчан сөйләп булмый бит, яшерен теләк, яшерен омтылыш тыелып кала. Әмма бераздан ул тагы кыядыр талпына башлый, шул кадәр көч белән тыелып торган ашкыну тышка бәреп чыга, тынгысыз чишмәләр агымы төсле, язгы су шикелле шаулый башлый һәм ярларга, буага бәрелә, иркенлек дәгъва итә. Дулкыннар берсен-берсе имгәтәләр, вакыйгалар да, яңадан хәлләнеп, бәрелешләр кайнап торган урынга ашыгалар. Бу агымда ачу һәм соклану, горурлык һәм курку, өметсезлек һәм тантана. Боларның барысы да — дөньяны мин күргәнчә, минем күңелдәгечә, нәрсәнедер мин эзләгәнчә, мин әйтергә теләгәнчә. Минем уйлар, минем кичерешләр. Менә алар кайда икән! Әйе, ул көнне мин йөрәгемдә туганнан бирле йөрткән алламны таныдым:

— Бетховен!

Табигатьнең үзе кебек гади, мин аны аңлыйм. Табигатьнең үзе кебек үк катлаулы, ләкин мин аны аңлыйм. Үзе белән тыңлаучы арасындагы, минем арадагы озын юлда ул көчен югалтмый, ул минем күңелдә ярдәмче авторын таба, миндә үзен таба, Бетховенны!

Кимсетүле тавыш килә: «Тыйнаксыз!» — ди кемдер. Аңламаган кешеләр әйтә моны! Әйтсеннәр, бүгеннән башлап, мин бүтән кеше, бүген мин үземнең хыялым белән очраштым!

Мәхәббәт төсле, яшьлек шикелле матур, ярсу: көрәш мәйданна-

рында яңгыраган «Ура» тавышы төсле, нәфрәт шикелле дәгъвалы бу моңнар, бу чыңнар минем арттан ияреп киттеләр елларга, елларга...

Имтихан көне. Алар анда да мине озата килделәр.

Шәһәрдәге бердәнбер якын кешем Лена да бар иде. Мине әллә нинди озын бүлмәгә алып кереп киткәч, ул «переживать итеп» (үзе соңыннан шулай диде) ишек төбендә калды.

Башта үзем яраткан көйне җырларга куштылар. Ә мин кайсын ятарканымны белмим.

— Алай булса, теләсә нинди не,— диделәр.

«Сарман»ны сузам. Рояльдә уйнаулары («аккомпанемент» диләр аны сын) үземә дә ошый, Бетховен концертын хәтерләтә. Кемнәрдер астан гына елмаеп утыралар. Соңгы көннәрдә тыңлаган концертлардан соң, бүгенге «концерт» үзем өчен дә сәер иде. Бераздан үзләре бер көй уйнап куйдылар. Кабатларга куштылар. Мин кабатлый бардым. Тавышлар алышына тора, көйләр яңара, мин иярәм, татарча, русча.

Соңынтын, нинди инструментта уйнавымны белгәч, кулга баян тоттырдылар. Тагын «Сарман»нан башлап, аны бер кат уйнап чыккач, әкертен-әкертен өзек-өзек тавышлар, икеләнүләр узып, «Сарман» белән «Шомыртым» арасындарак торган көйгә күчтем, үзем дә ныклап аңламаган, шул минутта гына туган һәм онытылачак, кәгазьгә төшәргә өлгермәячәк, үземчә, авыл картиналарын төсмерләргә тиеш булган тавышлар агышына биреләдем. Беркөнге концерттагы кебек үк: көйләр алмашына, ялгана, үсә; аларның да чиге юк төсле, бу юлы тынса да, кабат яңарып, табигатьтә дәвам итәр төсле. Бетховен моңнары шикелле...

Уйнаудан тукталуга:

— Мин бу иптәшне бүтән җәфаламас идем, — диде бер иптәш. «Алмадылар» дигән уй кинәт тәнне чымырдатып узды шул чак. Калганнары да: «Мин каршы түгел», «Мин килешәм», дип сөйләнә башлагач, коелдым да төштем. Күзләргә яшь килде. Нәрсә булса да сорарлык хәл калмады. Аптыравымны аңлап булса кирәк, бер агай:

— Мин сезгә җыр классына керергә тәкъдим итәм! — диде.

— Юк, ул труба буенча керергә уйлый, — диде беренче көнне күргән мәхәббәтле кара агай.

— Ул бит баян буенча тели.

— Үзең ни әйтер идең? — диде мәхәббәтле агай.

— Җырчы булмыйм, авылда көләләр! — дидем мин ишетелер-ишетелмәс. Чынлап та ни йөзең белән күренерсең, «җыр өйрәнергә укырга кердем» дип кайтсаң? Кеше эшләп йөрсен, син җырлап йөр... Ә баян — башка, ансыз яши алмыйлар. Көлмиләр дә. Гармоньчы дигән дан бөтен район буйлап йөри. Минем теләк — Чайковскийны, Бетховенны баянда уйнау. Аннан соң дөньяда берни дә кирәкми. Белеп булмый, бәлки үзем дә композитор булып китәрмен әле.

— Мине композиторлар классына алсагыз иде, — дидем мин шул ук минутта кыюлыгыма, фикернең тиз алышуына үзем дә гаҗәпләнеп.

— Ярый, композиция буенча кабул итәбез, — диделәр, озак та көттермичә.

Монда әйтелгән сүзләр хәтердә шулай ачык булып, озак та үтмәстән: «Табигать биргән мөмкинлекнең берсе дә тормышка ашмады бит, берсе дә!» дип офтандырыр өчен сакланып калганнардыр инде, күрәсең.

Имтихан бүлмәсеннән чыккач, бөтен чырай-кыяфәтем әйтеп торгандыр, ахрысы, Лена, сорашып-нитеп тормастан, кочаклап алды:

— Котлыйм үзеңне, чертенок!

Шушы минутта мин аны яратканымны сизеп алдым. Әйе, бу — мәхәббәт бугай, Лемешев җырлаган мәхәббәт!

* * *

Уфадан пароход белән кайттык. Кеше искиткеч күп. Дүртенче класс дигәне — коридорлар, мичкә өсләре, идән... Шунда ике тәүлек чамасы кайтылды. Күңел күтәренке. Сәбәпсез дә, сәбәп белән дә көләм, таныш түгел кызлар белән дә, телләрен рәтләп белмәсәм дә, маржа кызлары белән дә шаярып алам.

Хәтеремдә, без тар гына коридорда утырып барабыз. Караңгы төшеп килә. Шулай да пароход эчендә ут кабынмаган әле. Лена бераз гына астарак, минем аркага башын куеп утыра. Уйлана бугай. Бүген беренче кат мин аны шушындый тын, боек кыяфәттә күрәм.

— Син авырмыйсыңдыр ич, Лена?

— Син берни аңламыйсың... Кара минем күзләремә.

Карыйм: күзләре яшь белән тулы. Эре-эре бөртекләре йомшак җәйге пальтосына тәгәрәп төштеләр.

— Син бернәрсә дә аңламыйсың, син — эгоист. Син минем күзләремнән бернәрсә дә күрмисең. Әйт, күрмисең бит?

Мин «эгоист» сүзен беренче кат ишеткәнгә күрә, аңламасам да, кабатлап сорамыйм. Күзләренә тагын да текәлебрәк карыйм:

— Күрәм, син елыйсың...

— Бүтән нәрсә күрмисеңме?

Ул, минем кулларымны чытырдатып кыскан хәлдә, артисткалар сыман башын артка җибәреп, һаман шул күзләре белән ялварулы карап тора. Мин аны ничектер кызганып куйдым. Йөрәгемне авыр хис урап алды. Үземнең дә күңелем тулды.

— Әйе, син бернәрсә дә күрмисең, күрергә дә теләмисең, — дип кабатлады ул.

— Күрәм! Күрәм!

Шул сүзне ишетүгә, ул кочаклап, башын минем иңгә китереп куйды. Юатырга тырышам. Мин аны рәнҗеткәнмен кебек. Ул минем очен күпме тырышты, ә мин... Үземне зур гаепле санап, мөмкин булганның барысын да эшләргә әзер идем мин бу минутта.

— Җитәр, Лена, елама, җитәр. Мин дә яратам, чынлап яратам!

Бу минутта ул миңа күкрәкләре белән сыенды, тагын да кайнаррак итеп кысты да, кинәт ычкындырып, шатлык очкынланып торган яшьле күзләре белән туп-туры караган хәлдә хәрәкәтсез калды. Иреннәре калтырангандай булды. Тәнгә шундый ук калтырану күчкәнен сиздем һәм кызны үземә таба тарттым. Ул янып торган иреннәрен иреннәремә китерде. Бөтен тәнне ярсытып кытыклаган бу иреннәрне мин беренче тапкыр татыйм... Мондый якынлык миңа таныш түгел, ул миңа әллә нәрсәләр вәгъдә итә, бу...

Пароходта кинәт ут кабынды. Кулларын тиз генә ычкындырды да Лена үзен тәртипкә китерә башлады. Сумкасыннан көзге чыгарды. Миңа үзе берничә кат юып китергән кулъяулык белән битләрен, күзләрен сөртте. Мин утырган мичкә өстенә иелде дә, җавап та көтмичә, үзенең дуслык хакындагы мәзәк карашларын сөйләргә тотынды.

— Мин бик көнче. Кара аны. Мин сине үземнән башка беркемгә дә бирмәячәкмен — син бары минеке генә булачаксың. Мин үзем синең өчен дөньяда мөмкин булганның барысын да эшләячәкмен. Без синең белән шундый итеп яшәрбез!.. Безне бергә күргән һәр кеше сокланмый калмас. Синнән дә, миннән дә бәхетле кеше булмас!

Төн уртасында безне пароход Исмаел дигән пристаньга китерде. Шунда төшәбез инде. Леналар авылына сигез чакрым. Безнекенә, турыдан кайтсак, унике. Алар авылыннан китсәк, унсигез чакрым җәяү кайтырга кирәк. Ләкин Лена белән бергә кайтырга мөмкин булганда, бүтән юлдан китә алмыйм.

Исмаел ярлары — биек тау. Шунда менәбез. Анда яшел чирәмлек, көтү йөри, ә тегендә, сул якта, болыннар, әле күптән түгел генә без эшләп кайткан болыннар... Мин кинәт өшеп, калтырап куям, күзләремне ул яктан күчерәм, башым иям... Ничек булды соң әле бу? Ничек булды?

Тиздән кояш чыгар. Ай да баемаган. Дөнья үзе якты, үзе күләгәле...

Идел буйлары инде ерак калды. Менә монда — урылган иген басуы. Унда да, сулда да, алда да. Тирә-як — алтын киңлек. Көлтәләрдән өелгән биек чүмәләләр. Алардан шундый тәмле ис килә, өлгергән иген исе! Печән исеннән һич ким түгел. Әйе, алар һәркайсы үз урынында. Шәһәр кешесе, мескен, нинди тәм татудан мәхрүм бит. Чүмәләләр, чүмәләләр, әйтерсең, алар кечкенә алтын өйләр... Аларның һәркайсы безне чакырып тора кебек:

— Безгә килегез, ял итеп китегез.

Чүмәләләр өй булса, бу басулар нинди искиткеч шәһәр булыр иде! Лена адымнарын акрынайта.

— Арыдыңмы, Лена?

— Әйе, йокым килә.

— Минем дә.

— Әйдә, менә бу өйдә йоклап чыгабыз. Анда безне көтәләр.

Лена йокылы күзләре белән елмаеп куя. Култыклашып юлдан ике йөз метр чамасы читтәге бер чүмәлә янында тукталабыз. Юл капчыкларын куйгач та баш очына арыш көлтәләре салабыз. Кызга чүмәлә ягына ятарга кушам: аңа анда җил тимәячәк. Август таңы ярыйсы ук салкынча. Аска минем пиджакны җәеп, өскә анның җәйге пальтосын ябынабыз.

— Мондарак, Әнис! Салкын...

Якынрак елышам. Башларын сыйпыйм. Кырда инде беренче кояш нурлары уйный. Ул нурлар Лененың алтынсу чәчләренә төшә. Бу чәчләр өлгергән арыш сабаклары төсле... Бу кашлар, керфекләр... башаклардан күчерелгән һәм матурлап ясалган төсле... Ә иреннәр... Бу иреннәр синең иреннәргә кушылганда бөтен кан тамырларың буйлап гаҗәеп тәм агыла — яңа гына өлгергән бодай бөртеге тәме, сөт сыман хуш исле, бодай суы тәме. Бу тәмне татыган кешеләр мине аңлар. Ленага хисләрем белән якынлашкан саен якынлашам, ә ул карышмый, тартынмый, бөтен тәне белән миңа омтыла. Бу минутта күз алдымнан болын киңлекләре, чәчәкләр чуарланып уза... Покослар, печән исе, куыш исе, чебен, черки безелдәве? Әйе, алар да хыялга кергән, чыкмаслык булып кергән. Ә менә урак өсте? Бөтен нәрсә өлгергән һәм үзенең тәмен татырга вәгъдә биреп торучы урак өсте? Аңардан киммени?! Юк, ким түгел бугай, син бу тәмне, табигатьнең серле тәмен татымыйча ничек калырсың. Менә Лена, юмарт август ае шикелле, шул серне ачарга вәгъдә биргәндәй, синең иркеңдә ята... Чәчәкләр сокланырга, хыялланырга яхшы, әмма аларны алыштырган җимеш тәме — бөтенләй башка, бөтенләй башка. Менә ул синең янында, сиңа сыенып ята.

Әллә йоклап, әллә йокламыйча, безнең арулар җилгә очкандай юк булды. Иртәнге кояш нурлары, чыклы арыш сабакларында җемелдәп, күңелгә әйтеп бетергесез шатлык агышы китерде.

Өсләрне кагып кигәч, капчыкларны аркага астык та әкияттәгечә якты алтын киңлекләр, арыш шәһәре урамнары буйлап, җитәкләшеп, алга атладык.

— Авылга һич кайтасы килми, анда өйгә кайтып керсәк, сине югалтырмын төсле,— диде Лена моңаеп. Мин шаярткан булдым:

— Әйдә, алайса, кайтмыйк.

— Әйдә! — диде ул да, чырае яктырып.— Минә бу авылда минем туганнарым бар, аларга кереп чәй эчик...

— Аннан кире шушы басулар, урманнар, таулыклар, чокырлар буйлап йөрик... Су коеныйк, чишмәләрдән сулар эчик, җимеш җыйыйк...

Ничек сөйләшенсә, шулай эшләдек тә.

Алар авылына — Ишкарга караңгы төшкәч кенә кайтып кердек. Ул үз өйләренә кереп китте, мин аларның күршеләренә, электән үк аралашып йөргән бер дус семьяга тукталдым. Әйберләрне калдыргач, урамга чыктым да авылның кичке авазын тыңларга керештем. Җәй көне шулай еракларадан килгән тавышларны тыңлап моңаерга яратам мин. Кайдадыр еракта арба шылтырап бара... Ул шылтырауда ниндидер яшерен мәгънә бардыр кебек. Ә тегендә, амбар тирәләрендә, шундый ук тыныч ритм белән җилгәргечләр такылдый, колхоз кызлары, колхоз хатыннарының йөрәк тибешен яңгырата... Ерак басуда трактор җир эшкәртә, аның туктаусыз гөрелтесендә кышкы салкыннар сизелгәндәй була, күңел кар астында калачак ябь-яшь уҗымны, нәни сабакларны кызгана. Якындарак кызлар җыры... Таныш тавыш бугай. Әйе, таныш. Тукта, кем, Фәһимә җырлый түгелме соң? Болай моңлы, бу чаклы матур итеп аннан башка кем җырлый алсын! Һава дулкынарында тирбәлеп, минем өчен шелтә төслерәк яманеу сүзләр ишетелә. Нинди җыр бу? Ул җырлыймы, әллә бүтән берәүме? Бераздан сүзләр аермачык ишетелде:

**Сине уйлап ята-ята,**
**Сызылып таңнар ата.**

Әйе, ул, Фәһимә! Кинәт туган бу ышаныч, күңелгә якын кешеңне очратканда була торган куаныч, үкенү сыман бер ачы хис белән бергә бутала. Күзгә әче яшь тыгыла. Юк, аны бүген күрергә, бөтенесен сөйләп бирергә... Ә аннан? Кайсын яратырга? Кайсы белән... ә мин кайсын яратам соң әле? Берсен генәме? Икесен дәме? Әллә берсен дә чын ярату белән ярата алмыймммы? Әллә мин ул хистән мәхрүммме? Фәһимә!

**Сөясең дә кебек, сөймисең дә,**
**Әллә ничек...**

Әллә ничек, кайчандыр үз йөрәгемнән чыккан көй бүген минеке түгел, аннан инде мин читләшкәнмен, үземнән үзем читләшкәнмен. Дөресрәге, көй элекке бугай, әмма сүзләр... Сүзләр күбәйгән һәм ерактан ачык ишетелмәүләре белән тагын да серлерәк, тирәнрәк, мәгънәлерәк тоелалар. Мин тавыш килгән якка чабарга телим, үз йөрәгемнән чыккан моңнарны үземә кайтарырга телим, яңадан аның белән кавышырга... Тик...

Якында гына, минә шушы өйдә — Лена бар! Ул — өйдә, куыклы лампа уты яктысы тышка сирпелә. Шул яктылык эчендә, пәрдәләрнең кушылмый калган урыннары аша, ашыга-ашыга Лена узып йөргәне күренә. Мөгаен ул, минем янга чыгарга ашыгадыр. Ә мин? Нишләргә минә?

...Югары яктан, печән төягән арбага утырып, ике кеше узып китте: абыйсы белән... Фәһимә! Күрешкәч нәрсә әйтермен, белмим, ләкин аны күрергә кирәк. Мин аны күрмичә булдыра алмыйм.

Шулай үрсәләнеп торган хәлемдә минем кемдер арттан кочып алды. Әлбәттә, Лена.

— Киттек, Әнис! Клубка. Уфадан артистлар килгән, — дип, минем үз өрмәсенә буйсындырып, җилтерәтеп алып та китте ул.

Минем нәрсә кичергәнне башына да китерми, теленә ни килде шуны сөйли, шаяра, көлә.

Клубка кердек. Анда халык аз әле, билет алдык та яңадан урамга чыктек. Анда таныш-белешләр белән күрешәбез, сөйләшәбез. Кайсылар бирәү безнең арттан:

— Фәһимә дә кайткан! — дип калды.

Ялга каршы көн, әниләрен күреп китим дигәндер инде.

— Кайтса соң, ни булган! — диде Лена, исе китмичә генә.

Яңадан клубка кердек һәм янадан ишек төбендә туктaлдык. Үзем Лена белән сөйләшәм, үземнең күзләр әллә кайда. Ул бугай... Юк, ул түгел, хәтта охшамаган да. Менә монысы... Чигәсенә төшкән җиңел бөдрәләре... Ул! Үзем дә сизмәстән бер адым алгарак чыктым. Лена да минем белән... Фәһимә монда да фронттан яраланып кайткан абыйсы белән икән. Мине күрүгә башын иде... Әллә күрмәде. Каршысына китәр идем, уңайсыз, Лена монда. Үзе безнең янга килер әле, шуны көтәм, нигә көтәм — үзем дә белмим. Ленага карыйм. Көләчлеге — җилгә очкандай, күзләре чебешкә ташланырга җыенган карчыга күзләре төсле яна, ялтырый. Шулай да, дулкынланганын тышка чыгармаска тырышып, иң өстә яткан сүзләрен миңа житкерә...

— Нишләп җыелмый инде бу халык?.. Уфа кадәр Уфа артистлары килгән.

— Театр кайгысы түгел шул хәзер. Бүтән кайгы.

— Өйдә ятып кына кайгыны җиңеп булмый инде, барыбер...

Лена, тукта, барыбер ишетмим, ул килә, менә безнең турыга килеп житте, мин аның белән исәнләшәчәкмен, күзләр генә очрашсын. Әйе, ул атлый, тик, әйтерсең, безне күрми, әйтерсең, мин аның өчен юк, мин аның өчен чит, таныш түгел. Үзенең сыгылмалы, салмак хәрәкәтләрен тамчы да үзгәртмичә, каядыр югарырак караган хәлдә тып-тыныч атлап узып та китте ул. Ә мин, мин аның артыннан йөгереп китәргә теләдем. Көчем житмәде һәм ул шуннан, әлбәттә, бөтенесен аңлады. Әйе, без бит аның белән нindидер яшерен көч ярдәмендә бәйләнгән идек, ул минем ни уйлавымны әллә каян белә. Хәзергә ачылмаган бу уртаклык законын бер заман галимнәр ачарлар әле, күрерсез, барыбер ачарлар. Ләкин бүгеннән соң бу бәйләнеш турында башка да китерергә мөмкин булмаячак. Ничек узып китте? Әйтерсең, мин дөньяда юк. Ә мин соң аны йөрәктән чыгара алырмынмыни!

Спектакль нәрсә турында баргандыр, концертта нәрсәләр башкарылгандыр, хәтерләмим. Дөресрәге, мин аларны ишетмәдем бугай. Лена белән ничек очрашачагыбыз турында килештек бугай. Аның белән ашыгыч саубуллаштык та, юл әйберләрен алып, үзебезнең авылга, Әшмәнгә ашыктым. Анда мине бу газаплардан, каршылыклы кичерешләрдән арыну мөмкинлеге, тынычлык көтәдер кебек иде.

Болытлы төн — дөм-караңгы. Юл бераз пычранып та өлгергән икән. Ялгызым, төнге юлдан атлыйм да атлыйм. Күз алдымнан, миңа игътибар да итмичә горур атлап, һаман Фәһимә узып китә.

Үзебезнең урманга да життем менә. Юл күренми, урман читеннән чамалап кына барам. Сазлыграк жир башлана. Вак куаклыклар эчендә төн тагын да карала төшә. Кая барамдыр, миңа барыбер бугай.

Шул вакыт кинәт нәрсәгәдер бәрелеп... Юк, бәрелеп түгел, нindидер штык сыман каты нәрсә күкрәгемә кадалудан чак кына тайпылып, тукталып калдым. Каты әйбернең чайкалып мине читкә ыргытуын сиздем, тик егылмадым, һуштан язгандай читтә катып калдым. Күземә коточкыч бернәрсә чалынды. Ул да тукталган, тын гына миңа карап тора икән, ләкин куарга исәпләми, күрәсең. Таныйм, бу — безнең колхоз үгезе ич, миңа каршы атлап, юлдан килгән, ә мин аның мөгезләренә килеп бәрелгәнмен... Мин моны үзем өчен нәрсәгәдер ишарә сыман кабул иттем...

Өйгә кайткач, өстәлдә хат көткәнен күреп, ашыгычлык белән шул хатны ачтым. Мин шәһәргә киткәч үк килгән икән. Таныш почерк. Фәһимә хаты! Бәлки соңгысыдыр. Бәлки менә бу кадерле сүзләрне мин соңгы тапкыр укыймдыр.

Ул курешү көнен ничек ашкынып көтүе хакында язган, киләсе атнага ялга кайтачагын әйткән, әгәр шәһәрдән кайтып житсәм, үзе кебек сагынсам, килергә кушкан. Соңыннан мәгънәсе миңа инде таныш булган баягы жыр язылган:

**Сөясең дә кебек, сөймисең дә,**
**Әллә ничек синең карашың.**
**Шул карашың я иркәли мине,**
**Я әрнетә йөрәк ярасын.**

**Сөясең дә кебек, сөймисең дә...**
**Мәхәббәт соң әллә уенмы?**
**Күңелең әгәр башкаларга төшсә,**
**Чынын әйтү сиңа кыенмы?**

**Сөясең дә кебек, сөймисең дә,**
**Шаяртыпмы, бәгырем, йөрисең?**
**Ташлар булсаң, — ятны башлар булсаң**
**Әйт дөресен, күңелем сүрелсен.**

Сизенгән, әлбәттә, сизенгән. Лена белән киткәнемне ишеткәч язгандыр... Мөгаен. Әйе, язылып бетте — икебезгә бер жыр. Ә мәхәббәт?

Утны сүндерәм дә йокларга ятам. Әз генә булса да йоклый алырмын, ял итәрмен дип өметләнмим дә. Колакта бертуктаусыз чыңлап таныш көй ишетелә: «Сөясең дә кебек, сөймисең дә...»

Караңгыда, әле озак барылачак юл өстендә мине баягы үгез көтә һәм күзем йомган арада аңа бәрелермен кебек, күзне йомарга куркып ятам. Куркам, сискәнеп китәм.

Бәрелермен кебек...

*(Дәвамы бар.)*

# *Татар театрына 60 ел*

Тарихның якты, бәхетле сәгатьләрендә, күп шатлыклы, яңа идеяләр рус чынбарлыгының йокыга талган ярларын океан корабыдай уятып җибәргән, давыллы хисләр ташкыны хөрриятнең көчле авазы белән үзенә юл ярган көннәрдә, яшьләрнең каһарманнарча тырышлыклары нәтиҗәсендә, татар театры туды.

**Мулланур ВАХИТОВ.**

## БӘЙРӘМ БЕЛӘН

**1906 елның 22 декабре (яңа стиль белән 1907 елның өченче январе) профессиональ татар театры туган көн булып исәпләнә. Шул көнне Казанда беренче ачык спектакль уйнала.**

**1907 елның маенда Ильяс Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге театр труппасы Россия шәһәрләре буйлап гастрольләргә чыга, халыкка үзенең спектакльләрен күрсәтә башлый. Бераздан труппага Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская килә. Габдулла Тукайның «Мәдхия» исемле мәгълүм шигыре нәкъ менә аңа — иске гореф-гадәтләргә һәм шәригать кануннарына каршы барып, сәхнәгә менгән беренче артисткабыз Сәхипҗамал ханым Волжскаяга багышланган:**

Күр, ничек иртә кояш чыкса, җиһанда нур тула;
һәр күңелләр нурланадыр, чыкса Гыйззәтуллина...

**Аның сәхнәгә менүе реакцион даирәләр өчен аяз көнне яшен яшьнәү белән бер була. Тагын бераз вакыт узгач, 1907 елның август аенда, әлеге труппага, артист булып Габдулла Кариев керә.**

**Милләтчеләр, фанатик дин әһелләре театр артистларын төрлечә кимсеткән һәм эзәрлекләгән, театрны бөтенләй ябу хакында махсус карарлар чыгарган бер вакытта, халкыбызның Х. Ямашев, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Коләхметов, Г. Камал кебек алдынгы карашлы уллары милли театрга зур өмет багладылар, аны яшәтү, үстерү өчен көчләрен кызганмадылар. Күренекле революционер М. Вахитов, беренче татар артистларының фидакарь хезмәтенә югары бәя биреп, болай диде: «.. Кариев, Болгарская, Байкина — якынлашып килгән яңа тормышның беренче ягымлы нурлары, киләчәк буыннар шатлыгы өчен үз-үзләрен аямыйча, армый-талмый эшләүчеләре... Алар икейөзлелек һәм бозыклык белән тулган бай аристократ салоннарыннан түгел, бәлки халык арасыннан күтәрелделәр һәм мещанлык мәрәле белән пычранмаган саф җаннарын чын гуманистик сәнгать өчен корбан иттеләр».**

**«Сәйяр» — ил гизүче, сәяхәтче дигән сүз. Беренче профессиональ театр труппасына бу исемне Габдулла Тукай биргән иде. Труппа коллективы «Сәйяр» исемен тулысынча аклады. Шәһәрдән-шәһәргә йөрүче күчмә театр тамашачыларны яктылыкка, азат тормышка өндәде һәм халык алдындагы изге бурычын намус белән башкарды.**

**Авыр, кыен шартларда яшәвенә карамастан, татар театры гел үсә, ныгый, камилләшә барды. Россиянең әле бер, әле икенче почмагында яңадан-яңа коллективлар, труппалар төзелә торды. Сәхипҗамал Волжская, бер төркем артистлар белән Уфага китеп, анда «Нур» исемле труппа төзи. Ә 1915 елда Оренбург шәһәрендә «Ширкәт» исемле өченче театр труппасы эшли башлый...**

**Реализм традицияләрендә тәрбияләнгән, халыкка хезмәт итүнең гүзәл рухы белән сугарылган татар артистлары Бөек Октябрь революциясен пролетариат язучысы Максим Горькийның «Мещаннар» исемле әсәрен куеп каршыладылар...**

Гражданнар сугышының беренче көннәреннән үк татар артистларының барлык труппалары фронтка китә, халыкны интервентларга каршы актив көрәшкә туплый.

Совет власте елларында театр зур һәм данлы юл узды. Менә татар совет театр сәнгате узган зур юлның кайбер баскычлары:

1920 ел, 25 июнь.

Татарстан Автономияле Совет Социалистик республикасы төзелү уңае белән, Казанда милли театрга символик нигез салу үткәрелә.

1922 ел, 8 ноябрь.

Республиканың башкаласы Казан шәһәрендә Кызыл Октябрь исемендәге Беренче татар дәүләт театры ачыла.

1923 ел, 1 январь.

Казанда татарның атаклы артисты Габдулла Кариев исемендәге театр техникумы эшли башлый. Режиссер-педагоглар итеп Кәрим Тинчурин, Зәйни Солтанов, З. Соловянова билгеләнә. Студентларны композитор Салих Сәйдәшев, язучы Фатих Әмирхан укыта.

1926 ел.

Татар театрының егерме еллык бәйрәме үткәрелә. Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Бари Тарханов, Мохтар Мутин, Зәйни Солтанов, Кәрим Тинчурин, Касыйм Шамил, кебек сәнгать осталарына Татарстан АССРның атказанган артистлары, ә Г. Камалга Татарстанның халык драматургы дигән мактаулы исемнәр бирелә. Шул еллардан алып театрыбыз Татар дәүләт академия театры дип йөртелә башлый.

1939 ел.

Театрга Галиәсгар Камал исеме бирелә.

1957 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы уздырылды. Академия театрының спектакльләрен тамашачылар гаять җылы каршылады, Мәскәү театр җәмәгатьчелеге татар артистларының уенына югары бәя бирде. Татар совет театр сәнгатен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен, театр Ленин ордены белән бүләкләнде.

Исемнәре бөтен илгә мәгълүм бик күп язучыларның һәм артистларның, режиссерларның һәм художникларның иҗаты шушы театр, аның 60 еллык бай тарихы белән бәйләнгән.

Хәлил Әбҗәлилов, Фатыйма Ильская, Галия Булатова, Хөсәен Уразиков, Фуат Халитов, Гөлсем Болгарская, Камал III, Габдулла Шамуков, Гөлсем Камская, Нәҗип Гайнуллин, Хәким Сәлимҗанов кебек сәхнә осталарының уенын күреп кем генә сокланмады икән!

Г. Ибраһимова, Р. Җиһаншина, Р. Хәйретдинова, Ш. Әсфәндиярова, В. Минкина, Г. Надрюков, Д. Ильясов, Ш. Биктимиров, А. Хәйруллина, И. Солтанов, Ф. Кульбарисов, И. Гафуров, Р. Бикчәнтәев, А. Галиева, Н. Гәрәева, Р. Таҗетдинов, Н. Ихсанова, Г. Исәнгулова исемнәре тамашачыларга яхшы таныш.

Яшәвенең беренче елларыннан ук татар театры, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Колахметов әсәрләреннән тыш, рус һәм чит ил драматургиясенең иң яхшы үрнәкләренә мөрәҗәгать итә килде.

Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, М. Фәйзи, Ә. Фәйзи, Ш. Усманов, Ф. Бурнаш, һ. Такташ, Ф. Сәйфи-Казанлы, Т. Гыйззәт үзләренең әсәрләре белән татар совет театрын яңа югарылыкка күтәрделәр.

Н. Исәнбәт, М. Әмир, Р. Ишморат, Ф. Хөсни, Г. Минский, Х. Вахит, Ш. Хөсәенов, А. Гыйләҗев һәм башка драматургларның әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләр тамашачыларның мәхәббәтен казанды.

Халкыбызның горурлыгы һәм мактанычы булган Татар дәүләт академия театры соңгы елларда үзенең үсешендә яңа биеклеккә күтәрелде. Ул заман белән, бүгенге тормыш белән бер адымнан барырга омтыла.

Беренче мәртәбә театр ишекләре ачылган көннән соң 60 ел вакыт узды. Бу алты дистә ел эчендә театр зур һәм катлаулы үсеш юлы үтте, ул һәрвакыт үзенең тамашачыларына акыллы киңәшче, яхшы дус булды.

Хөрмәтле иптәшләр!

Татарстан Язучылар союзы идарәсе, «Казан утлары» журналы редакциясе Сезне чын күңелдән зур бәйрәмегез белән котлыйлар, эшегезне, данлы юлыгызны тагын да зур уңышлар белән дәвам итүегезне телиләр.

*Ильтани Иляловa*

# ҮРНӘК БУЛЫРЛЫК ИҖАТ

**50** ел!.. Һәр көне, сәгате, хәтта минуты да гаять күп көч сарыф итүне, арУталуны белмәстән өзлексез эзләнүне сорый торган, кешенең бөтен барлыгын — талантын, физик һәм акыл көчен үзенә сендереп бара торган иҗади хезмәт белән үткән еллар. Һәм алар бөтенесе дә бер кешенеке — бөтенесе дә халык артисты Фатыйма Ильскаянныкылар.



Беренче тапкыр сәхнәгә ул революция алды елларында күтәрелде һәм үзенең сәнгать юлындагы беренче адымнарыннан ук тамашачыларда югары әхлак принциплары тәрбияләү өчен көрәшә башлады. Театр сәхнәсе аның өчен чын мәгънәсендә көрәш аренасы булып әверелде. Аның Ильская дигән фамилияне йөртүе дә тикмәгә генә түгел бит. Хәтта шуның белән дә ул үзенең иленә, халкына хезмәт итәргә омтылуын белдерде.

Фатыйма Ильская театрга килүенең беренче елларында ук күп уйный. Төрле чак була: аерым эпизодларда да, төп рольләрдә дә уйнарга туры килә. Ул Г. Камал, К. Тинчурин һәм чит ил драматургларының әсәрләрен куюда катнаша. Революциядән соң, әле 1918 елда ук, бер төркем актерлар белән бергә Фатыйма Ильская Мәскәүгә бара. Башкалада үткән айлар, МХАТ һәм башка театрларда булу, атаклы рус актерларының уенын күрү яшь актриса өчен осталыкка ирешү юлында менә дигән мәктәп була.

Электән кимсетелеп, кыерсытылып, эзәрлекләнеп-кысылып килгән татар театр сәнгате революциянең беренче елларында ук бик нык үсте. Бөтен Советлар иле гадәттән тыш үзгәрешләр кичергән давыллы һәм ялкынлы көрәш еллары иде ул. Патша Россиясе тарафыннан тәмам коллыкка төшерелгән һәм Октябрь революциясе көннәрендә азатлык яулап алган халык кинәт авыр йокыдан уянып киткәндәй була, бөтен көче белән яңа тормышка, яктылыкка омтыла. Тиз арада театрлар оештырыла, мәктәпләр төзелә, югары уку йортлары ачыла. Әмма дошманнар да кул кушырып утырмыйлар, ачыктан-ачык та, астыртын төстә дә яшь Совет Республикасына каршы көрәш алып баралар, һәртөрле юллар белән социалистик җәмгыять төзелешенә аяк чалырга маташалар. Әлбәттә, бу көрәш театрны да читләтеп үтә алмый. Мондый шартларда театрның кем файдасына эшләве аның тамашачыга нәрсә күрсәтүе һәм ничек күрсәтүе белән билгеләнә. Халык театрга тормыш мәктәбе итеп карый. Әнә шуна күрә дә театрның үз эчендә реализм тарафдарлары белән формалистлар арасында башланып киткән көрәшнең кем файдасына хәл ителүе аеруча зур әһәмияткә ия була. Әйтергә кирәк, Г. Камал исемендәге татар театры бу көрәштә сынатмый һәм тиз арада тамашачының хөрмәтен яулап ала. Мондый уңышка ирешүдә аның труппасында Кәрим Тинчурин кебек җитәкченең, М. Мутин, М. Әпсәләмов, Ш. Шамилский, К. Шамил, Н. Таҗдарова, Н. Арапова, Г. Болгарская, Ф. Ильская кебек артистларның булуы

хәлиткеч роль уйный. Алар тормышчан һәм чынбарлыкны дөрес сурәтләүче сәнгать өчен бөтен көчләрен биреп көрәшәләр.

Баштагы елларда Фатыйма Ильскаяның иҗаты әнә шундый вакыйгалар эчендә кайнап үсә. «...Аның талантының нәфис чәчкәсе татар сәхнәсенең элекке кояшсыз, карангы, авыр көннәрендә ачылды. Азат илнең азат сәхнәсендә ул тагын да гүзәлрәк булып чәчәк атар»,— дип язды Һади Такташ Ф. Ильскаяның Совет властеның беренче елларындагы иҗаты хакында.

Чынлап та, еллар үткән саен актрисаның иҗаты һаман үсә һәм ныгый барды. Тамашачыны кешелеклелеккә, тормышның гүзәллеген тоеп, көр күңел белән яшәргә чакыру тавышы көчлерәк яңгырый башлады. Ул иҗат иткән образларның һәркайсы кешегә ихтирам һәм олы мәхәббәт хисләре белән сугарылган. Актриса үзе иҗат иткән образлар аша тамашачының йөрәгенә үтеп керергә, аны саф күңелле, үз кадерен һәм дәрәҗәсен белә торган, зур хәрефтән язылырлык Кеше итеп тәрбияләргә омтыла.

Әле кырыгынчы еллар башында ук Гадел Кутуй ана, татар сәнгатендә гаҗәп бер талант, дип бәя бирә. «Ул иҗат иткән образларда,— дип яза Гадел Кутуй,— рухи гүзәллек күп, ул хатын-кыз йөрәгендәге серләрне ачып бирү сәләтенә ия... Ильская һәр образда үзенә бертөрле һәм беркайчан да үзен-үзе кабатламый. Ләкин аларның барысы өчен дә уртак сыйфатлар хас: бу — гадилек һәм тормыш дөреслеге». Сүз дә юк, бик дөрес тотып алынган һәм бик төгәл әйтеп тә бирелгән. Тик, Гадел Кутуй фикерләрен дәвам итеп, тагын шуны өстисе килә: Ф. Ильская иҗат иткән образларның барысы өчен дә уртак булган сыйфатлар моның белән генә бетми әле. Образлардагы шигърият һәм нечкә күңеллелек, рухи байлык, хатын-кызларга хас булган гаҗәеп бер эчке матурлык сыйфатларының искиткеч терелек, шаянлык-шуклык белән үрелеп баруларын да әйтеп үтәргә кирәк. Ильская иҗатында тормыш чынбарлыгының дөрес чагылышы һәрвакыт романтик төсмерләр белән дә бәйләнеп баралар бит.

Фатыйма Ильскаяның илле ел дәвамында уйнаган рольләре — ә аларның саны йөздән артык — күп төрлеләр. Аларның күпчелеге классик репертуарда иҗат ителгән образлар: Шекспир трагедияләреннән Джульетта, Дездемона, Корделияләр; Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» драмасыннан Луиза белән Мильфорт; Гольдониның «Кунак өе хуҗасы» комедиясеннән Мирандолина; Лопе де Веганың «Печән өстендәге эт» комедиясеннән Диана; Бомаршеның «Фигароның өйләнүе» комедиясеннән Сюзанналар. Рус классикасыннан һәм хәзерге чор совет драматургларының әсәрләреннән алынган рольләр дә бар. Һәм, әлбәттә, иң күбе татар язучыларының пьесалары буенча иҗат ителгән образлар: Айсылу («Ташкыннар»), Фатыйма («Тормыш җыры»), Камилә («Хаҗи әфәнде өйләнә»), Рәүфә («Рәүфә»), Мәргыйзә («Хөррият»), Кәүсәрия («Карлыгач канат кага») һәм башка бик күпләр.

...Шат күңелле Сюзанна. Ул — көләч һәм шаян. Матур һәм зур күзләреннән очкыннар сибелә. Аннан бетмәс-төкәнмәс дәрт, тазалык һәм көч бәркелеп тора. Ул Альмавиваны бик оста хәйләли һәм үз сөйгәне Фигароның турылыклы ярдәмчесе булып китә. Сюзанна-Ильская бик чибәр, ягымлы һәм бераз гына кыланчык та.

Ә берничә елдан соң Ильская Таняны (А. Арбузов, «Таня») уйный. Бусы инде бөтенләй икенче төрле характер. Тамашачы каршына ул башта үз иренә чиксез дәрәҗәдә гашыйк булган һәм үз тормышының төп мәгънәсен дә аңа хезмәт итүдә генә дип ышанган беркатлырак яшь хатын булып килеп баса. Әмма ул һаман үсә, җәмгыятьнең һәр яктан җитлеккән бер кешесе буларак формалаша бара. Фатыйма Ильская шушы үсеш процессын бик зур осталык белән, ачык һәм ышандырырлык итеп тамашачыга җиткерә. Ул үз героен өч этапка бүленгән катлаулы юлдан уздыра. Бәхетне фәкать шәхси тормышта, мәхәббәттә генә табарга мөмкин дип уйлаган яшь хатын тамашачы күз алдында үзгәрә бара. Иренең мәкерле йөзе ачылгач, ул үзенең элекке идеалларына ышанычын югалта. Кеше үз бәхетен фәкать хезмәттә генә табарга тиеш икән, дигән фикергә килә ул. Өченче этапта исә без аны, тормышның авыр сынауларын үтүгә дә карамастан, үзендә олы күңеллелекне, кешелеклелекне, рухи гүзәллекне саклап калырлык көч тапкан, кыен хәлләр алдында куркып калмый торган кыю һәм акыллы бер хатын итеп күрәбез. Таня образы актрисага зур кыенлыклар аша бирелә. Бик күп вакыт һәм көч сарыф итәргә туры килә. Әмма актриса өчен боларның берсе дә юкка булмый, чөнки алдагы елларда Джульеттаның (Шекспир, «Ромео һәм Джульетта») бик җаваплы һәм катлаулы образын иҗат иткәндә дә зур файдасы тия ул хезмәтнең.

Джульетта образында да кешенең шәхес буларак үсешен, формалаша баруын күрсәтергә кирәк бит. Яшь кенә кыз, вакыйгалар агышы белән килеп туган үзенчәлекле шартлар тәэсирендә, кыска гына вакыт эчендә тулы камиллеккә ирешкән акыллы хатын булып житешә. Фатыйма Ильская бу рольне дә зур осталык һәм тәгаллек белән башкарып чыга.

Еллар үтә, актрисаның осталыгы үсә, чарлана бара. Инде кырыгынчы елларда ук, матбугат битләрендә аның иҗаты турында гел мактап сөйли башлыйлар. «Ильская бик әйбәт уйный»,— дип яза үзенең 1943 елгы бер мәкаләсендә Ю. Головащенко. Ильскаяның Диана ролендә уйнавы хакында фикер алышканда К. Державин аны «бик шәп» дип бәяли. «Гроза» спектакленә 1944 елда «Красная Татария» газетасында рецензия басыла. «Һичшиксез,— дип яза автор,— спектакльнең төп уңышы Ильскаяның Катеринаны менә дигән итеп уйнавына бәйләнгән».

Күп тә үтми сәхнәгә Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры» пьесасы чыгарыла. Әсәр үзенең тормышчанлыгы, характерларының байлыгы һәм шул ук вакытта үзенең шигърилеге, музыкальлеге белән сокландыра. Аның һәр сүзе, фразасы уйнаклап, җырлап тора. Кешеләрнең олы хисләре, тирән кичерешләре турында язылган бу әсәр хакында А. Глебов болай ди: «Ул үзенең бөтен эчтәлеге белән шулчаклы шигъри ки, аны хәтта драматик поэма дип тә атарга мөмкин булыр иде, ә шул ук вакытта ул бик тормышчан да, анда бик калку итеп бирелгән тормышчан вакыйгалар һәм характерлар тулып ята». Әсәр сәхнәдә дә зур уңыш белән бара. Тамашачылар аны зур кызыксыну белән һәм яратып карыйлар. Һичшиксез, ТДАТ коллективының бу уңышында Фатыйма ролен башкаручы Фатыйма Ильскаяның да өлеше зур. Биредә тамашачы билгеле бер схема белән эшләнгән шаблон образны түгел, ә тормышчан һәм тулы канлы совет кешесен күрә. Фатыйма — туры сүзле, эчкерсез, бик мөлаем һәм сөйкемле хатын. Аны яратмаска, аңа сокланмаска, аның белән горурланмаска мөмкин түгел.

Шулай да, аерым очракларда режиссураның тиешле югарылыкта булмавы талантлы актрисаның уенына комачаулык итә. Шуңа күрә еш кына әйбәт башкарылган рольләрдә дә фикер төгәллеге житешми, образ төссезләнә төшә. Дездемона, Корделия һәм билгеле күләмдә хәтта Катерина рольләре белән дә нәкъ шундый хәл килеп чыга. Әгәр инде Ильская кебек талантлы актриса да шундый хаталар ясый икән, бу тагын һәм тагын бер кабат театрда режиссураның нинди зур һәм әһәмиятле урын алып торуы турында сөйли.

...Ә еллар һаман да үтә тора, инде үз эшенең остасы буларак тәмам үсеп, өлгереп житкәч, инде мактаулы исемнәр алгач, халык артисты дәрәжәсенә ирешкәч, актрисага икенче пландагы рольләргә күчү турында уйларга вакыт житә. Әнә шушы күчеш вакытында ул үзенең бөтен көчен, кыюлыгын, олы акылга ия икәнлеген күрсәтә дә инде. Ул олы яшьтәге хатын-кызлар рольләрендә дә бик уңышлы уйный башлый. Островскийның «Котырган акчалар» комедиясендәге Чебоксарова шундый рольләр арасында беренчеләрдән исәпләнә. Әсәрне сәхнәгә ул чакта әле ГИТИСның дипломанты булган Марсель Сәлимжанов куя. Режиссер әсәрнең идея эчтәлеген тамашачыга житкерү эшенә аның исеменнән башлап тотына: «Котырган акчалар». Шундый акчаларның колы булган кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре дә нормаль түгел, котырынкы мөнәсәбәтләр, дип фикер йөртә ул. Спектакльдә бер генә унай герой да юк. Андагы персонажларның үзара мөнәсәбәтләре дә үтә кансызлык, икейөзлелек белән сугарылган. Бөтен нәрсә дә исәп-хисапка корылган. Фатыйма Ильская да нәкъ шундый трактовкадан чыгып уйный һәм шәп уйный. Аның Чебоксаровасы юантыграк гәүдәле, беренче карашка сабыр акыллы, аристократ тәрбияле хатын булып күренә, ләкин шул ук вакытта аңарда никадәр әшәкелек, кабахәтлек тә бар кебек. Үзенең берләнбер кызы Лидиягә дә ул товар итеп кенә карый һәм аны мөмкин кадәр кыйммәтрәк бәягә сату турында баш вата. Аның бөтен борчылганы, бөтен кайгысы шул. Чебоксарова-Ильская салкын канлылык һәм зур саклык белән эш итә, «товарның бәясен төшермәсәм генә ярар иде», дип, гел куркып яши. Тышкы кыяфәте белән юньле генә күренгән бу кеше, эш чак кына акчага кагылса да, шунда ук үзенең бөтен тәрбияләлеген, бөтен кешелек сыйфатларын югалта. Шулай бервакыт Лидиягә килгән кунакларның берсе ялгыш кына идәнгә акчасын төшереп җибәрә. Һәм Чебоксарова-Ильская үзенең дәрәҗәсе, аристократлыгы турында онытып, акча артыннан ташлана, шуны эзлап идән буенча үрмәләп йөри. Икенче бер урында аның әшәкелеге тагын да ачыграк чагылыш

таба. Ул утларны сүндереп йөри, ярым караңгы бүлмәдә Телятев белән Лидиянең үзләрен генә калдырып чыгып китә. Аннан соң посып кына ишек аша тегеләрне күзәтеп йөри, исәбе, андый-мондый хәл булса, миллионер Телятевне эләктереп алырга һәм кызына өйләндереп калырга.

Ә берничә елдан соң Ильская бөтенләй икенче характердагы рольдә — В. Лавреньтьевның «Ата хакы — тәңре хакы» драмасыннан Софья ролендә уйный. Тамашачы каршына ул менә дигән балалар тәрбияләгән, илебезгә әйбәт кешеләр үстереп биргән ана булып килеп баса. Фатыйма Ильскаяның Софьясы — ягымлы, йомшак күңелле, шәфкатьле, олы йөрәкле хатын.

...50 ел. Әгәр дә дөньяда могҗиза булып, актрисаның шушы вакыт эчендә иҗат иткән барлык образлары да реаль кешеләргә әверелеп тамаша залына җыела алсалар, без анда төрле илләрдән, төрле чорлардан килгән, төрле яшьтәге һәм профессиядәге, төрле дәрәҗәле һәм характерлы кешеләрне очратыр идек. Алар арасында без патша Россиясенең авыр шартларында яшәп тә, кыенлыклар алдында баш имәгән, күңел түрләрендә горурлык һәм кешелеклелек хисләрен саклап кала алган хатын-кызлар белән бергәттән, олы ихтыяр көченә ия булган кыю совет кешеләрен дә, йомшак табигатьле һәм киң күңелле, саф йөрәкле мөлаем кызларны да күрер идек. Бу залда татарлар да, руслар да, башкортлар да, французлар да, испаннар да, немецлар да, италиялеләр һәм башка бик күп милләтләрнең хатын-кызлары булыр иде. Алар — күп төрлеләр, берсе дә икенчесен кабатламый. Кайсылары — тыйнак һәм сабыр холыклы, икенчеләре — кайнар һәм чуар йөрәкле. Алар барысы да бер үк актрисаның фантазиясе һәм талант көче белән иҗат ителгәннәр. Шуңа күрә, бу образлар бер-берләреннән ничек кенә аерылып торсалар да, без аларда бер үк артистны күрә һәм аның әшәкелеккә, явызлыкка каршы актив мөнәсәбәтен тоя алыр идек.

Ләкин андый могҗиза юк һәм була да алмый. Шуңа күрә фотолар белән канәгатьләнергә туры килә. Ә фотолар күп. Менә алар безнең алдыбызда яталар. Аларда — Фатыйма Ильская төрле рольләрдә. Аларның һәркайсында без үзебезгә ни дә булса сөйли торган хәрәкәтчән йөзне күрәбез, актрисаның образны үзенә буйсындыра торган көчен, акылын тоябыз.

Һәр фото актриса иҗат иткән бер образны чагылдыра. Менә бусы гүзәл Трильби, ә аның янәшәсендә — тәкәббер һәм горур Турандот, чая, гаугачыл һәм оят дигән нәрсә белән дә бик үк санашмый торган Кәүсәрия, кыю һәм кырыс Долорес Ибаррури, хәсрәтле-моңсу Айсылу, җыйнак һәм дәртле Фатыйма, мәхәббәт шатлыгына чумган Дездемона, гамьсез һәм шаян Мирандолина, йөрәк ярасына түзә алмыйча сыкранучы Луиза Миллер, җинел акыллырак Мария Антоновна...

Фотолар күп, аларның барын да санап чыга алмыйсың. Аларны караганда образлар галлереясы яныннан үткәндәй буласың, гаҗәпләнәсең, сокланасың: һәркайсы үзенә бертөрле, берсе дә икенчесенә охшамаган, никадәр мимика байлыгы! Артист өчен йөз мимикасының нинди зур әһәмияткә ия булуын һәркем белә. Ә бит сәхнәдә артист уйнаган һәр образның үз мимикасы бар, ул гадәттә озак эзләнүләр, авыр һәм тырыш хезмәт нәтиҗәсендә табыла һәм ул фәкать шул бер образ, шул бер кеше өчен генә ярый, аны икенче персонажларга күчерә алмыйсың. Шуңа күрә дә, әлеге фотоларны күргәч, ирексездән сокланасың: никадәр көч һәм тырышлык бар бу актрисада!

Фатыйма Ильская үзе башкарган рольнең пластик ягына, гәүдә торышына, хәрәкәтләренә дә бик зур әһәмият бирә һәм үзенчәлекле образлар иҗат итүдә аннан да бик оста файдалана. Сәхнәдә ул, вакыйгалар агышының ритмын тоеп, шуңа ярашып, бик төгәл һәм матур хәрәкәт итә.

Үзенә бертөрле лиризм һәм ягымлылык белән сугарылган тавыш; йомшак, ләкин төгәл хәрәкәтләр ясарга сәләтле куллар; йөз хәрәкәтләренең байлыгы, сыгылмалы гәүдә — шулар барысы бергә тупланып башкарылган рольнең һәр яктан да эшләнгән төгәл һәм тулы образын тудыралар, аның бөтенлеген һәм камиллеген тәэмин итәләр...

Яшь кенә кызның тәүге мәртәбә театр ишеген ачып кергән көне инде еракта, артта калган. Аннан бирле ярты гасыр вакыт үткән. Ә атаклы сәхнә остасы булып җитешкән актриса әле бүген дә яшь йөрәкле, бүген дә аның күзләре яшьлек дәрте белән очкынланалар. Бүгенге тормышында ул яшьләрчә тоя, яшьләрчә кабул итә һәм анда яшьләрчә яшәргә омтыла.

Мәңге яшьлек Сезгә, Фатыйма апа!

# ЭШЧЕЛӘР БИСТӘСЕНДӘ СПЕКТАКЛЬ

Татар театр тарихына караган материаллар бер урынга тупланмаган. Аларның күбесе инде эзсез югалып беткән, икенчеләре аерым кешеләр кулында сакланa, кайберләре архив шүрлекләрендәге материаллар арасында тузанга күмелеп ята.

Безнең алда театрыбыз тарихына бәйләнешле шундый сирәк очрый торган документларның берсе — Г. Кариев җитәкчелегендәге «Сәйяр» труппасы куйган спектакльләрнең афишасы.




«Сәйяр» труппасы 1913 елның 2 ноябрендә Прохоровой бистәдә (хәзерге Киров районы) эшчеләргә Я. Вәли драмасы буенча эшләнгән «Ачлык кушты» исемле һәм А. Соколовның «Каенана өйдә булса, эшнең асты өскә килә» исемле бер пәрдәлек комедиясе буенча эшләнгән спектакльләр күрсәткән. Афишадан күренгәнчә, ул спектакльләр иреккле янгын җәмгыятенең Прохоровойдагы бүлекчәсе файдасына куелган.

Я. Вәлинең «Ачлык кушты» драмасы турында ул вакыттагы татар матбугатында байтак язылган. Бу драмага бәя бирүче кешеләрнең беренчесе атаклы татар драматургы Г. Камал була. «Йолдыз» газетасында басылган мәкаләсендә Г. Камал драманың әдәби сыйфаты түбән булуын әйтә, әсәргә динамика, хәрәкәт җитми, ди.

Күзгә күренеп торган кимчелекләре булуга да карамастан, Г. Кариев кебек талантлы художник җитәкчелегендәге труппа бу драманы сәхнәгә чыгара. Алай гына да түгел, «Ачлык кушты» спектакле тамашачылар арасында зур уңыш казана, татар телендә чыккан вакытлы матбугат аңа уңай бәя бирә.

Моның сере нәрсәдә? Ни өчен урта кул пьеса буенча эшләнгән спектакль шундый уңыш казана? Әлбәттә, спектакльнең уңышлы чыгуында Габдулла Кариев, Гөлсем Болгарская кебек артистларның роле зур була. Бу әсәрдә Г. Кариев Күретдин ага, Г. Болгарская Мәһисылу рольләрен башкаралар.

Ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар. Прохоровой бистәдә әлеге спектакльне күргән Г. Хәсәнов иптәшнең[1] сөйләвенә караганда, хәерчелектән, ачлыктан җәфаланган гаиләләр арасында бу елларда үзләренең кызларын Урта Азиядән килгән купецларга сатып җибәрү очраклары күбәя. Ә Ярулла Вәли драмасы үзенең бөтен пафосы белән шундый аяныч күренешләргә юнәлтелгән була. «Ачлык кушты» спектаклен караганнан соң, үз балалары белән сату итүче ата-аналар бөтенләй сирәкләнде, дип сөйли Г. Хәсәнов иптәш. Бу инде «Сәйяр» труппасының халык интереслары, аның кайгы-шатлыклары белән якыннан кызыксынып яшәве турында сөйли торган фактларның берсе.

*Х. ГОБӘЙДУЛЛИН.*

—✦—

[1] Г. Хәсәнов хәзерге көндә пенсиядә, шәһәребезнең Киров районында яши.

# *Хөсәен Ямашевның тууына 85 ел*

*Хөсәен Ямашев ленинчыл типтагы профессиональ революционер иде. Ул үзенең бөтен көчен, бөтен гомерен һәм сәләтен халык бәхете өчен көрәшкә багышлады. Алдынгы иҗтимагый-политик карашлар үсешенә зур йогынты ясаган ялкынлы большевикның якты истәлеге халкыбыз күңелендә мәңге саклаa.*

*Шушы елның 19 январенда күренекле татар революционеры Хөсәен Ямашевның тууына 85 ел тулды. Татарстан Партия Өлкә Комитеты секретариатының махсус карары буенча, Хөсәен Ямашевның 85 еллыгы бөтен республикада киң күләмдә билгеләп үтелде. Предприятиеләрдә, колхозларда, совхозларда, уку йортларында, аның революцион эшчәнлегенә багышлап, беседалар үткәрелде, лекция һәм докладлар укылды. Республика газета-журналларында Хөсәен Ямашевның тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган материаллар басылды[1]. Татарстан радиосы һәм телевидениесе күренекле революционер турында тапшырулар оештырды.*

## КӨЧ БЕЛӘН БЕРГӘ ГҮЗӘЛЛЕКНЕ ҖЫЙГАН ДИҢГЕЗ КЕБИ

**...Татарларның алдынгы кешеләре, башкалар белән беррәттән, оештыру группаларына керәләр, кайберләре рус түгәрәкләренә йөри, барысы да гомуми массовкаларга катнашалар.** Ләкин тел аерымлыгы аркасында, татар телендә генә алып барыла торган түгәрәкләр төзергә, соңыннан оешмага тарту максаты белән кайвакыт фәкать татарлар өчен генә башлангыч оештыру җыелышлары үткәрергә туры килә. Листовкаларны да татар теленә тәрҗемә итәргә кирәк була. Моны шулай ук татарлар гына башкара ала. Шушы максат өчен комитет янында татар оештыручысы бар. Комитет аның фикере белән бик нык исәпләшә. Казан халкының 30 проценты татарлар икәнен искә алсак, бу бик аңлашыла... Ул (Хөсәен Ямашев — ред.), әйтергә кирәк, милләтчелекнең аз гына да катнашы булмаган «ортодоксаль» караштагы тәпле социал-демократ...

«Пролетарий» газетасы. 1905 ел. 22 сан.

**...Ләкин бу хыял (университетка керү — ред.) тормышка ашмый кала, чөнки аны рус иптәшләренең политик хәрәкәте дулкыны үзе белән бергә ияртеп алып китә.** Ул халык файдасына, өлешсез калган һәм изелгән массалар файдасына, азатлык һәм тигезлек файдасына эшли башлый...

«Невская звезда» газетасы. 1912 ел. 3 июнь.

**...Вакытсыз үлгән Хөсәен Ямашев йөзендә татар социал-демократлары социализм идеяләрен чын күңелдән таратучы, үзенең мохитен яхшы аңлаучы һәм кешеләрнең ышанычын казана белүче ялкынлы көрәшчене югалттылар.** Үз идеяләренә тирән инанган, армый-талмый эшләүче, тимер ихтыярлы кеше буларак, ул бөтен табигать белән көрәшче иде...

«Звезда» газетасы. 1912 ел. 1 апрель.

> Үтте тормыш пычрагын гәүһәр кеби вөҗдан белән,
> Аз гына кер кунганын да кай җиреннән кем табар?
> Ул көрәште һәм явыз эшкә җәза бирде килеп,
> Үткен акылы шул көлешкә пакь көмештән юл булып.
> Ул көрәште, язда елмайган кояш тәсле, бәләнт,
> Карны, бозны ул ничек эретә көлеп һәм нур коеп.

Г. ТУКАЙ.

**...Ямашев һәм иптәшләре татар массасы өчен ана телендә газета чыгаруны күптән планга куйганнар иде. Вакыйгаларның... кызу кайнап, сулыш алырга ирек бирмәс дәрәҗәдә тиз баруы, полиция, жандармерия** тыгызлаулары моңа мөмкинлек бирмәгән иде; башка чара булмагач, яшерен җилем басмаларда прокламацияләр, кечкенә китаплар чыгара тордылар. Татар телендә беренче яшерен сәяси прокламацияләрне язучылар һәм беренче мәртәбә басып таратучылар Ямашев һәм аның иптәшләре булды... 1906 елның (дөресе — 1905) соңгы яртысында Хөсәеннең Казаннан качып Уфага баруы аны Татарстан пролетариатыннан, эшләп килгән аппаратыннан аерса да, югарыгы өмет — газета чыгару эшендә аңа юл ачты.

Г. Ибраһимов.

**Мәйданда вакытта һичшиксез ике мең кадәр кеше бар иде.** Озата баручыларның бәгъзылары мәйдан ягында калдылар. Яртыдан зиядәсе мәкъбәргә (зиратка — ред.) кадәр озата бардылар.

Хөсәен әфәндENең җиназасы өстенә яшьләрдән, иптәш студентларыннан һәм хатыны тарафыннан ленталар куелган иде. Иптәшләре тарафыннан куелган лентада: «Вакытсыз киткән мәңге онытылмаслык дустыбызга», юридический кружок идарәсе тарафыннан куелган лентада: «Ул үз халкының якты истикъбале (киләчәге — ред.) булачагына ышану һәм өмит илә китте», — дип язылган иде.

Г. Камал.

---

[1] «Казан утлары»ның быелгы саннарында укучыларыбыз А. Расихның Хөсәен Ямашевка багышланган яңа романы белән таныша алачаклар. *Редакция.*

*Энҗе Мөэминова*

## Аңлармы ул

Бүлмәм иркен,
Бүлмәм шундый якты!
Һәрбер караш шундый ягымлы!
Шул бүлмәдә бүген,
керфек какмый,
Каршы алдым бәхет таңымны.
Гел җырлыйсым гына килеп
тора —
Хисләремнән ахры исердем —
Улым бүген бүләк итте миңа
(Ә үзенең әле исеме дә юк)
Ана! — дигән бөек исемне.
Шатлыгым зур,
Шундый, шундый зур ул!
Сыймас төсле хәтта ишеккә!
Бүлмәм уртасында кояш үзе —
Улым йоклап ята бишектә!
Яшәү даулап туган тәүге аваз
Җырга күмде тирә-ягымны.
Кояш нурларының күплегеннән
Тәрәзләргә ялкын кабынды.
Улым туды!
Нәни улым туды!
Күрегез, ул нинди сөйкемле!
Аның тәүге аваз салуыннан
Җыр башланып китәр
шикелле!
Аның тәүге аяк атлавыннан
Чор башланып китәр шикелле!
Тәрәзәләр аша тышка карыйм,
Офыкларга карыйм
һәм күрәм:

Кемдер улым өчен
юллар салган,
Кемдер аңа бакча үстергән.
Кемдер аңа атап җырлар
язган —
Кемдер аңа бәхет китергән!
Ул аңлармы икән шуларны?!
Толлар күзендәге яшь
тамчысын
Күрә алыр микән күңеле?
Аңлармы ул
кеше бәхетенең
Түбән ләззәтләрдә түгелен?
Әнә шундый борчу уйлар белән
Тәрәзәдән карыйм урамга..
Улым бәхете өчен
кайнап торган
Җанлы тормыш күрәм мин
анда.
Киң үзәндә яңа шәһәр туа.
Яңа шәһәр...
Яшьлек шәһәре!
Аның әткәсе дә иҗат итте
Ул яшисе шушы шәһәрне!
Ә мин?
Ә мин аның өчен
язар китабымның
Җөмләләрен эзләп интегәм.
Аның өчен әйтер сүзләремә
Тормыш дәлилләре китерәм.
Ул аңлармы икән шуларны?

## Туган җиргә мәхәббәтем...

Мин — юлаучы!
Юлым ерак,
юлым олы:
Маршрутым күренеп тора —
«Дуслык юлы».
Юл чатында басып торам
горур карап:
Кайда көчле тарту көче?
Кай яктарак?!
Җанга якын,
җанга газиз
Кайсы тараф?
Ленин каласын яктырткан
ак төннәрме?
Төньяк балкышы уйнаган
ак төннәрме?
Башкаламның курант чыңлы
таңнарымы?
Тау иленең кар түбәле
тауларымы?
Җылы якның ак мамыклы
кырларымы?
Урал тауның курай моңлы
җырларымы? —
Кайсы минем күңелемне
ныграк тарта,
Күңел кошым очып китәр
кайсы якка?
Шуны уйлап басып торам
горур карап.
Хыялларым җир әйләнә,
әйтерсең лә
Космик кораб?
Миңа гаҗәп! —
Баскан җирдән китеп булмый,
Китеп булмый —
Баскан җирем магнитланган!
Туган җиргә,
торган җиргә,
үскән җиргә
Мәхәббәтем мәңгелеккә
бәйләп куйган!

## Шелтә сүзе ишеткәлим

Яшьләр белән шаулап үтә
минем гомер.
Шуңа күрә картаерга
мөмкин түгел.
Беренчеләр белән киләм
сентябрьдә.
Майда китәм уенчылар
белән бергә.
Яз җиткәндә яшем җитсә
уенсигезгә,
Көз җитүгә кабат төшәм
мин сигезгә.
Шуңа күрә өлкән яшькә
җитеп тә мин,
Өлкәннәрдән шелтә сүзе
ишеткәлим.
«Балаларның балалыгы
күчә сиңа,
Һичбер вакыт акыл кермәс
ахры сиңа!»
Шелтәлиләр шулай диеп
бик еш кына.
Минем бик нык хәтер кала
менә шуңа.

## Сәер мәхәббәт

Һәр дәрескә балаларым
көтеп ала.
Дәрес беткәч, хөрмәт белән
озатып кала.
«5»ле куйсам — сөенәләр,
үзем кебек.
«2»легә көенәләр —
үзем кебек.
Сөйләшәләр иң әйбәткә
мине санап.
Әниләре калып тора
бер яктарак!
Тик...
Авырып китсәм, «Буш дәрес!»
дип кул чабалар.
Буш дәресләр күбрәк булса,
куаналар.

## Кыз язны ашыктыра

Кечкенә генә шешәдә
Тал яфрак яра.
Һәр иртәдә бер кыз бала
Аңа күз сала:
    — Бөреләр бүген тагын да
    Күбрәк ачылган.
    Өйдә җылы, урамда да
    Буран басылган.
Яшел-сары яфракчыклар
    Хуш ис тарата.
Кыш та матур, кыз нигәдер
    Язны ярата:
— Кайчан тәрәзәм төбендә
Тамчылар тамар?
Кайчан күбекләр уйнатып,
Гөрләвек агар?
Киләсе яз килми калмый,
Килә ул, килә!
Кыз көнеле яз каршына
Ашыга нигә?
— Талым яфракка күмелде,
Өйдә күңелле!
Карлыгачлар, сыерчыклар
Килсен иде инде...

*Камил Мостафин*

## Йолдыз

Еракта бер йолдыз яна.
Юлчы аңа карап бара.
Уза чүлне, уза сазны, —
һаман житә алмый аңа.

Юлчы менә биек тауга...
Йолдыз ерак, һаман ерак!
Кеше артка борылып карый
һәм аптырап кала шул чак:

Ул үткән жир жем-жем итә,
анда — яшен, ялкын һәм боз.
Кеше күрә: узган юлда —
күпме йолдыз, күпме йолдыз!

## Тынычсызлык

Минем көннәремдә
кайчагында
тынычсызлык хисе кузгала.
Дөнья матур...
Ә мин, аның улы,
матур яшим микән дөньяда?
Артка борылып карыйм:
менә монда
буш чәчәктән җимеш көткәнмен,
ә менә бу айсыз кара төндә
якты утны күрми үткәнмен.
Менә монда, кирәк булмаса да,
юк-бар өчен көчем түгелгән,
ә тегендә
мөһим бер эш мина
никтер «пустяк» булып күренгән...
Күпме ялгыш...
Дөрес юлны табу
бигрәк кыен кайчак, юлдашым...
Ялгышларны төзәтергә була, —
гомеребез ялгыш булмасын!
Ә бит гомер гаҗәп кыска нәрсә,
озайтмаса аны адымын,
озайтмаса аны елмаюын,
кешеләргә әйткән җылы сүзең,
мәхәббәтең, көчең, акылың.
Гомер кыска,
июнь төне кебек,
ә син, тормыш, чиксез, син озын,
Киң сулышлы тормыш,
ал байраклы тормыш,
сиңа бирәм йөрәк җылысын!
Бу җылыдан, бәлки,
Игаркада
гүнгән мәкләр чәчәк атырлар...
Дөнья гүзәл. Аны гүзәл иткән
күпме буын!
Эх, безгә дә, дустым, бу дөньяның
бер почмагын булса матурлап!

## Шулай була икән...

Төн
дөньяга кара шәлен япкан.
Тик фетнәче яшен,
ялт иттереп,
ертып ала шәлнең бер читен.
Көтмәгәндә ул күрсәтеп куя
буш урамны, юлны, тау битен.

Ул яктыртып ала коймаларның
борылмалы «патрон ленталарын»,
печән чәйнәп торган ялгыз атның
кара төнгә охшаш зур күзен...
Яшен яшьни шулай төн озын...

Караңгылык ак кылычлар белән
кисәкләргә чатнап бүленә...
Шулай була икән кайвакытта:
кояш яктысында күренмәгән
гаҗәп дөнья
яшен яктысында күренә.

## Дезертир

Ул сугыштан качкан һәм үлемнән:
артык куркак җанлы булганга,
илен ташлап, кешеләрне ташлап,
качып киткән кара урманга.

...Яшәгәннәр кешеләр, үлгәннәр,
ялан аяк ап-ак карга басып,
шомлы эшафотка менгәннәр...

Ул белмәгән моны... Бөкерәйгән,
сүзсез калган, беткән, корышкан.
...Үлеменнән качкан көннән алып
ул мәңгегә киткән тормыштан.

●

Һәр кешенең үз йолдызы була, диләр.
Кояш та бит — тик бер йолдыз. Ул кемнеке?
Кеше үлсә йолдызы да сүнә, диләр...
Кояш кына мәңге якты. Ул безнеке!

Кеше үлә, ләкин була үлемсезләр.
Җир уллары бу турыда белә күптән.
Йолдыз сүнә... Ә кояшта — мәңге ялкын,
чөнки аңа үлемсезләр җаны күчкән.

— — — ◆ — — —

*Клара Булатова*

## Яратаммы сине?

Яратаммы сине? —
айтә алмыйм.
Яратамдыр, бәлки.
Бәлки — юк.
Син булсан да, чөнки,
булмасаң да,
Яшәү рәхәт мина шулай ук.
Тик шулай да,
синен сөюецне
Сизеп яшәү нинди күңелле.
Белеп тору, тагын уйлап мине
Йокламыйча үткән төнеңне.
Шаулап торган,
халык тулган залда
Син тавышымны таный аласың,
Йөзәрләгән кеше арасында
Тиз үк мине эзләп табасың.

Ерактан ук мине күзәтәсен,
Ялгыз гына үткән чагымда.
Яки кинәт төсең үзгәртәсен
Башка берәү булса янымда.
Кайда йөрсәм дә мин,
юлларыма
Түгелә кебек синен карашың.
Кайчак шулай ерак йолдызларның
Сулышларын тоя аласың.
Яратаммы сине? —
әйтә алмыйм,
Бәлки, юктыр,
бәлки, сөямдер.
Мин тормышны сөям.
Бәлки аның
Матурлыгы синең беләндер.

## Ялгыз каен

Юл буенда үскән ялгыз каен
Җил кагылган саен бөгелә.
Көннәр туган саен, ап-аккаем,
Үзәкләрең нидән өзелә?
Һичкемең юк синең янәшәңдә,
Гомерләрең ялгыз ник үтә?
Күләгәңдә бары эссе җәйдә
Узгынчылар гына ял итә.
Кайберләре, кайрыларың юнып,
Пәке белән эзләр салганнар...
Минем дә бит, каен, йөрәгемдә
Уелып калган кара ярам бар.
Мәңге сызлар яра салып өчен
Йөрәгемә якын килгәннең
Бер узгынчы гына булганлыгын
Белмәдем мин, каен, белмәдем.

Тукталмады миндә озакка ул,
Бөтенләйгә китте янымнан.
Китәр булгач ташлап, бу җанга ул
Ник кагылган?
Нигә кагылган!..

Ак кәүсәңдә, каен, кара эзләр,
Кемнәр икән шулай салганнар.
Минем дә бит, җаным, йөрәгемдә
Уелып калган кара ярам бар.

Һичкемем юк шулай янәшәмдә,
Синең кебек ялгыз көн үтә.
Күләгәмдә бары, эссе җәйдә
Узгынчылар гына ял итә.
Узгынчылар гына.

## Вакыт үтә...

Вакыт үтә...
Шуны сизү аның
Йөрәгендә сагыш кузгатты.
Ул авылдан килгән зур сандыгын
Төпкә кадәр ачып бушатты.

Җиллэтергә дипме, әйберләрен
Алып-алып элде барысын да.
Кыз вакыттан калган ак күлмәген
Киеп басты көзге каршына.

«Чыгарышка» диеп теккән иде...
Ә аннан соң, сабан туенда,
Шул күлмәкне киеп көткән иде
«Ул» килүне чишмә буенда.

Беркайчан да кире кайтмас өчен
Үтеп киткән назлы кыз чакны,
Һәрнәрсәгә бәйләп нечкә күңел
Ник сагына икән бу чаклы?..

Йөгерек судай яшьлек агып киткән...
Күлмәге дә инде кигәндә
Билләреннән кысып, ятып тормый...
Улы үйный, әнә, идәндә.

Өстендә дә бүген чуар халат,
(Ак ефәктән күлмәк текмәгән.)
Гәүдәсенең, ләкин аңа карап,
Сылулыгы һаман бетмәгән.

Кашлары да әле дугалана,
Күзләре дә көлә яктырып
Тик аларда хәзер башка төрле,
Аналарга хас бер матурлык.

Еллар. узар.
Чәче көмешләнер.
Җыерчыклар тулыр йөзенә.

Улы үсәр.
Йортка килен төшәр.
Оныклары менәр тезенә

Көлгән чакта күзләр очкынланмас,
Бит очлары алга буялмас.
Тик барыбер аңда.
ул чакта да.
Ана гүзәллеге югалмас.

## Яшьлек эзем калган...

Менә кайттым тагын
Сиңа, туган ягым.
Яшьлек эзем калган
Монда адым саен.

Хатерәмә ерак
Истәлекләр килде:
...Ул язда бит миңа
Унҗиде яшь иде.

Унҗиде яшь иде...
Әле дә күз алдымда,
Йөрдек икәү бергә
Елга буйларында.

Табигатьнең язгы
Назлы кочагында
Күбәләктәй җиңел
Уйнап шул чагында.

Урманнарда йөрдек,
Тауларына мендек.
Шат күңелле идек,
Саф күңелле идек.

...Аннан аерылып син
Ерак киткән идең,
«Көт», — дип киткән идең
Һәм мин көткән идем.

Әйе, көткән идем
Ләкин хәбәр килде:
«Оныт, көтмә инде,
Ул өйләнгән», — диде.

«Ул өйләнгән инде»...
Әрнеп куйды йөрәк:
«Нигә сөеклемә
Бүтән кадерлерәк?»

Кайнар яшьләремне
Сөрттем күптәнме соң?
Алар дымы күздән
Әле кипкәнме соң?

...Тормышыңа синең
Бер күз салыр идем,
Беренче һәм соңгы
Мәхәббәтем минем.

Син бәхетлеме соң?
Син канәгать микән?
Бар да төгәл микән?
Бар да әйбәт микән?..

Бәлки, хәзер син дә
Уйга чумгансыңдыр,
Яшьлек көннәреңне
Сагына торгансыңдыр.

Бәлки, бу минутта
Такмаклап, юатып,
Бала сөясеңдер,
Кулыңда уйнатып.

Юк, кирәкми, күрмим,
Тагын сыкрар күңел:
«Ник, — дип, — башканыкын,
Ник минекен түгел?!»

...Еллар күмеп киткән
Йөрәк яраларын
Яшь юкәле юллар
Кузгаттылар тагын.

Яшьлек эзем калган
Монда адым саен.
Әй, ник кайтармыйсың
Аны, туган ягым!..

# *Вьетнам хикәяләре*

*Бүгенге көндә бөтен прогрессив кешелек дөньясының карашы сугыш ялкыны эчендә кайнаган Вьетнамга төбәлгән. Вьетнам халкы иң яңа сугыш кораллары белән коралланган Америка империализмы һәм аның ялчыларына каршы үзенең азатлыгы өчен каты көрәш алып бара.*

*Героик илнең язучылары да бу көрәшкә турыдан-туры катнашалар. Хәзерге көндә халыкның азатлык һәм бәйсезлек өчен көрәше темасы — Төньяк һәм Көньяк Вьетнам язучылары өчен дә уртак тема.*

*Журналыбызның бу санында Вьетнам язучыларының әнә шул темага багышланган берничә хикәясен бирәбез.*

*Фан Ты*

## ИКЕ БЕРТУГАН

Иртәнге сәгать дүрт. Дошман доты атакага әзерләнгән безнең отделение өстенә атуын дәвам иттерә. Дошман пулеметларының такылдавы курчак армиясе солдатларына: «Кичекмәстән бирелегез! Фронт сезгә мәрхәмәт күрсәтә... Командирыгыз үз сүзләлансә... катгый чаралар күрелер...» дигән өндәмәләрне ишетергә ирек бирми.

Бер кырыйдан:

— Гранаталарны әзерләргә!

— Иптәш командир, пулемет тыгылды!

— Кайда иптәш Кам? — дигән ашыгыч авазлар ишетелеп кала.

Кояндыр Кам килеп чыга һәм, кулындагы «лебель» винтовкасын тоткан килеш, отделение командиры Люк каршына килеп баса. Шул вакыт һаваны тырылдатып пулемет аткан тавыш ярып үтә. Бәхеткә каршы, Люк белән Кам җиргә ятып өлгерәләр.

— Мина шартласа, атакага сигнал булыр, чыгарма хәтереңнән, — дип Люк Камга искәртеп куя.

Кам аңа:

— Тыңлыйм, — дип җавап бирә.

Ул җиргә сыенып кына мылтыгын кора. Димәк, сугышка әзер. Аның Азатлык армиясенә килүенә ике ай инде, шулай да ул беренче сугышта ук мондый каты бәрелешкә очрармын дип башына да китермәгән иде. Хәзер Камга чик буендагы чәнечкеле тимер чыбык киртәләргә якын ук килергә кушылды. Ул артык дулкынлана иде. Люкның: «Сынатма, егет!» дип пышылдавыннан гына бераз тынычлана төшә.

Үлемнән курыкмый ул. Ләкин дары исе аңкыган бу җирдә яту чирканыч аңа. Беренче мина төшеп ярылу белән ук ул үзен бик тиз кулга алды. Люк атса, Кам да ата, Люк сикереп торса, аның артыннан ук Кам да аягына баса.

Аңа хәзер Люкның кара шлемы гына күренә. Ул, командиры кебек, бик күп дошман постларын һәм чәнечкеле тимер чыбык киртәләрне үтте.

Бәрелеш кызганнан-кыза бара иде. Шул вакыт, көтмәгәндә, көчле бер яктылык Камның күзләрен чагылдырды, җир тетрәп киткәндәй булды. Көчле шартлау артыннан өстенә яңгыр булып бомба ярчыклары, балчык төерләре коелды. Ул «Атакага!» дигән приказны чак-чак кына ишетте һәм куе төтен пәрдәсен үтеп, алга ыргылды...

Кулларын югары күтәргән кешеләр арасыннан Люкның:

— Эх, углат янки! Сез монда ялланган офицерларны бикләгәнсез икән... Мәнә нигә бирелмичә торгансыз! — дигән тавышы ишетелде.

Азатлык армиясенең дүрт сугышчысы америкалының гәүдәсен брезентка салып «соңгы юлга» алып киттеләр. Камга бу янки, оккупациядә калган үз авылында борын чөеп, күкрәк киереп йөрүче башка янкиларга караганда, нигәдер, бик мескен булып күренде.

Кам арлы-бирле йөренде. Үтеп барышлый, Нго Динь Дьемның стенадагы сурәтенә мылтык түтәсе белән төртеп алды, кемнеңдер ташландык ботинкаларын элэктереп, читкә ыргытты. Тагын арлы-бирле йөренде... Яңадан әйләнеп килеп, ул ботинкаларны тагын еракрак атып ташлады.

Камның юкка вакыт уздыруын күреп торган Люк моны бер дә килештермәде:

— Коралны сугышып алу турындагы боерык исеңдәме? Исеңдә булса, менә бу портупеясе һәм патроннары булган «гарант»ны тиз генә үзеңә ал, ә «лебелең»не ташла. Я, канәгатьме шуның белән?

Кам, башка берәү элэктермәсен дигәндәй, америкалының автоматын йөгереп барып кулына алды. Ләкин ул портупеяне киям дигәндә, кемнеңдер:

— Ти, энем... — дип эндәшүеннән сискәнеп китте.

Ул, үзенең бала чактагы исемен ишетеп, каушап калды, артына борылып карады, җитмәсә, таныш та кебек иде бу тавыш. Тик ул үз тирәсендәге отделение сугышчыларыннан башка берәүне дә күрмәде. Портупеяне алырга дип башын июе булды, тагын:

— Кам, энем...— дигән тавыш ишетте.

Америка командирының джипыннан берәүнең әлек башы, аннары канга буялган яшел күлмәге күренде. Кам югалып калмады, аңа автоматын төзәде:

— Чык монда тизрәк!

— Бирелэм. Чыгам, туган.

— Монда сиңа туган кеше юк, этка туган син!

— Зинһар, атма, атма инде! Бу мин — Шыу мин.

— Син — Шыу?!

Солдат, кулларын күтәреп, Кам алдында катып калды. Аның йөзе танырлык түгел, канга баткан, һәм ул әзлексез күкрәгенә тама. Бу Камның бертуган абыйсы — Шыу иде. Алар ике тамчы су шикелле бер-берсенә бик охшаганнар.

Тик Кам кулын коралдан ычкындырмады.

— Син яралы...

— Зарар юк, шартлаудан соң нигәдер күкрәк авырта.

— Әнә утыр. Хәер, юк, кулларыңны бәйләргә кирәк әлек.

Шыу, почмакта чүгәләп утырган килеш, үксеп елап җибәрде. Кам авыз эченнән генә мыгырданып:

— Таптың елар вакыт... Ник әлек бирелмәдең соң? — диде аңа.

— Курыктым.

— Ярый, балавыз сыкма, бәлки сине җибәрерләр. Тик ни кушсалар, шуны үтәргә тырыш. Өйдәгеләр хакында берни дә белмисеңме?

— Син китеп, ике-өч көн үткәч тә безнекеләрне авылдан кудылар... Хәрби сәбәпләр аркасында бугай.

Ут белән су арасында калган Кам ни диярга да белмәде, ахыр чиктә генә «китәргә кирәк» дигән уйга килде. Абыйсы белән сөйләшергә иртәрәк кебек. Абый булудан бигрәк, ул хәрби әсир хәзер. Иң яхшысы, аны иптәшләр карамагына тапшырырга, ә алар нишләргә кирәген үзләре белерләр. Дошман тарафыннан мобилизацияләнгән солдатларга Фронт бит мәрхәмәт күрсәтә.

Кам сугыш кирәк-яраклары тутырылган ящикларны ташырга кереште. Аны һаман бер уй борчыды: ул шатланырга да, кайгырырга да белмәде...

Шыуны да, үзен дә америкалылар белән дьемчыларга «хезмәт итәргә» мәҗбүр итүләре бик исендә аның. «Хәрби хезмәткә» китү вакытын кичектерү өчен аз тарткалашырга туры килмәде. Әмма җирле властьларны алдау бик җиңел түгел иде. Алар: ир туганнарның берсе хезмәткә китсә генә, икенчесенә калырга мөмкин, дигән ультиматум куйдылар. Шул вакыт инде Шыу өлешенә курчак хөкүмәтә армиясенә хезмәткә китү җирәбәсе чыкты һәм шулай итеп Каршылык күрсәтү армиясе белән элемтәгә керү өчен ул энесенә вакыттан отарга ярдәм итте. Соңыннан алар Азатлык көчләре ягында кушылырга сүз куештылар. Бәрникадәр вакыттан соң Кам фронт белән бәйләнешкә керде. Армиядәге абыйсына ул: өебез янды, этиебез үләргә ятә. Шыу кайтып

китсен, — дип хатлар да язып карады. Әмма көтүе юкка гына булды. Барыбер хатыхәбәре килмәде. Көтелмәгән берәр хәл килеп чыгудан куркып, сугышка Кам үзе генә китте. Ул вакыт абыйсы энесенә атар, ә энесе аның ярасын бәйләр, дип кем уйлаган... Атака вакытында абыем Шыу үз коралын ялланган гаскәрләргә, америкалыларга нигә бормаган! Менә бу фикер Камның бер генә минутка да башыннан чыкмады.

Бу уйларын оныту өчен ул ашарга тырышып карады, әмма капкан ризыгы аш булып түгел, ә таш булып төште. «Әгәр Шыу безнекеләргә аткан булса! Ә бит атака вакытында безнең ике сугышчыбыз үлде, дүрт-бишләп кешебез каты яраланды. Шыу да карап тормагандыр, ни дә булса эшләгән булырга тиеш?! Моны миңа кичекмәстән ачыклыйсы калган». Кам тагын: «Әгәр ул кемгә дә булса аткан булса... ул вакытта...» — дип уйлады.

Нәфрәт һәм кызгану тойгысыннан тыны кысылды. Ул, корал складына кереп, үксеп-үксеп елап торды, шулай да күз яшен иптәшләренә күрсәтмәскә тырышты.

Бераз тынычлана төшкәч, Кам яңадан элекке хәленә кайтты. Шунда ул Азатлык армиясе сугышчыларының джип шиннарын ямаганнарын күзәтеп торучы абыйсын күрдә. Кам, түземен җуеп, нәфрәтләнеп кычкырып җибәрде:

— Бар, кит!.. Әсирләр янына кит! Тизрәк кит!..

Шыу тиз генә башын күтәрде һәм аның маңгаенда төер-төер булып кипкән зур кан таплары күренде.

Шыу, сагаеп кына Камга эндәште:

— Туганым, ал мине үзең белән, командир рөхсәт итте... — диде. Аннары Шыу үз-үзен тыя алмады, кызып китте. — Мин үземне-үзем кисәкләп ташларга әзер! Син миңа ышанмыйсың икән — ышанма! Миңа болай да хурлык, түбәнчелек! Атыгыз, үтерегез мине! Сез бит минем хакта берни дә белмисез... Фронт белән элемтә урнаштырырга тырышуымны да... берсен дә!.. Ә бит курчак хөкүмәте армиясенә китүем синнән булды. Әгәр мине аз гына көткән булсаң... Ә син, яхшы атланып, ялгызың китеп баргансың.

— Гаеп үзеңдә дә бар, — диде Кам. — Мин сиңа төрле сылтаулар табып, хатлар салдым. Ә син вакытында әйләнеп кайтмадың. 4352 нче сектор, 297.508 нче матрикул, шулаймы?

Шыуга бу җитә калды:

— Син ул хатларны минем кулга кергәндер дип уйлыйсыңмы? Алар килгән бер хатны яндыра бардылар. Үзең килгән булсаң менә...

Кам, ни дип җавап кайтарырга белмичә, аптырап калды. Шул чак алар янына отделение командиры Люк килеп чыкты.

— Менә бу егет Азатлык армиясенә кушылырга рөхсәт сорый. Син аны таныйсыңмы, Кам?

Кам, кыяр-кыймас кына:

— Бертуган абыем ул минем. Сезгә аның турында сөйләгәнем дә бар кебек, — диде.

— Әйе, сез бер-берегезгә ике тамчы су кебек охшагансыз. Ярый алайса, абыең булса — иртәгә сынап карарбыз. Хәзер юындыр үзен, — диде Люк.

Кам юл капчыгыннан кулмәген алды. Кайчандыр ул күлмәкне алар абыйсы белән алмашлап кияләр иде. Хәзер ачыктан-ачык сөйләшергә дә мөмкин. һәм Кам абыйсыннан:

— Атака барганда аттыңмы син? — дип сорады.

— Әйе.

— Ник аттың? Кемгә аттың?

— Джипның көпчәкләренә аттым. Американың качуыннан курыктым. Мин ул турыда синең командирыңа әйттем инде.

— Ярый, алайса, шәп эшләгәнсең. Тик мин сиңа бер киңәш бирер идем. Азатлык армиясе сугышчыларын «пиратлар», ә дьемчыларны «милләт сакчылары» дип атый күрмә, югыйсә үзеңнән бот чабып көләрләр. Приказ бирсәләр, «ярый, әфәндем» дип әйтә күрмә, ә «тыңлыйм, иптәш» диген. Хәзергә шуларны белсәң, җитеп торыр.

Күңеле күтәрелеп киткән Кам Шыуны ишек алдына алып чыкты. Анда аларны кулына карабин тоткан Люк каршы алды. Бу карабин Шыуга түгелме соң! Ә Кам бит моны башына да китермәгән иде.

— Кара аны, егет, — диде Люк Шыуга. — Син хәзер безнең белән. Башта курс үтәргә кирәк булыр. Тик ул — «коммунизмны фаш итү» рухында түгел... Син дошманның мәкерен һәм Революциянең нәрсә икәнен аңларга тиеш. Бу сиңа милли азатлык фронтына хезмәт итәргә көч бирәчәк. Синең кебекләр дүрт-биш кеше. Курсны тәмамлагач, безнең белән калыргамы, өйгә кайтыргамы — үзегез хәл итәрсез. Ә калучылар турында: «Өстәмә тикшерү өчен алып калындылар», — дип хәбәр итәләр. Ул чагында оккупацияләнгән зонадагы туганнарыгызга да хәвеф-хәтәр булмас. Ә хәзер бар, иптәшләреңне куып җит.

Шыу, сүзсез генә, башка әсирләргә барып кушылды. Кам, аның артыннан күз алмыйча, озатып калды. Бигрәк кечкенә буйлы күренде ул аңа!

Күктән ут ачарга әзер торган истребительләр сагы астында түбәннән очучы «демуазель» [1] күренде. 150 миллиметрлы орудиеләрнең гөрселдәве тәнге тынлыкны ярып үтте. Сугыш кирәк-яраклары һәм документлар төялгән джип һәм өч бронетранспортер юлда очраган барлык нәрсәләрне көпчәкләре белән изеп-таптап, пост янынннан узып киттеләр. Машиналарның маскировкаларын тикшереп чыкканнан соң, Кам Люкны куып җитте. Отделение командиры дошман ягына ярдәмгә ашыгучы частьларга каршы ут ачарга боерык бирде.

Шыу да әнисе белән иңгә-иң торып көрәшәчәк. Моңарчы аны әсиргә санап йөрткәннәр иде.

Камның да хәзер күзләре яшьләнми, тик йөрәге генә нигәдер тыныч түгел. Аның абыйсына бу форманы кидерткән кеше — кем? Аның кулына корал тоттыручы, янкилар джипын сакларга боерык бирүче — кем? Үзебезнекеләргә... үз туганы Камга атарга кушучылар кемнәр?!

— Америкалылар!

Сугыш хәрабәләрен, кешеләргә вакытсыз үлем, канлы күз яшьләре, кайгы-хәсрәт китерүчеләр — алар америкалылар! Бөтен кабахәтлек аларның «цивилизаторлык» юлы белән эшләнә. Кам һәм аның абыйсын чолгап алган пычрак ятьма да алар кулы белән үрелгән, аларга тын алырга да ирек бирмәүче, ике сүзнең берендә юк итү белән янаучылар да — шул ук америкалылар. Кам бу ятьмәдән котылды. Инде абыйсы да котылыр. Тагын бик күп яшьләр һәм аларның яшьтәшләре бу тозактан котылу өчен канлы көрәш алып барырлар. Безнең ул көрәшебезне бөтен прогрессив кешелек дөньясы яклый һәм Көньяк Вьетнамдагы Каршылык күрсәтүче көчләрнең җиңеп чыгачагына алар нык ышана.

Яңа көн туып килә. Башын горур тоткан, җитди һәм уйчан Кам зур ышаныч белән алга атлый. Ул көч ягыннан ун тапкыр өстен коралланган дошманга каршы бара...

*Мин Тхюи*

# ВАКЫТЛЫ КИЛЕШҮ КӨНЕНДӘ АТЫШЛАР

Бүгенге иртә, чыннан да, бик гаҗәеп иде. Көнчыгыштан искән йомшак җил Тхатьның йөзен сафландырып җибәрде. Йөрәгендә таш булып каткан авырлыкны таратты. Зәп-зәңгәр күк йөзе иртәнге кояшның күгелҗем нурларына коена. Кояш нурларыннан чит-читләре аксыл-кызгылт төскә кергән мәһабәт ак болыт өемнәре ашыкмый гына илнең көнбатыш ягына китеп баралар. Таң белән бергә уянган карлыгачлар да, каты кычкырып, яз килүен ашыктыралар кебек...

Әйе, Вьетнам «республикасы»ның җәяүлеләр гаскәре сафында хезмәт итүче гади солдат тормышында мондый иртәләр бик сирәк очрый... [2]

---

[1] «Демуазель» — кәләш (франц), биредә самолет-разведчик мәгънәсендә.
[2] Сүз Көньяк Вьетнамдагы курчак хөкүмәт гаскәре турында бара.

Тхать җай гына атлый бирде, әмма кызуларга ашыкмады, чөнки барасы юл болай да кыска. Бу рәхәт прогулка озаккарак сузылсын. Вакыт-вакыт борылып, ул күкрәген кояшка куйгалады, кулбашларын турайтты һәм тирән-тирән итеп саф һава сулады.

Аның күкрәгендә Гайсә пәйгамбәр сурәте төшерелгән бөти чайкалгалап бара. Тхать күзләрен әле күккә, мәһабәт болытларга төби, әле кара куючкылланып күренгән ерактагы агачларга карый. Киң канатларын салмак кына кагып, һавадан ләкләк очып үтте. Тхать, иреннәрен тыныч кына кыймылдатып, карашы белән аны озатып калды...

Аның кәефе минут саен яхшырганнан-яхшыра барды, ул хәтта ниндидер бер көйне көйләп җибәрә башлады. Тхать үзен дөнья мәшәкатьләреннән арынган кебек хис итте. Юл буенда үсеп утырган куе үләннәр дә аңа бүген шомлы булып күренмәде. Агач яфракларын өереп исеп куйган җил дә, аны сәламләп, аның алдында бии, гүя баш ия кебек.

Тхатьның йөрәген ниндидер ышану һәм тынычлану хисе биләп алды. Әйе, аның куллары гадәттәге металл авырлыгын сизми, йөрәге бөтенләй тыныч иде. Автоматын үзенең фортында калдырган иде ул. Бу аңа ирек һәм җиңеллек бирде.

Хәзер Тхать ялгышмавына чын күңеленнән ышанды. Азатлык фронты, католик диндагеләр рождество бәйрәмен (Гайсә пәйгамбәр туган көнне) авылларында тыныч үткәрсеннәр өчен, атышларны ике тәүлеккә туктатып торырга карар бирде. Һәр төн Азатлык фронты отрядларының рупорлары рождество көнендәге вакытлы килешүләрне хәбәр иттеләр. Ә моннан өч көн генә элек Тхатьның дусларыннан берәү аңа каяндыр бер листовка табып китерде, анда да атышларны туктату турында әйтелгән иде. Хәер, Тхать моңа болай да ышанган иде инде. Армия офицерлары, контрразведчиклар һәм психологик сугыш белән идарә итүчеләр вьетконгчыларның усал ниятле һәм кан эчкеч булулары турында күпме генә уйдырма хәбәрләр һәм «документлар» таратмасыннар, чынлыкта, тормыш моның киресен раслады. Фронт ай календаренча Яңа ел көнендә дә һәм Камбоджа бәйрәмнәре[1] вакытында да атышларны туктату турындагы вәгъдәсендә нык торды. Ә өстәвенә тагын Фронт гаскәрләре тарафыннан элек әсир алынып, бер айдан соң ирекк чыгарылган таныш солдатлар да, Тхатьның фикер йөртүенә караганда, ышандырырлык нәрсәләр турында сөйләделәр.

Шуңа күрә бүген йокыдан уяну белән үк Тхать, берничә иптәшен ияртеп, рождество көнендә өйгә җибәрүләрен сорар өчен комендатурага юнәлде. Башта офицерлар аның белән килешмәделәр, ләкин солдатларның үз сүзләрелеге барыбер өскә чыкты. Семьясы бик ерак булганга, Тхатька гына китәргә рөхсәт итмәделәр. Аннары ул рождество көнендә якын авылда булган туганнарына җибәрүләрен таләп итте, анда ул чиркәүгә бәйрәм гыйбадәтенә барырга ниятләнә иде.

«Кеше кай мәлне үзе килеп капкан җирдән чыгарга тырышмаса, ул читлектәге кошны хәтерләтә... Һәркем көченнән килгәнчә үз максатына ирешергә тиеш...» Рота канцеляриясеннән чыгып барганда Тхать әнә шулай дип уйланды. Юлда барганда очраган бер танышына: «Фронт безгә үз иркебезчә бәйрәм итәргә рөхсәт итте. Шәп бит, ә? Кемдер сиңа атар дип шикләнмисең хәзер...» дип сөйләнде.

Чиркәүдә гыйбадәт тәмам булгач та, Тхать, хатынының туганнарына барып, анда иркенләп күңел ачарга һәм, әлбәттә, аяктан егылганчы эчәргә кирәк, аннары йокы туйдырырга, ә икенче көнне иртә белән үк хатынына чакырып хат язарга кирәк булыр, дип күңеленә беркетеп куйды.

Шундый татлы уйларга чумган хәлдә, күршедәге Ча-эть фортына килеп җитүен сизми дә калды. Форт каршысындагы тыкрыкта бер төркем солдат күренде. Шунда ике кулын чалбар кесәсенә тыгып, тыкрык уртасында басып торучы форт коменданты күзенә чалынды. Аның да күкрәгендә Гайсә сурәте төшерелгән бөти асылынып тора иде.

— Әй! Кая җыендың болай?

Комендант Ча-этьның эт кебек усал һәм җиңел холыклы кеше булуын алдан белгәнгә, Тхать аның белән бәйләнергә теләмәде. Ул, аның янына килеп, устав кушканча сәлам бирде дә:

— Теләгемне үтәргә рөхсәт итегез, мин рождествоны бәйрәм итәргә барам, — диде.

---

[1] Көньяк Вьетнамда камбоджалылар (кхмерлар) яши торган районнар да бар.

— Кем рөхсәт итте, кем җибәрде сине?

— Сезнең рөхсәтегез белән, әфәндем... Үз командирым җибәрде. Бер мине генә түгел, тагын бик күпләрне...

— Ник ялгызың сөрелеп йөрисең. Вьетконг этләре башыма җитәр, дип уйламыйсыңмы?

— Ни бит... — Тхать шунда тотлыккандай булды. — Фронт кешеләре атышларны туктатырга сүз биргәннәр...

— Тукта, тел бистәсе!

Офицер, башын чайкап, кесәсеннән резинасын алды һәм шуны, авызына кабып, әвәли башлады.

— Әле, хәзер үк үз фортыңа кайтып кит!

— Ни бит...

— «Ни»елдәмичә генә үкчәңне күтәр! Бәйрәмсез дә яшәрсез! Ник көттерәсең, кайтып кит, диләр бит сиңа!

Дулкынланудан Тхатьның яңаклары кызарып чыкты.

— Бүген бит рождество, иң изге көн. Фронт та рөхсәт иткән... Семьям белән күрешә алмасам, миңа бик зур гарьлек. Мин — католик, ни өчен миңа чиркәүгә барырга ярамый?

— Син нәрсә, хайван, минем белән сатулашырга уйлыйсыңмы? Әле, хәзер үк ычкын моннан! Синеңчә, Фронт миннән өстенрәкмени?

Тхать, түзәр хәле калмагач:

— Әлбәттә, сез Фронттан өстенрәк. Тик шунысы гаҗәп: ни өчен соң сез шушы вакытка кадәр аларның гаскәрләренә копалларын ташларга әмер бирмисез дә үз кулыгыз белән аларның берсен дә калдырмыйча әсирлеккә алмыйсыз, — дип кычкырды.

Солдатларның күбесе, елмаюларын яшерергә теләп, читкә борылды. Комендантның йөзе кызарынып китте һәм ул, чәйни торган резинасын тешләре белән кысып, тагын да шашыныбрак җикеренергә тотынды:

— Урә кат! Урә кат! — дим мин сиңа.

— Мин урә катмаячакмын. Командирым миңа «урә катып» түгел, ә үзем теләгәнчә йөрергә рөхсәт бирде, сезнең мине тоткарларга хакыгыз юк.

Тхать борылып китә башлады. Комендант шашынып шунда ук пистолетына ябышты һәм Тхатька төзәде.

— Эх, син, фәлән-төгән... Эт урынына атып үтерәм бит!

— Ат! Үтер! Мин барыбер...

— Тукта!

Бер-бер артлы өч тапкыр аткан тавыш яңгырады. Тхать гөрс итеп юлга ауды. Сугыш сөреме сеңгән юлдагы үләннәр аның күкрәк ярасыннан ургылып чыккан кайнар канга коендылар. Соңгы көчен җыеп, Тхать:

— Кеше үтерүчеләр! Кеше ашаучылар! Алла үзе җәза бирсен сезгә! — дип кычкырды. Аның карлыккан тавышы бөтенләй хәлсезләнде. — Егетләр, күрәсезме, алар безне нәрсә эш...

Һәм ул шунда кинәт тынып калды. Бармаклары көзән җыергандай кысылдылар, тәне яшәү өчен соңгы тапкыр талпынгандай бөгәрләнеп килде. Ул, тагын нәрсәдер әйтергә теләп, башын артка бөрды, ләкин бусы аның иң соңгы сулыш алуы булды.

Ике солдат йөгереп килеп җитте. Алар аның алдында баш иделәр. Берсе калтыранган аскы иренен тешләгән иде.

Тыкрыкта торган берничә солдат кан сауган күзләре белән комендантны эзләп артка борылдылар. Ә куллары винтовка прикладларын кыстылар...

Еракта-еракта, бушлыктагы дулкыннар сыман, чиркәү чаңы тавышы ишетелде.

Ә. СИНЕГУЛОВ тәрҗемәләре.

—◆—

*Фатих Хөсни*

# УРЫННАРЫНДАМЫ СҮЗЛӘР-СОЛДАТЛАР?

Солдат хезмәтендә булып кайткан кешеләр беләләрдер: анда иртән һәм кичен, роталарны тигез сафларга тезеп, кешеләрне барлап чыгалар. Һәм бу көн саен шулай эшләнә. Кешеләр күп һәм төрле булган җирдә, шул төрле характердагы кешеләрне бергә укмаштырып, барысын да тиешле тәртипкә буйсындырып, билгеле максатны башкарырлык көч итеп әзерләгәндә, күрәсең, шулай «вакланмыйча» мөмкин дә түгелдер. Күңелгә әледән-әле шундый чагыштыру килә: язучы өчен дә сүзләр, билгеле бер дәрәҗәдә, стройдагы солдатлар кебек торырга тиешләр түгелме соң? Һич югы, күплекләре, ишлелекләре ягыннан, әйе, алар арасында зур гына охшашлык бар. Шулай ук төрлелекләре белән дә. Бигрәк тә аларның әсәрдә язучы куйган идея-эстетик максатка, һәркайсы нәкъ үз урынында торып, хезмәт итәргә тиешлекләре ягыннан.

Бу озын һәм, беренче карашка, беркадәр сәеррәк яңгырый торган чагыштыруны укучылар гафу итсеннәр, мин аны, үз нәүбәтемдә, шулай ук ачык бер максат белән эшләдем. Көндәлек әдәби практикабыздан чыгып, мин әледән-әле бер мәсьәлә тирәсендә борчылып уйланам: без — язучылар — үз ихтыярыбызда булган сүзләрдән-солдатлардан барлык очракларда да тиешенчә файдалана беләбезме икән? Аларның нәкъ үз урыннарында булуларына, нәкъ үз нурларын сибеп, шул куелган урынны һәм язучының әсәрдә куйган максатын яктыртып торуларына тиешенчә игътибар итәбезме икән? Әлбәттә, казарма тәртибе кертеп, сүзләрне көнгә ике мәртәбә — иртән һәм кичен — тикшерү ягында түгел мин. Ләкин әллә нидә бер булса да әсәрләребезне шушы яктылыкта үзара тикшерсәк, файдасы бик тияр иде. Һич югы, әллә нидә бер, үзенең шушы мәсьәлә буенча уйланулары, иҗат лабораториясендәге кайбер тәҗрибәләре белән уртаклашып, танылган әдипләребез чыгыш ясасыннар иде. Барыбыз өчен дә, бигрәк тә каләмдәш яшьләребез өчен, кызыклы булыр иде. Кызганычка каршы, андый чыгышлар да күренми. Артык тыйнаклыктанмы икән, әллә әдәби телебез турында сөйләшүдән тәм тапмый башладыкмы?

Озакка сузылган бу паузаны бозып, шушы юнәлештә фикер кузгатырга бер сәбәп булмасмы, дигән яхшы теләк белән, гора торгач дигәндәй, мин үз «командалыгым» астындагы сүзләрне-солдатларны барларга булдым әле. Бөтенесен дә булмаса, һич югы кайберләрен.

Хәер, бик ул хәтле гора торгач та түгел, җае шулай килеп чыкты. Соңгы вакытларда мин үз әсәрләремнең сайланма томнарын әзерлим. Шул уңайдан сайлаган әсәрләремнең барысын да яңадан бер кат күздән кичерергә, мөмкин булган төзәтмәләрне кертергә, кыскасы, иләгәнне янә бер «җиз иләк» аша үткәрергә туры килде. Монда минем аеруча кызыксыну белән башкарган эшем — тел ягыннан ясаган күзәтүләр булды. Яшерен-батырын түгел, моңарчы мине берәү дә телне белмәүдә яки телгә игътибарсызлыкта гаепләп чыкканы юк. Ничек кенә булмасын, мин үземнең йомшак ягымны бу тирәдән һич эзләми идем. Кызыклы бер хәл: вакыт узып, үземнең моннан байтак еллар элек язылган әсәрләремне салкын акыл һәм яңа «күз» белән укый башлагач, нәкъ әнә шул нык дип саналган «крепость» буйларында урынсызрак басып торучы яки җыйнаклыгы тиешенчә булмаган сүзләр-солдатлар күрдем. Телне бозу рецидивлары яки, берне уйлап та, тел чаралары җитешмәү аркасында, икенчене язып кую турында сүз бармый монда — ул яктан йөзне кызартырлык кытыршылыклар таба алмадым. Монда сүз, югары таләптән чыгып, әдәби телне, барыннан да элек, кешенең рухын, зәвыгын, гүзәллекне күрә һәм «тыңлый» белү сәләтен тәрбияләүче сәнгать чарасы итеп карап, кай урыннарда шул җитди максат югарылыгына күтәрелеп җитмәгән «сүзләрне-солдатларны» урыннарына утырту турында барыр.

Бигрәк тә күзгә тотылган яклар:

Модалы мавыгуларга бирелеп, халык теленең асыл нигезләреннән аерылып китүләр юкмы?

Телнең эчке аһәңенә ябышып ук ятмый торган дисгармоник сүзләр килеп кермәгәнме?

Сүзнең морфологик төзелеше җимерелмәгәнме?

Ачуланасы урында сүз ачулы чыкканмы? Күршеләре ачуланганда, ят тән булып, теш ыржайтып «көлеп утыручы» сүзләр юкмы? Яки, киресенчә, күршесендәге башка сүзләр шаулап көлеп торганда арага сытык чырайлы урынсыз сүзләр кысылмаганмы?

Һәм гомумән җөмләдә сүзләрнең үзара татулыгы, кардәшлеге ни дәрәҗәдә? Ахыр чиктә, җөмләнең эчке музыкасы, көче һәм мускулы әнә шуннан — җөмлә эчендә сүзләрнең берсе икенчесенә гармоник ябышып ятуыннан килеп туа да бит инде.

Бер башлагач, ихтимал, болардан башкалары да килеп чыккандыр. Кайберләре мисаллар китергәндә ачыклана барыр дип уйлыйм. Мисаллар дигәннән, төрлегә сибелеп игътибарны таркатмас өчен, мин, югарыда әйткәнемчә, мисалларны үземнән, анда да тик бер әсәремнән — «Җәяүле кеше сукмагы» дигән романымнан гына китерергә булдым.

Әйтик, менә революциягә хәтле иске авылда салымнарны үз вакытында түли алмаган фәкыйрь хуҗалыклардан түрәләр, «недоимка» өчен дигән булып, кулларына нәрсә очраса шуны җыеп, икенче төрле әйткәндә, талаганны талап йөриләр. «Төркем... өе өстенә ишелергә торган ярлы кешеләр турында озаклап тукталып кала һәм аннан нинди булса да *бер әйбер* йолкып алып чыгып чанага атмый торып, кузгалып китми иде» дип басылган 1959 елгы басмада. Әйберме, әллә әрмәкме, дип уйланып калдым мин әсәрне яңадан караганда. Әлбәттә, «әйбер» дә мөмкин. Әмма бу очракта «әрмәк» яхшырак. Яхшырактан да бигрәк, ачулырак. Социаль тамырны төгәлрәк ача. Әрмәк икән — инде аның әйберлеге ташка үлчим генә калган дигән сүз. Беткән, тетелгән, иңнән төшеп калыр чиккә житкән әйбер — «әрмәк». Дөрес, кайсы якларда чикмәнне дә «әрмәк» дип йөртәләр, ләкин бу очракта да күбесенчә иске чикмән күздә тотыла булса кирәк. Һәм шулай итеп, «әйбер» сүзен «әрмәк» сүзе белән алыштырдым.

Шушындыйрак тагы берничә мисал. Бар — «табыш алу», бар — «табыш күрәү». Хәйләкәр һәм ерактан күреп эш итүче авыл кулагы Сәлмән бай һәм аның «яңачарак» алдашырга өйрәнеп килүче малайлары, эшне казна поставкасына җайлап һәм шул казна эше сылтавы белән сугыштан качып калуны күздә тотып, алпавыт Антоновтан су тегермәне сатып алалар һәм шундук, аның бөтен ташларын ходка җибәреп, «бу тегермәннән күп кенә *табыш ала* башладылар». Шулай чыккан элекке басмада. Ә мин бу очракта, әлеге шул социаль тамырны төгәлрәк ачу максаты белән, Сәлмәннекеләрдән табышны *күрәтерге* үк булдым. Юк, алар табышны алып кына калмыйлар, алар табышны *күриләр*.

Яки менә өченче бер мисал: атсыз һәм тапныр кешесез калган фәкыйрь бер карчык, үзенең биш таяклык җирен вакытында ничек сукалатып-чәчтерергә белмичә, кырдан, Сәфәргали сөрә торган җир башыннан, авыз эченнән нидер сөйләнгәләп үтеп бара.

— Әй, әби, нишләп йөрисең? — дип сорап куя Сәфәргали.

«Сәфәргалинең кызыксынуы әбинең күңелен йомшартты булса кирәк, тотынды теге карчыкларча зарланырга, тотынды зарланырга».

Ә нишләп әле ике мәртәбә «зарланырга»? Нишләп мәгънәне көчәйтә төшә торган икенче бер сүз тапмаска? Әйтик, менә: «тотынды зарланырга, тотынды *еларга*» булса? Кабатланудан да котылачакмын, елау — мәгънәне дә көчәйтә төшәчәк. Иң әһәмиятлесе: «тотынды еларга» — карчыклар табигатенә төгәлрәк туры килә. Димәк, бу сүзнең урыны нәкъ менә шушында булса кирәк!

Тасвирлана торган хәл-әхвәлнең социаль төсмерен төгәлрәк бирү максаты белән ясалган мондый алыштырып куюларны яки, алыштырылырга тиешле булып та, күз житмичә калган урыннарны байтак китерергә мөмкин булыр иде, әлбәттә. Әмма эш мисалларның күплегендә, азлыгында түгел. Эш шунда: үз урыннарына килеп утырганнан соң сүзләр мин күздә тоткан максатка, минем максатка күбрәк һәм активрак «эшли» башладылар кебек. Ә бит язучы өчен иң зур сәнгать — сүзне аңлы рәвештә үз максатына эшләтә алу, шул максатка аның бар җегәрен юнәлтә белү.

Югарыда без җөмлә эчендә сүзләрнең үзара татулыгы, кардәшлеге турында һәм шуннан килеп туа торган музыкальлек, аһәңлелек, телнең мускуллы булуы турында гәп башлаган идек. Хәзер менә шуны бераз ижекләбрәк карыйк. Дөресен әйткәндә, бу — җөмлә эчендәге «операция» генә дә түгел. Бу — кайвакытта аерым бер кисәкләргә, эпизодларга карата да үзенең көчендә кала. Әйтик, бер эпизод үзе дә, анда катнашучылар да җиңелчә юмор планында ачыла башлады, ди. Һәм шул юморлы эпизодка тамакка тыгыла торган булып үтә житди бер сүз килеп кысыла, һәм колак та, күңел дә бу диссонансны шундук тотып ала.

Көннәрдән бер көнне, этисе йомыш белән җибәргән җиреннән, Сәфәргали, үзе дә рәтләп сизмәстән, Зәйтүнәләр капкасына барып сугыла һәм ишек алдында кызның этисе Габдулла абзый белән очраша. Һәм аптырабрак кала. Аптырарсың — кыз күрмәкче булып барып кер дә, кызның этисе белән күзгә-күз карашып кал әле. Кызыклы ситуация бит, әйтеп тә торасы түгел!

«— Сезгә тегүче кирәк түгелме алай са? — дип дуамал гына сорап куя Сәфәргали, картка туры ук карарга шулай да бик кыймыйча. Бу малайның тегүче малае икәнлеген белгәч, Габдулла абзый аның белән җайлабрак сөйләшергә була.

— Сез бит эшләгән өчен акча сорый торгансыздыр? — ди ул, малай белән шаярырга теләп.

Эш болай шаяртып сөйләшүгә киткәч, хәер, Сәфәргали дә сынатмый.

— Юк, эшен эшләгәч, акчаны безгә сорамыйча гына бирәләр, — ди ул һәм үзе, бу четерекле хәлдән ничек тә тизрәк ычкынырга тырышып, капкага таба атлый».

Күрәсез, монда тасвирлана торган хәл дә, анда катнашучылар үзләре дә җиңелчә юмор планында бирелә. Картның шук соравына игътибар ит та, малайның аңарга кайтарган җавабын кара...

Һәм аннары авторның шуны уңайдан ясаган авыр һәм үтә житди комментарийсын укы: «Габдулла агай дөнья күргән

кеше иде, бу яшүсмер егет әнә, чынлап та, тегүчедер тәсле булып күренде». Нишләп? Нәрсәгә нигезләп? Авторның үтә житдилеге, күрәсез, бу кисәктәге жиңелчә юморны кинәт жимереп ташлады һәм шул кинәтлек Габдулла агайның малайны тегүче итеп тануында логикасызлык та китереп чыгарды. Бу урында берничә төрле каршылык күз алдында. Беренчедән, Сәфәргали әле бу чагында егет түгел, яшүсмер малай гына. Малайның да аптырап калганрак минутлары. Икенчедән, Габдулла абзыйга аның «тегүчедер төсле булып күренүе» өчен нигез юк. Өченчедән, тел ягыннан «яшүсмер егет» дип раслау бик үк төгәл дә түгел. Яшүсмер икән — яшүсмер, егет булырга әле иртә. Егет икән — егет, яшүсмерлекнең монда катнашы юк.

Соңгы басманы әзерләгәндә мин бу четерекле урынны: «Габдулла агай дөнья күргән кеше иде, бу яшүсмер *тел бистәсе* әнә, чынлап та, тегүчедер төсле булып күренде» дип редакцияләдем. Һәм бераз котылдым дип уйлыйм. Беренчедән, Габдулла абзыйның малайны тегүчедер дип кабул итүендә азмы-күпме логика килеп туды. Чөнки ул — дөнья күргән кеше — тегүчеләрнең шулай телләренә салынган кешеләр икәнлеген белә. Икенчедән, «яшүсмер егет» дигән каршылыклы тәшенчәдән качтым. Өченчедән, «тел бистәсе» дигән характеристикам белән шушы эпизодтагы юморны саклап калдым, геройларым белән бер ритмга бастым.

Бусы озынгарак китте. Тагын бер-ике кыскарак мисал. Садыйк муллада тегү теккәндә, бер кичне шулай сүздән сүз чыгып, иске фикерле кадим мулланың Сәфәргалигә, янәсе, аның җәдит мәдрәсәсендә укыганлыгы өчен жене кузгала. Һәм ул аны сынап карау нияте белән пәйгамбәрләр мажарасы язылган иске бер китап тоттыра: янәсе, укып кара шушыны, ничек ермачларсың икән?

Малай башта авыррак ермачлый, соңга таба «шома гына, төртелмичә генә укый» башлый. «Укый» — бу урында артык житди, күршесендәге башка сүзләр, уен-көлкеле настроение белән ничектер «туганлаша» алмый кебек. Шуңа да игътибар ит: халык сөйләмендә шулай жиңелчә көлү-мыскыл тоны белән әйтелгән раслауларны без әледән-әле ишетеп киләбез ич — «малай урысча-татарча сукалый башлады хәзер», «акка кара белән язылганны мин аны үзем дә сукалыйм». Шуларның барысын да искә алып, бу очракта мин әле бик үк шомарып житмәгән Сәфәргалине укытырга түгел, бары тик *сукалатырга* гына булдым.

— Кабаланма ул кадәр, мин киткәч чыгарырсың,— дип, килененә боерык бирә Сәлмән карт, кладовойга ябылган Мидхәтне кайчан чыгарырга икәнлеген аңлатып.

«— Кабаланма ул *тиклем...*» дип үзгәрттем мин аны бу басмада. Тел нечкәлекләренә һәм, гомумән, берниндн нечкәлекләргә дә игътибар итәргә өйрәнмәгән иске фикерле авыл колагы өчен, «ул кадәр» дип нечкәртеп сөйләүгә караганда, «тиклем» дип сүзне бозып сөйләү төгәлрәк туры килә кебек.

Кай урында сүзнең азагын бераз кыландырып, морфологик кушымчалар өстәп кую да образның сөйләү рәвешен төгәлрәк бирүгә һәм, димәк, образны тулырак ачуга ярдәм итә.

Шул ук Сәлмән карт жәмәгать жыенында старостаны, аның жыемнардан кергән акчаны үзләштерүен акларга тырышып, бик төче телләнеп, жаһилләнеп, сөйли-сөйли дә, ахырдан, ышанычлырак чыксын өчен:

— Менә Садыйк хәзрәтне чакырып карыйк, ул да әйтеп бирер *әгәр* кирәк булса, — дип куя.

Соңгы, төзәтелгән редакциядә мин моны: «Менә Садыйк хәзрәтне чакырып карыйк, ул да әйтеп бирер *әгәренки* кирәк булса» дип төзәттем. Бер сүзнең «койрыгын» чак кына кыландырып, бөтереп кую гына бар. Ләкин әнә шул бәләкәй генә «операция» аркасында Сәлмән картның тәлкелеге, сүзләрне бөтереп-бөтереп һәм, мөмкин чаклы китапчарак итеп сөйләп, күз буярга тырышуы ныграк ачыла кебек, миңа калса.

Яки икенче бер урында Сәфәргали «недоимка» жыеп йөрүчеләр артыннан тагылып бара-бара да, ахырда, тыштан караганда гына мәзәк кебек күренгән бу эшнең асылын аңлый төшкәч, автор белән икесе бер авыздан дигәндәй:

— «Юк, башта күренгәнчә мәзәк эш түгел иде бу!» — дип нәтижә ясап куя. Җөмләнең әйтелешенә, жөмлә эчендәге сүзләрнең урнаштырылуына караганда, бу — Сәфәргали чыгарган нәтижәдән дә бигрәк, аның исеменнән, ләкин үз сүзләре белән автор чыгарган нәтижә төслерәк яңгырый. Шулай яңгырамасын өчен соңгы редакциядә мин аны «юк, башта күренгәнчә *үк* мәзәк эш түгел *икән лә бу!*» дип үзгәрттем. Бу жирдә кечкенә генә кушымча өстәлде, икенче урында инкарь итүнең редакциясе бераз үзгәртелде. Әнә шул сизелмәслек кенә үзгәрешләрдән малай үзе яки ул чыгарган дөрес нәтижә генә түгел, ә бәлки малайның бу темага кул селтәп, борылып китеп баруына кадәр күренеп кала кебек. Һәрхәлдә, минем үземә шулай тоела.

Кайвакытта болай да була. Син бик матур һәм оригиналь чагыштыру таптым дип уйлыйсың. Дөрес, чагыштыруның үзен генә аерып караганда, чынлап та уңышлы табыш булып күренүе мөмкин. Ләкин тормыш картинасының шул өзектә сурәтләнгән дөреслеге һәм, бигрәк тә, образның социаль жирлеге белән бәйләп караганда, беренче карашка бик нәфис күренгән бу «табыш»ның ят тән булып кычкырып торуы да мөмкин икән.

Әлеге шул «Җәяүле кеше сукмагы» романын үземчә янадан бер кат әнә күзе аша үткәзеп, нык кына чуарлап, яңадан машинкада суктырып биргәннән соң, рецензент Ибраһим Гази, яңа күз белән укып, аңардан тагы байтак кына «атылмый калган киек кошлар» тотып күрсәтте. Шулардан берсе: Сәлмәннәр йортына килен булып төшәргә әзерләнгән, киенгән-ясанган, бай зиннәткә төренгән, ләкин, сөйгән кешесеннән аерылып, сөймәгән кешесенә китү сәбәпле бу зиннәтләрнең берсе дә күзенә күренми торган моңлы, борчулы Зәйтүнәне

мин өереннән аерылып калган ялгыз аккош белән чагыштырган булганмын. Рецензент шунда ук карандаш белән кулъязма читенә «артык нечкәртелгән, тамакка йокмый» дип язып куйган. Бу мине чынлап та уйландырды. Зәйтүнәнең шул минуттагы рухи халәтенә, җилдә шаулап торган алма бакчасы кебек, йөргәндә шаулап торган атлас күлмәкләренә карагында, минем аны өереннән аерылып калган аккошка охшатуым үзен беркадәр аклый да кебек. Ләкин онытырга ярамый: Зәйтүнә бит гади авыл кызы, Габдулла агай кызы. Гомуми обстановка бик кырыс. Шуның өстенә тагы бичараның кешегә әйтә алмый торган тау чаклы кайгысы бар. Рецензент дөрес күрсәтә: нигә монда ул хәтле купшылык кирәк! Янадан караганда мин «аккош»ны каз белән, оясыннан адашып калган ялгыз каз белән алыштырдым. Кыр казы түгел, йорт казы. Бу инде җирнеке, әйтергә мөмкин, шул ук Габдулла абзыйларның үз казлары ук булуы мөмкин. Монда зур гына уртаклык һәм охшашлык бар.

Ә менә шул ук рецензент иптәшнең «Пөзек кашы» повестена карата әйтелгән фикерләрендә, Айдарның электә карангылы-яктылы шахталарда озак еллар калып сукырайган атларны кызганып, шунда ук тагы авылда калган һәм яшел тугайларда утлап йөри торган чабыш атларны сагынып искә төшергән вакытындагы «утлап йөриләр»не «чабышып йөриләр» белән алыштырырга киңәш бирүе мине ышандырмады. «Утлап йөриләр» — ул чабышып йөриләр түгел. «Утлап йөрү» төшенчәсенә — атларның яшь үләннәрне кырыккалап йөрүләре дә, туктап, берсе белән икенчесенең кашынып торулары да яки, тора торгач, болын яңгыратып кешнәп җибәрүләре дә керә.

О, бик зур һәм бик кодрәтле нәрсә ул — сүз. Әлбәттә, нәкъ үз урынын табып, үз төсмерләрен салып әйткәндә. Гадәттә, ашыкпошыграк язу аркасында, без аның барлык төсмерләрен дә искә алып житкермибез, урынындамы бу сүз яки урынына ук куелып житмәгәнме? — ул турыда уйлап баш ватмыйбыз. Шуңлыктан, кайбер сүзләрне кирәгеннән артык җигеп, өшәндерәбез, шомарган бакыр акчага әйләндерәбез. Шул ук вакытта океандай бай телебезнең энҗедәй җемелдәүче аерым сүзләре, синонимнары, кулланугa кермичә, әкренләп төшеп кала, онытыла бара. Хәлбуки, телгә, сүзләрнең үз урыннарында, үз бизәкләре белән яңгырауларына игътибар, шул турыда кайгырту, шул игътибарлылыкны иң элек үзеңдә булдыру, аннары шуны каләмдәш иптәшләреңнән сорый белү — бу соң, барыннан да элек, без язучылар эше түгелме?

Шуннан чыгып, үз даирәбез кешеләренә минем берничә практик тәкъдимем бар.

*Беренче.* Нәкъ менә шушы яктылыкта торып, безнең танылган әдипләребез, әллә нидә бер булса да, безне үзләренең лабораторияләренә алып керсеннәр, бу юнәлештә алар ничек эшлиләр, сүзләрнең көченнән ничек файдаланалар, әдәби телебезне тагын да баета төшү өстендә нәрсәләр эшләргә кирәк, кай якларыбыз аксый? — шуларны укучылар белән уртаклашсыннар иде.

*Икенче.* Бер үк вакытта үзара тикшерешү, береннең әсәрен икенчең нәкъ әнә шушы яктылыкта «укып карау» да күп кенә уңай нәтиҗәләр бирер иде. Берәүдән дә сер түгел, күп очраша, күп укый торгач үз әсәреңдәге «адашып йөргән» сүзләрне күрми башлыйсың. Ә икенче күз аны тизрәк күреп, тизрәк эләктереп ала.

*Өченче.* «Казан утлары» журналын чираттагы тикшерүләрдә, Язучылар союзы идарәсе, мәсьәләне үз агымына ышанып калдырмыйча, аерым кешеләргә алдан ук журналны нәкъ менә шушы аспектта да күзәтүне тапшырырга тиештер кебек.

Ниһаять, *дүртенче* теләк: шул ук «Казан утлары» журналында һәм башка органнарда әдәби телебезнең бүгенге торышы, аерым проблемалары, коммунистик төзелеш практикабызда телебезнең баюы, икенче телләр белән аралашу исәбенә нинди яңа сыйфатлар ала баруы кебек мәсьәләләр буенча шушы өлкәнең әһелләре — фән эшлекләре ясаган чыгышларны бик бик күрәсе килә.

# *Галимҗан Ибраһимовның туууына 80 ел*

*Художник Т. Хаҗиәхмәтовның «Безнең көннәр» романына ясаган иллюстрацияләре*



«Цирк мәйданында гаскәр, полиция белән бәрелешеп таралгач, ул яңадан анасына кайта алмады, кайбер яшерен әйберләрне качырып саклый торган Гәүһәр туташны күреп, аның аркылы аңлашты да төнге сәгать уникеләрдә кызыл приказчик Фәхринең квартирына кунарга барды».



«Бу арада инде кара демонстрация циркның капкалары, коймалары тирәсен үзенең тәреләре, патша сурәтләре, чалмалары, өч төстәге флаглары, поплары, муллалары, ес-башын алмаштырган полицейскийлары, охранка агентлары белән бөтенләй чолгап алган иде инде».



«Әмма аның белән бергә участокка ябылган икенче шәкерт Исламия мәдрәсәсеннән җырчы Сәхип икән. Аның ябылуы сәяси түгел. Ул башта кыюсызланып торды да әйтә куйды:

— Мин юләрлегем сәбәпле эләктем.— ди».



«...Тән суынган. Җан әсәре юк. Ләкин сәбәбе нәрсәдә? Хатын бик күп эзләгәч кенә картның баш сөягендә, җилкә чокырыннан аз гына өстә, каралып каткан ике тамчы кан тапты, шул җирнең тиресен каера төшсә, сөякнең тишелеп чатнаганын күрде. Пуля, шуннан кереп, минем эчендә тукталган икән! Хатын шулай уйлады да, картның үлек гәүдәсен аркасына салып, квартираларына алып китте. Ул аларда бер почмак алып тора иде:

— Эт түгел ич, ничек урамда калдырасың!? — дип, кат-кат үзенең теге мәйданнан китүенең сәбәбен көчәйтергә тырышты.»



«Без, ди, яктылыкны каладан көтәбез. Кая, нәрсәгез бар? Безнең эш мужикча былыр: үзем кебек ярлы-ябагайны җыйнармын да... Дүрт чакрымда Әликсәй бояры бар. Шуны басарбыз... Безгә нәрсә? Балта, сәнәк. Калдык-постык мылтык, күгәргән сөңге кисәкләре дә ярый.»

# ДУСЛАР ҖЫРЫ

## ДАГСТАН — ШИГЪРИЯТ ҖИРЕ

*Бала чактан ук бөек Пушкин, Лермонтов, Толстойларның әсәрләреннән укып, әкият дөньясыдай күз алдына баскан чал Кавказ, җырларда макталган Каспий буйлары, батыр, кыю җанлы тау халыклары, поэтик җәүһәрләр тудыручы ашуглары — Сөләйман Стальский һәм Гамзат Цадасалар белән күңелдә яши иде Дагстан.*

*Үткән елның январь аенда, ниһаять, бу тауларны илен күрү мөмкинлеге туды: мин Махачкалада һәм Дагстанның берничә районында булдым.*

*Тәэсирләр бик зур. Махачкаладан атаклы Гунибка кадәр автобуста бару да, таулардагы шоссе юл, юл буендагы тополь, алма, груша агачларының матурлыгы да, автобустагы кызларның авар һәм лезгин җырларын җырлаулары, биек таулар — Кавказ сыртлары, тарлавыклар, шаулап агучы елгалар — барысы да күңелдә онытылмаска калды. Дагстан — күп кенә шәһәрләр һәм тау битләренә тезелгән кат-кат йортлардан торган авыллар иле. Халкы күп төрле: авар, кумык, лезгин, даргин, лаклар... Авыллар һәрберсе үзенчә атаклы: Кубачи авылында — оста көмешчеләр яши, Унцукол авылында бөтен Союзга атаклы таяклар ясала, Андида бурка һәм папахалар эшләнә.*

*Гуниб — крепость, легендар Шамилнең соңгы ставкасы, хәзер район үзәге. Дагстанның бөтен авыллары диярлек тарихка, легенда һәм җырларга бай. Гунибта аварлар түгенда булганда, без аларның шактыен ишеттек, кунакчыл хуҗалар безгә күп нәрсәләр сөйләделәр.*

*Авар лиригы — гашыйк Мәхмүд җырлары, атаклы лезгинка биюе, пандур һәм чаганада уйнау белән бергә, Шамил һәм Хаҗи Морат турындагы тарихи җырлар да яңгырады бу мәҗлестә.*

*Хочбар турында җыр бик үзенчәлекле. Җырда феодаллар — нуцалларга каршы көрәшкән ярлы егет мактала. Утта яндырырга хөкем ителгәч, ул нуцалның ике улын да үзе белән бергә сөйрәп, ялкынга ташлана. Ә Чох исемле зур авылда Камалил Бәшир турында легенда ишеттек. Бусында Чох авылы егете, әкияттәгечә матур бер батыр турында сөйләнә. Аны күргән хатын-кыз, ирен, семьясын ташлап китә торган булган. Халык таләп итүе буенча, Бәширне үз этисе үтерә. Хатын-кызлар аның кабереп ачып, хәтта мәетен дә урлап китәләр. Характерлы детальләр: Бәшир нурлы, ак йөзле егет була, аңардан җиргә күләгә төшми, су эчкәндә, тамагыннан су үтүе күренеп тора икән һ. б.*

*Легендар Шамилгә бәйләнешле җырлар да күп. Гунибта Шамилнең, пленга төшкәч, сөйләшүләр алып барган беседкасы бар.*

*...Кавказ матур. Шашкын сулы Койсу елгасы, күп санлы тау чишмәләре дә аның җырыдыр төсле. Ләкин, барыннан да бигрәк, халкының җырлары, моңнары белән көчле Кавказ. Бай фольклор һәм язма әдәбият — аның горурлыгы. Бүгенге чорда, коммунизм төзүче совет халкын сокландыручы Дагстан поэзиясе, аның вәкиле Рәсүл Гамзатов һәм башкалар иҗаты, үзенең традицияләре белән искиткеч бай, тирән эчтәлекле иҗатка — халык җырларына, халыкның беренче шагыйрьләре Батырайларга тоташа.*

*Рәдиф ГАТАУЛЛИН.*

# Дагстан халык җырлары

## Себергә сөрелгән улына ана җыры

*(Даргинчадан)*

Син яшәгән якта, улым,
Төшәме томан түбән?
Әгәр син яшәгән якта
Түбәндә булса томан;
Бел, улым: шушы томан —
әниең сагышыннан.
Син яшәгән якта, улым,
Күк күкриме җәй көне?
Әгәр күкләр күкри икән
Җир өстендә кай көнне,
Бел, улым: бу — әниеңнең
Кайгыдан салган өне!
Син яшәгән якта яңгыр
Явамы кайчакларда?
Әгәр дә яңгырлар яуса
Син яшәгән якларда,
Бел: күктән төшкән ул тамчы —
Ике сеңелеңнен яше!

## Ана һәм кыз

*(Аварчадан)*

— Әни, әни, уян әле,
Бер гаҗәп хәлгә кара:
Яшел үлән үскән анә
Тирә-юньдәге карда.

Әни, түбәгә күтәрел,
Бер сәер хәлгә кара:
Тауларда бозларны каплап,
Чәчәкләр үсеп бара.

— Кызым, калын кар астыннан
Калкып чыгалмый үлән.
Син күрәсең, яз кебек
Бик яшь булганга күрә.

Кызым! Чәчәкләр үсми бит
Тауларда кыш аенда,
Син гашыйк, —
шуңа чәчәкләр
Күрәсең хыялыңда.

●

*(Аварчадан)*

Хатыннар, сез тудырмагыз куркак уллар! —
Кайгы булыр андый улның булуы
Һәм, тапмагыз, сез хатыннар, —
батыр уллар,
Бик зур кайгы андый улның үлүе!

●

*(Лакчадан)*

Мактанма, ир, син үзеңнең туның белән,
Ут шикелле ярсу чапкан атың белән.
Хатын гына ирне чын ир итә ала,
Мактаналсаң, мактан —
яхшы хатын белән!

## Биек таулар

*(Лезгинчадан)*

Туган якның биек таулары,
Итәгендә — чишмә сулары,
О, матур таулар!
Ул тауларда — йөзем бакчасы,
Ә бакчада минем җанашым!
О, бәхетле таулар!
Ерак таулар,
Биек таулар,
Матур таулар,
Бәхетле таулар.
Ташкын сулар бигрәк салкын ла
Күләгәдән аккан чагында.
О, матур таулар!
Әнием бирми мине ярыма,
Сөймәгәнгә ничек барырга?
О, бәхетле таулар!
Кешеләрдә кайгы аз түгел.
Иң зур кайгы йөртә бу күңел.
О, матур таулар!
Күпме кара бу ак дөньяда,
Мәхәббәт бар,
бәхет юк анда.
О, бәхетле таулар!
Ерак таулар!
Биек таулар!
Матур таулар!
Бәхетле таулар!

## Бетте минем җырым!

*(Ногайчадан)*

Бер яшемдә — ак тирмәдә тәпи йөрдем,
Ике яшьтә — сөйләштем мин, «әни»,— дидем.
Өч яшемдә — дуслар белән уйнап йөрдем,
Дүрттә туктаттылар уенымнан минем:
Биш яшемдә — алтын белән чигү чиктем.
Алты яшьтә — матур диган исем йөрттем.
Сигез яшьтә — ясанырга өйрәттеләр
Ә тугызда — җанда кайгы көйрәттеләр.
Ун яшемдә — ярык аша күзләде бай,
Унбер яшьтә — яучы килде, раббым, ходай!
Уникедә — миңа калым килеп җитте...
Унөч яшьтә — алып китте — җырым бетте.

## Куркаклар

*(Кумыкчадан)*

Тирә-якта тынлык —
Ә куркаклар шаулый...
Яу шау-шуы купса —
Куркак якын бармый...
Кайда туй мәҗлесе —
Куркак чыга алга...
Яуга дәшкән чакта
Куркак чигә артка.

Ашап-эчкән чакта
Кызыл йөзле куркак,
Уклар очкан чакта
Куркак йөзе ап-ак...

Мактана бит куркак:
— Мин, ди ул, чын батыр!
Яуда кача үзе,
Сайлый таулар артын.

## Кәләш җыры

*(Татчадан)*

Бу төндә һәркем йокысыз,
Туктамый-тынмый елый кыз:
Ой, дәдә! Ой!
Әтисенә текте бүрек,
Булмады тегеп бетереп.
Ой, дәдә! Ой!
Энесенә яулык чикте,
Чигелми калды бер чите.
Ой, дәдә! Ой!
Нәгышләре — чуар иде...
Иртүк йортка яучы килде.
Ой, дәдә! Ой!
Инде әшне әни, апа,
Төгәлләргә сезгә кала.
Ой, дәдә, ой.

## Омарла Батырай

*(Даргин ашугы, 19 гасырның икенче яртысында яшәгән.)*

Күкрәгемдә ут йөртәм мин,
Урманнарны яндырыр ул.
Белмим, кайчан үземне дә
Шулай көлгә калдырыр ул?!

Таулар-ташларны җимерер көч —
Давыл йөртәм күзләремдә.
Белмим, кайчан үземне дә
Очырыр ул җилләрендә.

●

Мин мавыккан кебек сиңа
Мавыксаң әгәр син дә,
Елганы боз каплар иде
Җәйнен кызу көнендә.

Мин яраткан кебек сине,
Ярата алсаң син дә,
Бозда үләи үсәр иде
Бик салкын кышкы көндә.

●

Син дингез ярында,
Җиде төсле чәчәк.
Бер төсле булсаң син,
Сине кем сөячәк?!

●

Кара урманда күк бүре,
Юлдашым булчы минем.
Кеше күзеннән качыйм мин
Сукмагың белән синең.

Күктәге кара карчыга!
Син дустым булсаң минем —
Эзләремне калдырмыйча
Авыллар үтәр идем.

●

Дингез артыннан калыккан
Кояштан, чыксаң, өйдән, —
Су өстендәге камыштай,
Калтырар минем тәнем.

Тау артыннан чыккан айдай
Тәрәзәдән карасаң,
Камышлыктагы кош кебек,
Сискәнер минем җаным!

Рәдиф ГАТАУЛЛИН тәрҗемәләре.

# БИШЬЕЛЛЫК ВАХТАСЫНДА

*Мәхмүт Хәсәнов*

## ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ, СӘЕТ СӘЛИМГӘРӘЕВ

Тулы исеме Сәетмөхәммәт аның. Иптәшләре Сәет дип кенә йөртәләр: Сәет Сәлимгәрәев.

Үзләрен данга күмгән атаклы нефтьчеләребез турында сүз чыктымы, иң беренчеләрнең берсе итеп аның исемен атыйлар.

Сәет үзенең нибары дүрт кешедән генә торган вахтасы белән ел саен диярлек 8.750 метр чамасы тау токымы бораулап үтә.

Күпме бу?

Бик күп. Ел саен өзлексез рәвештә «кара алтын» биреп торучы 5 яки 6 скважина дигән сүз бу. Кайбер бригадалар, мәсәлән, егермешәр кешедән торган коллективлары белән дә шулкадәр җир бораулап үтә алмыйлар.



— Сәет Сәлимгәрәев 15 ел бораулаучы булып эшли. Шул вакыт эчендә ул бораулап үткән нефть скважиналарын бергә кушсаң, үзе бер промысел булыр иде, — диләр бораулау конторасында.

Һәм бу чыннан да шулай. Сәет Сәлимгәрәев «Татбурнефть» трестының Азнакайдагы данлыклы 3 номерлы бораулау конторасында гына түгел, бөтен республикабызның «беренче номерлы» бораулаучысы булып санала.

Шушы Сәет кебек егетләр белән бит инде Социалистик Хезмәт Герое Михаил Петрович Гринь бригадасы Татарстан шартларында елына 35 мең метрдан да артыграк бораулап үтәргә мөмкин икәнлекне практикада күрсәтте.

Нәкъ инде шуларны рекорд артыннан рекорд куюлары белән бөтен ил нефтьчеләре әледән-әле котлап торалар. Шулар исеменә берничә тапкыр рәттән партиябез һәм хөкүмәтебез исеменнән тәбрикләү телеграммалары килде.

1966 ел исә Сәет өчен аеруча истәлекле булды. Аның вахтасы монарчы әле беркайчан да күрелмәгән яңа уңышка иреште: елның беренче яртысында гына алар 5 мең метрга якын каты тау токымнарын бораулап үтеп, республика буенча янадан рекорд куйдылар...

Хәер, узган ел гомумән башка еллардан күп яклары белән аерылып торды. Язлары да башка елларныкына караганда матуррак килде. Шомыртлар да, алмагачлар да башка елларга караганда күңеллерәк булып чәчәк аттылар.

Юк, бер язы гына түгел, җәе дә искитмәле булды 1966 елның. Мондый матур ел унҗиде ел әйләнәсенә бер килә, диләр картлар.

Хәер, гаҗәп тә түгел, съезд елы иде бит ул.

Яңа бишьеллыкның беренче елы иде.

Нур өстенә нур дигәндәй, Сәет тормышында да узган елны онытылмаслык бер вакыйга булып алды.

Азнакайда нефть чыга башлаганнан бирле эшләп, беренчелекне үз кулында тоткан М. П. Гринь бригадасында гел мактапып кына телгә алынган Сәеткә күп төрле премияләр, кыйммәтле бүләкләр алырга туры килгәләде. Әмма, бүләкнең иң зурын, гомер буена онытылмаслык истәлек булып калырдаен, ул узган ел алды. СССР Верховный Советы Президиумының 1966 елның 23 май Указы белән хөкүмәтебезнең иң зур бүләге — Ленин ордены белән бүләкләнде ул.

Коммунист Сәет Сәлимгәрәев Ленин ордены кавалеры хәзер.

...Азнакай ягы, атаклы як.

Данлыклы як.

Аның бораулаучылары, нефть чыгаручылары һәм җидееллык заданиены биш елда үтәп чыккан атаклы вышка монтажлаучылары турында кемнәрнең генә ишеткәне булмады икән! Шушы коллективлар бит инде соңгы ун ел эчендә Бөтенсоюз социалистик ярышларда соклангыч уңышларга ирешеп, үзләрен данга күмделәр.

Үткәннәргә чигенеш ясап тормыйча, 1966 елның беренче яртысын гына алыйк. Азнакайлылар яңадан үзләренең гүзәл уңышлары турында бер-бер артлы рапорт бирә башладылар...

Бу уңышларга ирешүнең сере бик гади: монда яңалыкны яраталар, алдынгы эш алымнарын, яңа техниканы беренчеләрдән булып производствога кыю кертәләр.

Мисал өчен бораулау конторасын гына алыйк. Производствоны яңача планлаштыру һәм экономик стимуллаштыру кебек бик әһәмиятле хуҗалык реформасы да монда илебездә иң беренчеләрдән булып (1966 елның беренче көннәреннән үк) производствога кертелде.

Производство белән җитәкчелек итүнең яңа системасына күчү, 1966 елның беренче кварталында ук гүзәл нәтиҗәләргә ирешүгә юл ачты.

Берничә мисал.

КПССның Татарстан Өлкә Комитеты бюросы «Татнефть» берләшмәсе бораулау бригадалары социалистик ярышының 1966 ел 1 нче квартал нәтиҗәләрен тикшереп, КПСС Өлкә Комитеты һәм Татарстан Министрлар Советының күчмә Кызыл Байрагын, «Әлмәтбурнефть» трестының беренче конторасында эшләүче Николай Драцкий бригадасыннан алып, «Татбурнефть» трестының Азнакайдагы өченче бораулау конторасында эшләүче мастер А. Хөснетдинов бригадасына бирергә дигән карар кабул итте.

Мастер А. Хөснетдинов бригадасы узган елның беренче квартал планын 111,5 процентка, хезмәт житештерүчәнлеге планын 111,5 процентка үтәде. Бораулауда житештерүчән вакыт 81,0 процент булды. Бер метр җир токымы бораулап үтүнең үзкыйммәте 5,5 процентка киметелде, бораулау тизлеге планга карата 109 процент тәшкил итте.

Икенче квартал исә үзе белән тагын да зуррак куанычлар, шатлыклар китерде. Иң элек «Азнакайнефть» промыселлары идарәсе коллективының икенче квартал нәтиҗәләре буенча Бөтенсоюз социалистик ярышта беренче урынга чыкканлыгы турында хәбәр таралды. Коллективка СССР Министрлар Советының һәм ВЦСПС Үзәк Комитетының күчмә Кызыл Байрагы һәм 28 мең 125 сум күләмендә акчалата беренче премия бирелде.

Ул да булмады: буровой вышкалары монтажлаучыларның яңа уңышы турындагы хәбәр яшен тизлеге белән таралып өлгерде.

Атна да үтмәде — тагын да зуррак шатлык. Азнакайның бораулаучылар коллективы да икенче квартал нәтиҗәләре буенча социалистик ярышта беренче урынга чыкты һәм акчалата бирелә торган беренче премияне алды.

Коллектив җиде ай эчендә генә дә план буенча бирелгән 72 урынына 83 скважина бораулап промыселга тапшырды. Шул ук чор эчендә 69 мең ярым сум дәүләт акчасы янга калды.

Зур уңыш бу.

Бәлки шуңа күрәдер, илебезнең төрле-төрле почмакларыннан, шулай ук чит илләрдән дә, бик күп кунаклар, бик күп делегатлар киләләр монда. Алдынгы эш ысулларын өйрәнергә, тәҗрибә уртаклашырга һәм, ниһаять, үзләрен данга күмгән Азнакай нефтьчеләрен үз күзләре белән күрергә дип киләләр алар. Билгеле инде, бөтенсоюз күләмендә барган социалистик ярышта берничә ел рәттән җиңүче булып чыккан атаклы бораулау конторасында да булалар...

Андый вакытта, кагыйдә буларак, контора җитәкчеләре бернинди икеләнүсез бораулаучы Сәет Сәлимгәрәев исемен атыйлар.

— Үз эшенең виртуозы,— диләр аның турында.

Шунда ук, диспетчер аша, Сәетнең кайдалыгын белешәләр. Вахтада булса, машиналарга төялеп, буровойга чыгып китәләр. Өендә булса, чакыртып алалар.

Күптән түгел генә, Әлмәттә нефтьчеләрнең Бөтенсоюз форумы барган көннәрдә генә, Азнакайга зур бер төркем кунаклар килде. Башкортстан, Төмән, Кубань, Төньяк Кавказ һәм илебезнең башка нефть районнарыннан килгән вәкилләр дә бар иде анда. Форумда вакытта ук берничә тапкыр исеме телгә алынган Сәет Сәлимгәрәевны күрергә теләделәр алар.

Сәетнең өендә чагы туры килде.

Чакырттылар...

«Бораулаучы» дигәч тә без, гадәттә, гаять зур физик көчкә ия булган, тимер ихтыярлы бер пәһлеванны күз алдыбызга китерәбез. Кунаклар да мәһабәт гәүдәле, аю кебек салмак хәрәкәтле бер пәһлеванны күрербез дип әзерләнгәннәр иде булса кирәк, алларында җыйнак гәүдәле, яшүсмер малайныкы кебек чандыр буй-сынлы бораулаучыны күргәч, «шушы да булдымы сезнең күккә чөеп мактаган бораулаучыгыз!» дигәндәй, бер мәлгә сәерсенеп калдылар кебек.

Андый вакытта, ирексездән, Мәскәү янындагы колхозларның берсендә сыер савучы булып эшләүче Л. Сысоева белән булган бер кызыклы вакыйга искә төшә. (Бу турыда ул үзе КПССның XXIII съезды трибунасыннан сөйләгән иде.) Депутат буларак, аңар да, Совет парламентарие составында, Америка Кушма Штатларында булырга туры килә. Шунда песнәк кадәрле генә яшь-яшь кызның, колхоз кадәрле колхозда сыер савучы булып эшләве турында ишеткәч, ышанмыйлар. Чираттагы «пропаганда» дип уйлыйлар. Сысоевага бер фермерның фермасында рәттән берьюлы берничә сыер саварга һәм җыелган халыкны гаҗәпкә калдырып, үзенең чыннан да «гади» бер сыер савучы икәнлеген «исбат итәргә» туры килгән...

Сәетнең дә нинди бораулаучы икәнлеген белү өчен буровойда,

вахтада торганда эшләвен күрергә кирәк. Менә шунда инде аңарда бораулаучы өчен кирәк булган барлык сыйфатларның да барлыгын күрәсең. Аның житез, төгәл, өлгер хәрәкәтләрен күреп сокланып туя алмыйсың. Ирексездән: каян килгән аңар шулкадәрле житезлек тә, шулкадәрле дәрт, егәр, дип уйлап куярга мәжбүр буласың.

Билгеле булганча, нефть скважиналары бораулаганда, инструментны (ике километрга якын сузылган корыч трубалар тезмәсен) күтәреп-төшерү төп эш процессларының берсе булып санала. Скважинаның тирәнлеге мең ярым метрга житәрәк, тау токымнары гаять катылана. Скважинага төшерелгән яңа борау сәгать, сәгать ярым эчендә 7—8 (урыны белән, хәтта 3—4) метр да бораулап үтә алмый, үзенең диаметрын югалта, үтмәсләнә. Аны шунда ук яңадан алыштырырга кирәк. Моның өчен инструментны 25 метрлы «шәмнәр»гә бүлеп яңадан жир өстенә күтәрергә, яңа борау куеп, яңадан бер-берсенә ялгап, скважинага төшерергә кирәк.

Инструментны күтәреп-төшерү, төп эш процессы булу белән беррәттән, гаять дәрәжәдә авыр, катлаулы һәм зур төгәллекне таләп итә. Сәетнең бу эшне башкаруы турында иптәшләре үзара сүз алып барганда: «Ут өере!..» диләр.

Чыннан да, бу эшне башкару буенча беркемнең дә әле Сәеткә житкерә алганы юк. Аның эш алымы бүгенге көндә контораның гына түгел, республикабызның барлык бораулаучылары өчен үрнәк булып тора.

Хәер, бер инструментны күтәреп-төшерүдә генә түгел, башка бик күп төрле эш процессларын башкаруда да Сәет күптәннән бирле инде «беренче номерлы бораулаучы» булып санала.

Жир-ана үзенең хәзинәсен бик тирән, күз-күз тимәслек итеп, мең төрле тау токымнары астына яшергән. Һәрбер тау токымының, «серле йозак» кебек, бары тик үзенә генә хас сыйфатлары, үзенчәлекләре бар. Теге яки бу тау токымын бораулый башлаганчы ук, бары тик «йозакка» яраклы «ачкыч» табарга, ягъни тиешле борау сайлап ала белергә кирәк. Бу эштә чак кына саксызлык күрсәтсәң дә, четерекле хәл килеп чыгуын көт тә тор, скважина сиңа менә дигән «күчтәнәч» әзерли дә куя: я инструмент шартлап сына, я борау уала, шарошкалары-ниләре белән скважина төбендә кала.

Кагыйдә буларак, скважина төбендә кечкенә генә металл кыйпылчыгы барлыгы беленсә дә, эшне дәвам иттерергә рөхсәт ителми.

Ул да булмый, скважина «кирелләнә»: балчык измәсе жир астында үзенә юл табып читкә ага башлый... Агрегатлар чакыртып берьюлы 15—20 тонна югары маркалы цемент эремәсе тутырылып, балчык измәсенең качу юлын томалыйлар...

Шунда ук бораулаучыларны яңа бәла сагалап тора: скважинаның стеналары жебеп ишелә башлый... Яңадан агрегатлар кирәк, яңадан егерме яки утыз тонна цемент тутыр...

Кыскасы, кыенлыкларның исәбе-хисабы юк. Нефть скважиналары бораулауны тикмәгә генә инә белән кое казу белән чагыштырмаслар иде.

Буровойда андый-мондый четерекле хәл килеп чыктымы, Сәеткә мөрәжәгать итәләр. Бу инде мастерның да, бригада членнарының да гадәтенә кергән.

Михаил Петрович Гринь һәр очракта диярлек бер үк сүзләрне кабатлый:

— Вахтада Сәлимгәрәев булганда жаным тыныч. Мин аңар үземә ышанган кебек ышанам, — ди. Шунда ук өстәп тә куя: — нинди генә хәл килеп чыкмасын, югалып та, каушап та кала торганнардан түгел ул. Кыскасы, башлы егет...

Юк, мактау сүзләренә юмарт кеше түгел Михаил Петрович. Әмма Сәеткә һәрвакытта да диярлек ике генә сүз әйтүне кирәк дип таба:

— Молодец, Сәет!

...Июль аеның соңгы көннәре. Искиткеч матур чак. Сәетләр гаиләсе бик иртә торды ул көнне. Ял итәргә дип сөйләшеп атап куйган көннәре иде бу.

Әй-йе, алар бүген чын-лап торып ял итәчәкләр. Алдан ук сөйләшеп куй-ганча, туп-туры Гүзәл Ык буена, табигать куенына китәчәкләр. Җыйнаула-шып ялга чыгып, балык-лар тотып, ухалар пеше-реп, рәхәтләнеп бер ял итсеннәр әле.

Сәет шундый уйлар бе-лән машинасын алырга дип гаражга йөгерде. Юлда иртәнге вахтага ба-рырга дип чыккан бораулаучылар очрадылар.

— Сәлам, Сәет!..

— Сәлам, дуслар!

— Нәрсә, ял итәсең-ме?

— Әйе, ният шулай-рак иде.

— Безнең өчен дә ял ит.

— Була ул...



Социалистик Хезмәт Герое М. П. Гринь һәм С. Сәлимгәрәев.

Автовокзал турына җитәрәк, каяндыр Михаил Петрович Гринь килеп чыкты. Сәетне туктатты.

— Үзең килеп чыгып бик яхшы иттең әле. Югыйсә, өеңә кеше җибәрергә дип тора идек... — диде ул.

Сәет сагая калды.

— Берәр нәрсә булдымы әллә?..

— Әйе, — диде мастер. — Кичә кич конторада, директор кабинетында, производство киңәшмәсе булды...

— Соң?..

— Сиңа бригада кабул итәргә туры киләчәк...

Сәет бер мәлгә төшенә алмыйчарак торды.

— Берәр җиргә китәсеңме әллә? — дип сорап куйды.

Бу сорауны тикмәгә генә бирмәде ул. Михаил Петрович отпускаларга, депутат буларак сессияләргә киткәндә, анда-монда командировкаларга барганда (кайвакытларда хәтта чит илләргә дә командировкага киткәли), кагыйдә буларак, һәрвакытта да үзе урынына мастер итеп Сәетне калдыра торган иде.

Юк, Михаил Петрович беркая да китми икән: Сәетнең үзенә бригада биреп, бөтенләйгә мастер итеп күчерергә булганнар...

Сәетнең башында берьюлы берничә төрле уй чагылып китте: кайсы бригаданы бирергә булдылар икән? Конторада хәзерге көндә 7 бригада.

Сигезенчесен оештырырга гына уйлыйлар, әмма отпускалар чоры булырак, кеше җитмәү сәбәпле, бу эш хәзергә тоткарланып тора.

Шулай да сорап куйды ул:

— Кайсы бригаданы бирергә булдылар?

— Хөснетдиновныкын.

— Ә Хөснетдинов үзе?..

— Ул отпускага китә. Аннан кайту белән, участок начальнигы итеп күчереләчәк...

Михаил Петрович сәгатенә күз төшереп алды.

— Ә хәзер бар. Буровойга...

— Ничек?!. Хәзер үкме?

— Әйе. Яңа буровой кабул итәргә кирәк...

Сәеткә өенә кайтып өс-башын алыштырырга да туры килмәде. Тиз генә вахта машинасына утырды да туп-туры буровойга китеп барды.

Сәет үзе кабул итеп аласы бригада членнарын яхшы белә. Хәер, тату бер гаилә кебек яши торган бу конторада бер-берсен белмәгән кеше юктыр да.

Бораулаучылар белән тулган автобус ялтырап яткан асфальт буйлап алга ыргый...

Иң арттагы урыннарның берсендә утырган Сәет вахтага баручылар арасыннан үзенең кешеләрен, үзенең яңа иптәшләрен барлый... Әнә бораулаучы Шакуров утыра. Димәк, хәзер аның вахтасы... Ул мастерның алышынуы турында ишеткән булса кирәк. Бая, Сәет автобуска сикереп менеп утыру белән, елмаеп, бөтенләйгә үз итеп исәнләште. Әнә ярдәмчесе... Шунда ук — вахтаның электригы Мөхәммәдияр Хәбибуллин. Кулында, гадәттәгечә, китап аның. Укып бара... Күпне күргән, шактый кызык, үзенчәлекле кеше бу. Аның бер лә белмәгәне юк. «Аяклы энциклопедия», диләр Мөхәммәдияр турында. Аның: «Тәүлегенә 3—4 сәгать китап укымасам, көнемне әрәм уздым дип саныйм мин», — дигән сүзләрен Сәеткә үз колагы белән ишетергә туры килгәне бар.

Сәет бригаданың башка кешеләре турында да уйлап алды.

Бригада кадәр бригада кабул итеп алу уен эш түгел инде ул. Әмма, бригада да үзенең якын дусты, Әхәт Җиһаншинның булуы аның өчен бик унай иде.

Хәер, Әхәт аның якын дусты гына түгел, авылдашы, хәтта классташы да. Бер партада утырган чаклары да күп булды аларның. Биографияләре дә бер үк төсле. Икесе дә Азнакай районычын Чувар-Абдул авылыннан. Бергә үстеләр, икесен дә бер үк көнне армиягә озаттылар. 1951 елда армиядән дә бер үк вакытта кайтып төштеләр. Ул чакта инде: «Бу якларда да нефть бар икән. Җитмәсә тагын чиксез күп икән», дигән сүзләр телгә кергән иде. Ике дус Азнакайга эшкә керергә дип килделәр. Аларны Бөгелмәгә, бораулаучы ярдәмчеләре әзерли торган кыска сроклы курсларга җибәрделәр. Кайттылар. Эшли башладылар. Исемнәре макталып телдән төшмәде аларның. Бер үк вакытта өйләнделәр... Эштә дә, тормышта да, ничектер үзара ярышып, берсе-берсен уздырырга теләгәндәй яшәделәр алар. Берсе автомашина сатып алды. Ничек итеп инде икенчесе калсын ди! Икенчесе дә алды...

Икесе дә орден кавалерлары: Әхәт Җиһаншин Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры.

Һәм менә Сәетнең тормышында тагын бер үзгәреш...

Әле кичә генә гади бораулаучы булган Сәет Сәлимгәрәев, бүген инде вахтага мастер булып бара.

...Табын яңы гөрләп тора.

Әмма, Шәмсекамал Сәетнең алдындагы рюмкага кагылмавыннан ук сизә: димәк, ире янадан төнгә карап буровойга дип чыгып китәчәк...

Шулкадәр көянәк, шулкадәрле тынгысыз җан булса да булыр икән. Гади бораулаучы чагында да андый-мондый четерекле хәл килеп чыганитә калса (буровойда андый хәл атлаган саен) тәүлекләр буенча шуннан кайтмас иде. Хәзер, мастер булып алгач, аякка күтәрелгәч, ни булачы билгеле инде!

Һич югында бүген өйдә булсын иде инде. Кичке бишләрдә генә кайтты лабаса! Иртәгә ял. Шуның өстенә өйдә кунак та бар. Бик кадерле кунак. Шәмсекамалның иң төпчек, иң сөекле энесе Канәгать килде. Тукай исемендәге колхозның алдынгы механизаторы ул.

Бөтен туган-тумачалар өзелеп яраталар аны. Хәер, гаҗәп тә түгел. Ир-ат затыннан берләнбер шул ул... Ә бит заманында сигез бала булып үстеләр алар. Биш ир бала, өч кыз.

Ватан сугышына киткән дүрт абыйсының дүртесе дә кайтмады... Дүрт офицерның да батырларча һәлак булулары турында кара печатьле кәгазьләр генә килде...

Ул вакытта Шәмсекамал яшүсмер кыз бала гына иде. Ә хәзер, әнә, аның үзенең ике кызы бар. Өлкәненә 14 яшь. Кечесенә, әнә, пианинода уйнаганына — Гүзәлгә — 11 яшь. Бүлмә эче Салих Сәйдәшев, Яруллин моңнары белән тула...

Табын янында утыручылар нәни музыкантның уйнавын хәйран булып тыңлыйлар. Гүзәл хәзер Азнакай музыка мәктәбенең дүртенче классында укый. Бетховен, Чайковский, Шостакович әсәрләрен тыңларга теләсең икән, рәхим ит!

Шәмсекамалның күңеле бу юлы да алдамады. Төнге уңынчы яртылар җитәрәк, Сәет, кунакларыннан гафу үтенеп, табын янынна:і күтәрелә башлады.

— Сез, туганнар, утыра торыгыз, — диде ул. — Мин бик тиз... Әйләнеп кенә кайтам.

Картының брезент тужуркаларын кия башлавыннан белде Шәмсекамал: Сәет кайтмаячак. Җитмәсә тагын бая гына әле төнге вахтада бер кеше җитмәве турында сөйләнеп утырган иде.

Хәер, Шәмсекамал да хәлне аңламый түгел. Сәет кабул итеп алган 7016 номерлы буровойда соңгы метрлар бораулана... Иң җаваплы, иң четерекле вакыт. Өстәвенә, ул участоктагы нефть катламы башка урыннарга караганда 130—150 метрга тирәнрәк ята. Шуның өстенә, басым да көчле ул тирәдә. Нефть фонтанының өскә бәреп чыгуы бар... Җитди авария булып санала ул. Андый аварияне булдырмас өчен алдан ук хәстәрен күрә башларга кирәк. Моның өчен кичекмәстән скважинаны югары сыйфатлы балчык измәсе белән тутырып куярга кирәк...

Автовокзалга барып җиту белән ишетте Сәет: төнге вахтаның тагын бер эшчесе авырып больницага кергән.

Вахта машинасы, Азнакайның якты урамнарын артта калдырып, кырлар киңлегенә чыкты. Ярты сәгать чамасы да үтмәгәндер, көчле фара яктысы белән төнге караңгылыкны бораулап килүче вахта машинасы 7016 номерлы буровойга якынлашты. Машина йөрешен әкренәйтә төште һәм, соңгы тапкыр борылыш ясап, гөрләп торган буровойны, насос корылмаларын, культбудка стеналарын бизәгән лозунг, плакатларны яктыртып алды да туктады.

Чираттагы вахтага килгән бораулаучылар, автобустан сикерешеп төшү белән, тирә-якны лер селкетеп торган буровойга күз салдылар.

— Күтәрә дә башлаганнар... — диде кайсыдыр.

Бар да буровойга таба юнәлделәр.

— Эшләр ничек бара?

— Бар да тәртиптә...

Кичке вахтада торган Шәкуров, алмашка килгән Пензяковка рапорт биргәндәй, эшнең ничегрәк барганлыгы турында әйтте. Анннары бары тик үзләренә генә аңлаешлы сүзләрне тезеп китте:

— 71 шәм. Бер одиночка. Квадрат полный...

Сүзнең ахырында тормоз колодкаларын алыштыруын хәбәр итте.

— Менә анысы яраган! — диде Пензяков.

Шул вакыт Сәетнең әмере яңгырады.

— Башладык, иптәшләр!

Тирә-як кинәт сискәнеп киткәндәй булды. Буровой эче янадан дәртле, көчле гөрелте белән тулды...

...Саф та соң күзгә һава! Әллә кайлардан таулар, зәңгәрсу урманнар — барысы да аермачык булып күренеп тора. Тирә-якта — республикабызның нефть районнарына гына хас күренеш.

Әнә, алда югары вольтлы электр линияләренең челтәрле мачталары... Шунда ук, башларын ак болытларга терәп, буровойларның корыч вышкалары тезелеп киткәннәр. Күп алар. Вышкалар белән бөтен кырлар, тау битләре, урман буйлары, хәтта урман эчләре тулган. Буровойлар арасында уннарча һәм уннарча километрларга сузылган ялтырап яткан асфальт юллар. Юллардан өзлексез рәвештә мең төрле машиналар агылып тора. Шунда ук үлчәгеч резервуарлар, трап, арматура һәм культбудкалар. Чак кына читтәрәк, үзәнлектә, һәркайсына йөзәр мең тонна нефть сыешлы көмеш резервуар батареялары тезелеп киткәннәр...

Сокландыргыч матур бу яклар! Диңгез кебек булып җәелеп яткан иген кырларында — комбайннар... Бодай уралар алар. Артларыннан тузан өермәсе генә тузып кала...

Ә мондарак, шактый биек калкулык өстендә, 7016 номерлы буровой. Сәет буровое. Штурвал артында бораулаучы Әхәт Җиһаншин.

Инструмент төшерәләр...

— Тирә-як җир тетрәгәнгә охшап лер селкенә...

Буровой эчендә түзә алмаслык эссе. Элеваторлар, «шәм»нәр ут урынына кызганнар. Кул белән кагылырлык түгел.

Вахта членнары шабыр тиргә батканнар. Буш элеватор чираттагы «шәм»гә менеп киткән арада, берәрсе йөгереп килеп, салкын су сиптереп торган шланг астына йөзен куя.

Ниһаять, инструмент төшерелеп бетте. Насосларны җибәрделәр... Һәм әле генә төшерелгән яңа бораy йөзләрчә мең яшьлек тау токымнарын кимереп, девон нефтенә якынлаша башлады...

Скважинаның тирәнлеге 1800 метрдан арткан иде инде. Бораy проектта күрсәтелгән тирәнлеккә якынлашып килә...

Беренче вахта бетәр алдыннан, Сәетнең көр тавышы яңгырады:

— Стоп! Булгандыр, туганнар...

Сәетнең заявкасы белән чакыртылган каратаж партиясе килеп житте. Нечкә приборлар ярдәмендә скважинаның сыйфаты тикшерелде. Отлично!..

Нефть ике горизонт булып ята икән. Димәк, скважина нефтьне мул бирәчәк, озын гомерле булачак...

———□———

Зәет Мәҗитов

# Хәерләре белән үссеннәр

Курыкмыйча әйтергә мөмкин: соңгы ике-өч елда поэзиягә килүче яшьләр сизелерлек артты. Ф. Яруллин, Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин, К. Мостафин, Р. Мингалимов, К. Булатова, Г. Рәхим, Рәшит Әхмәтҗанов, М. Садыйков, Р. Закиров, З. Маликов, С. Гәрәева һәм башка яшь шагыйрьләрнең шигырьләре матбугатта шактый еш күренәләр.

Шунысы куанычлы, аларның беренче китапларын шигырь сөючеләр игътибар белән күзәтеп бара икән. «Казан утлары» журналы редакциясенә килгән хатлардан бу бик ачык күренә. Димәк, яшь шагыйрьләр авазы укучыларга ишетелерлек булып яңгырый.

«Мин З. Маликовның, М. Садыйковның шигырьләрен яратып укыдым. Яшьләрнең фикере укучыларның күңеленә якын һәм аңлаешлы. Садыйковның табигать күренешләренә гашыйклыгы һәм оста итеп тасвирлавы аерата ошады», дип яза Пермь өлкәсеннән Сөембикә Ихсанова.

«Яшьләрнең фикере укучыларның күңеленә якын һәм аңлаешлы» дип, хат авторы бик дөрес әйтә. Яшь шагыйрьләрнең күпчелек әсәрләре матур хисләр, тирән фикерләр белән сугарылган. Хезмәтне олылау, гади кешеләргә хөрмәт, саф мәхәббәткә омтылу — яшьләр поэзиясенең үзәк идеясе әнә шул. Нәкъ менә шушы як яшь поэзиябезнең дөрес юнәлештә, гуманистик традицияләр җирлегендә үсә баруын раслый. Әйтелгәннәрне дәлилләү өчен мисалны теләсә кайсы яшь шагыйрь иҗатыннан күпләп табарга була. Менә Р. Рәхимовның яңа гына басылып чыккан «Сабан тургае» (1966) дигән җыентыгы. Шагыйрьнең үз темасы бар. Ул бүгенге авылны, аның табигатен яратып сурәтли, бүгенге авыл кешеләренең рухи дөньясын, фәлсәфәсен, характерын ачып сала. Аның шигырьләрен укыганда, бүгенге авылның үзен күргәндәй буласың. Бер генә строфалы түбәндәге шигырьгә күз салыйк:

**Июль төне. Ачык, зәңгәр күктән**
**Сызылып-сызылып йолдыз коела.**
**Арыш арасына ялгыш төшеп**
**Ут чыгарыр кебек тоела.**

(*Июль төне*)

Июль төненең гаҗәп матур сыйфатларын тотып алган шагыйрь.

К. Мостафин үзенең «Кеше яши» шигырендә түбәндәгечә яза:

**Бу без — һәлак булдык. Ә җил сөйли:**
**Кеше яши җирдә, аннан — җырда...**
**Һәм һәр кичне без керәбез уйга,**
**Һәм һәр таңда без чыгабыз юлга.**

Поэзиянең тормыштагы ролен аңлауда да яшь шагыйрьләр өлкәннәр традициясен дәвам иттерәләр. Ф. Кәримгә багышлап язылган «Шагыйрь үлми» шигырендә М. Садыйков шагыйрь гомере турында уйлана һәм болай дип белдерә:

**Шагыйрь үлде диеп кем дә әйтми,**
**Шагыйрь үлми, исән!**
**Үлемсезлек чишмәсенә ятып**
**Яшәү суын эчкән.**

К. Мостафин исә Муса Җәлил турында:

**Муса исән, без тоябыз аның**
**Бөек рухы бездә яшәвен,—**

дип яза.

Шигъри иҗатның җиңел түгеллеген яшьләр аңлыйлар, хәзерге укучының поэзиягә куйган югары таләбен беләләр һәм үз иҗатлары белән ул таләпләргә җавап бирергә омтылалар. Эзләнү, поэзиядә үзенә яңа сукмак салырга тырышу, яңа сүз әйтү теләге — яшь шагыйрьләрнең табигый сыйфаты.

Поэзиягә нинди тавышлар белән килеп керделәр соң алар?

Игътибар белән карасаң, һәр яшь шагыйрьнең үз моңын, үз тавышын сизәргә була. Ф. Яруллин язмыш авырлыкларына баш имәгән, авыр сынаулар алдында да бай хисле, көр күңелле булып яши алган яшь кеше образын сурәтләүче «Мин тормышка гашыйк» исемле беренче җыентыгын бирде. Рәшит Әхмәтҗанов, халык иҗатыннан килә торган музыкаль стильгә яңа бизәкләр өстәп, нәфис-нечкә хисләрне җырларга омтыла. Р. Гатауллин һәм Р. Фәйзуллин поэзиягә яңа тема, сурәт-ритмика ягыннан үзенчәлекле яңа үсентеләр алып киләләр... Ләкин алар арасыннан укучыны сискәндереп, кайвакыт га-

җәпләндереп «туучыларын» да табарга мөмкин. Укучылардан редакцияләргә килгән хатлар да шул хакта сөйли. Газета-журнал битләрендә тәнкыйть сүзе дә ишетелә башлады. Беренче булып Н. Фәттах «Шигырьме, әллә башваткычмы» дигән мәкалә («Татарстан яшьләре» газетасы, 1965 ел, 17 июнь) язып чыкты. Р. Фәйзуллин һәм Р. Мингалимов шигырьләре турында сүз башлап, автор аларның «чамадан тыш оста һәм катлаулы булып күренергә тырышулары» турында яза, аларны форма белән мавыгуда гаепли. Р. Кутуй исә, киресенчә, «Литературная газета»да басылган «Что называть поэзией» дигән мәкаләсендә Р. Фәйзуллин поэзиягә яңалык алып килә, дип белдерә. Ә. Давыдов та Н. Фәттахка каршы чыга. «Казан утлары» журналына җибәргән хатында, Р. Фәйзуллин һәм Р. Мингалимов шигырьләренә тукталып, Сөембикә Ихсанова иптәш «мондый шигырьләрне басуның кирәге бармы икән» дигән фикерне әйтә. Р. Фәйзуллинның иреклe шигырьгә мөрәҗәгать итүе уңае белән байтак башка мәкаләләр дә чыкты, хатлар да алынды. Без аларның барысына да тукталуны бурыч итеп куймыйбыз. Шулай ук барлык яшь шагыйрьләр иҗатына карата да күзәтү бирергә җыенмыйбыз. Бу мәкалә Сөембикә Ихсанова һәм театр училищесы студенты Хәлил Мәхмүтов хатларына җавап рәвешендә язылып, ул хатларда күтәрелгән һәм нигездә, күпчелек укучылар тарафыннан әйтелгән сорауларга җавап бирү максатын күздә тота.

Р. Мингалимовның «Казан утлары» журналының 1965 елгы 10 санында басылган шигырьләре турында С. Ихсанова түбәндәгечә яза:

«Яшь язучы яңа алымнар белән, яңача язарга омтыла кебек. Ләкин язучының нәрсә әйтергә теләвен аңлау өчен, шигырьне кат-кат укырга кирәк. Әйе, чынлап та, бик катлаулы. Фикерләр буталчык, идея эчтәлеге ярлы, чакыру яки өндәү бөтенләй юк». Аннары хат авторы болай дәвам итә: «Шигырь, минемчә, бер мәртәбә укуда ачык аңлашылырга тиеш. Ә Мингалимовның шигырьләрен, борынгы Мисыр папирусларының серен ачкан кебек, тырышып укырга кирәк. Мондый шигырьләрне басуның кирәге бармы икән? Әллә мин үз карашларым белән ялгышаммы, әллә яңача язу шушы стильдә булырмы?»

Мисалга китерелгән шигырьләргә күз салганга кадәр, хат авторының кайбер фикерләренә тукталмый мөмкин түгел. Сүз дә юк, һәр әдәби әсәрнең идея эчтәлеге бай булырга тиеш. Бу мәсьәләдә яшьләргә дә ташлама ясарга ярамый. Шигырь шулай ук аңлаешлы да булырга тиеш. Ләкин шигырьнең аңлаешлы булуы әсәрдә фикерләрне турыдан-туры әйтү дигән сүз түгел. Әдәби әсәрдә фикер турыдан-туры әйтеп бирелми, бәлки образлар аркылы, персонажларның үз-үзләрен тотышлары, аларның хәрәкәтләре ярдәмендә белдерелә. Лирик әсәр исә лирик образның («мин» исеменнән сөйләүченең) кичерешеннән гыйбарәт. Бу «мин» нәкъ менә шагыйрьнең үзе дигән сүз түгел. Ул теге яки бу буыннан, теге яки бу катлауның вәкиле, яшь кеше, өлкән кеше, егет яки кыз да булып сөйләргә мөмкин. Иң мөһиме — лирик әсәрнең герой кичерешен сурәтләндерүе. Шуңа күрә шагыйрь, беренче чиратта, герой кичерешен укучыга җиткерергә, геройның уе һәм хисе ярдәмендә үз позициясен укучыга белдерергә омтыла. Димәк, иптәш Ихсанованың «Р. Мингалимов шигырьләрендә чакыру яки өндәү юк» дигән карашы дөрес үк түгел. Әгәр шагыйрь: «Укучы, син үзеңне фәләнчә тот, син тегене эшлә, моны эшләмә», дип турыдан-туры укучыны вәгазьләргә керешсә — бу инде мәкалә яки лозунгка әйләнә.

Дөрес, кайбер шигырьләрдә чакыру-өндәү характерында әйтелгән җөмләләр дә булырга мөмкин. Ләкин эш шунда, ул чакырулар шагыйрьнең турыдан-туры агитациясе, вәгазе булмыйча, лирик геройның шул формадагы кичерешe, лирик герой сүзләре булалар. М. Җәлилнең «Дуска», Ф. Кәримнең «Сөйләр сүзләр бик күп алар» шигырьләре, мәсәлән, әнә шундый. Әгәр барлык шигырьләр дә чакыру-өндәүләрдән торса, аны укучы бөтенләй яратмас, ул укучының күңелен дулкынландыра алмас иде. Г. Тукайның «Пар ат», «Көзге җилләр» кебек шигырьләрендә я пар атта Казанга баручы «мин»нең, я көзге төндә ил язмышы турында уйланучы лирик геройның хисләре бирелгән. Без монда укучыны вәгазьләү, өндәү белән һич очрашмыйбыз. Аларда кичереш, хис үзәктә тора. Шуңа күрә дә аларны лирик әсәрләр дип атыйлар.

Ә соң фикер ничек әйтелә? Идея ничек белдерелә? Лирик геройның нинди хәлдә, ни рәвешле кичерүе, уйлануы, ни өчен шатлануы һәм ни өчен борчылуы безгә дә йогынты ясый. Без матурлыкка сокланып карарга, начарлыкка борчылырга өйрәнәбез.

«Яңача язарга омтылу» мәсьәләсенә дә берничә сүз әйтик. Һәр әдәби әсәрнең кыйммәте, яңа хисләр, яңа фикерләр әйтү белән бергә, үзенчә, яңача сурәтләүгә дә бәйләнгән. Әмма яңача язу, барыннан да элек яңа фикерләрне, бүтәннәр әйтмәганне тотып алу һәм үзең тапкан сурәтләү чаралары ярдәмендә укучыга җиткерү дигән сүз. Димәк, беренче планда эчтәлек, язучының әйтергә теләгән төп фикере тора. Ә форма исә шул эчтәлеккә яраша. Форманы беренче планга чыгару исә, котылгысыз рәвештә, формализмга этәрә. Монда инде «яңача стильдә язу»да ярдәм итми.

Инде Р. Мингалимовның иптәш Ихсанова тәнкыйтьләгән шигырьләренә — «Иделдә» һәм «Кирәк идең» әсәрләренә тукталыйк. «Иделдә» шигырендә Р. Мингалимов гашыйк егетнең Иделдә су коенучы сөйгән кызына карап соклануын тасвирларга омтыла:

**Диңгез һавасы кебек саф**
**сүзләр пышылдаган иренең —**
**Миңа гомерем бәясе.**

**Кына тигән ун тырнагың —**
**Ун кояшым минем, —**

ди егет сөйгәненә карап. Егет кызны, кыз егетне сөя. Һәм егет, шатланып, «мин соң җирдәге һәр кызга, һәр егеткә шундый бәхет бүләк итмәс идемме?» дип белдерә. Бәхетле, саф мәхәббәткә ышану, үзенә генә түгел, «җирдәге һәр егет һәм кызга» шуны теләү шигырьнең төп мәгънәсе.

Ә иптәш Ихсанованың моның белән килешәсе килми. Ул егет турында «ә бит ул бар кызны да бәхетле итә алырмы?» дип сорый һәм «һәр кызга, һәр егеткә нинди бәхет бирергә тели — аңлашылмый», дип нәтиҗә чыгара. Мондый нәтиҗә чыгару өчен шигырьдә берәр сәбәп бармы?

Иптәш Ихсанова:

**Кына тигән ун тырнагың —**
**Ун кояшым минем, —**

дигән юллардан иң элек **«тигән»** сүзен **«яккан»** сүзе белән алыштырырга тәкъдим итә. «Яккан» сүз укучыга якынрак булыр иде. Бу юлларны бөтенләй укыйсы килми», ди ул. **«Тигән»** сүзе уңышлыракмы яки **«яккан»** әйбәтрәкме? Бу — бер мәсьәлә, укыйсы килмәү — икенче мәсьәлә.

Игътибар итик: «яккан» сүзе тырнаклар буялган булуны туп-туры белдерә. Ә егет исә тыйнак кеше, аның күңеле саф мәхәббәт белән тулы. «Яккан» сүзе аңа тупас тоела. Аңа нәфис, нечкә, тыйнак сурәт кирәк. Димәк, «яккан» сүзе монда һич ятышмый. «Тигән» авазлар ягыннан да нәфис, кызның да чамасын белеп кенә, килешле итеп кенә бизәнүен төгәл белдерә. Шулай түгелме, иптәш Ихсанова?

Инде укыйсы килү-килмәүне әйтсәк, монда сәбәп башка булмагае. Кешенең бер табигате бар: ул күнегелгәнне тизрәк кабул итә, күнелмәгән, яңа сурәт аны сискәндереп җибәрергә, хәтта аңа ят, ямьсез тоелырга мөмкин. Таныш һәм таныш түгел кешеләр белән очрашканда да шундыйрак хәл була бит.

Аннары хатта югарыда әйткән ике юлга карата болай языла:

«Кояшны ничек мыскыл итә, дип куясың. Кояш бөтен дөньяга бер генә, язучы өчен ул ун кояшка әйләнде. Һәр тырнагы бер кечкенә кояшка торырлык кызны әсәрдә күрмибез. Ун кояш безгә кирәкми, кызының тырнакларын егерме итеп табынса да эшебез юк».

Әйе, кояш бер генә. Бу дөрес. Әмма шагыйрь шуны да аңламый икән, дип карый алабызмы соң без? Алайса, шагыйрь нигә кызның ун тырнагын ун кояшка тиңләде?

Монда ике дөреслек — факт дөреслеге һәм шигъри дөреслек мәсьәләсе калкып чыга. Фикерне раслау өчен бер-ике мисалга мөрәҗәгать итик.

**Дустым, сиңа миннән сәлам**
**Урал таулары хәтле, —**

диелә халык җырында. Урал тавы хәтле сәлам. Димәк, бик күп сәлам. Әйтеп бетергесез күп. Һәм бу дөрес, чөнки ул җыр героеның кичерешен тулы итеп әйтеп бирә.

**«Минуты ай, сәгате ел»** — икенче бер халык җырында шундый тиңләү белән очрашабыз. Минут ай була алмый төсле, ләкин сагыну көчен ул төгәл житкерә. Муса Җәлилнең «Күлмәк» шигырендә кызның сөйгәне сугышта һәлак була. Ләкин кыз ышанмый. Күлмәкне үлгән егеткә илтеп кигезергә куша, һәм гаҗәеп хәл — егет терелә. Фактик дөреслек ягыннан караганда — моның булуы мөмкин түгел. Әмма ул шигъри яктан бик дөрес, чөнки кызның сөю көче шулкадәр зур булуын, аның егеткә көч биреп торуын шигъри яктан дөрес гәүдәләндерә. Бу рәвешле сурәтләү — сәнгатьнең мөһим үзенчәлеге. Без аны шигъри дөреслек дип атыйбыз. Р. Мингалимов шигырендә дә шул ук хәл. Кыз егеткә шулкадәр сөекле, кызның һәр ягы шулкадәр килгән — егет аның тырнакларын да кояш итеп күрә. Юк, кызның һәр тырнагы бер кояш, дими шагыйрь, кояш булып тоела, дип кенә әйтергә тели. Ун кояш дип раслау шушы охшатуны көчле итеп әйтү, укучы игътибарын тартырлык итеп әйтү өчен генә кирәк.

Иптәш Ихсанова шигырьнең тагын бер строфасын тәнкыйть итә.

**Көнләшмим,**
**Җимерелмәс дуслык,**
**Таш калалар тудыра белгән**
**Йомшак кулларың белән**
**Кочакла, кечкенәм, зур Иделне, —**

дигән строфада ул түбәндәге өч кимчелекне күрә:

«Беренчедән, таш калаларны тудырмыйлар, төзиләр генә. Язучы хатын-кыз булса, тудыру белән төзүне бутамас иде».

«Икенчедән, куллар бик йомшак та булмаслар һәм кыналары да тормас, диясе килә. Андый куллар чыныкканрак булалар алар».

Өченче кимчелек итеп хат авторы сөелү яки сөю көнләшми генә була алмавын китерә.

**«Тудыру»** сүзен дөрес куллану-кулланмау мәсьәләсеннән башлыйк. Дөрес, таш калаларны тудыру мөмкин түгел. Ләкин эш шунда: **«тудыру»** сүзе монда таш калаларга гына карамый, «җимерелмәс дуслыкка» да карый. «Җимерелмәс дуслык»ны исә төзеп булмый. Шунлыктан шагыйрь «тудыру» сүзен куллана. Бу сүз монда һич тә «хатын-кызның бала тудыруы» мәгънәсендә кулланылмый.

«Таш калалар төзи торган куллар йомшак булмый», ди хат авторы. Мондый раслау белән дә килешүе кыен. Соң төзелештә эшләүче һәр хатын-кызның кулы тимер кебек булып сөялләнеп катарга тиешме? Төзелештә хәзер техника юкмы? Аннары шагыйрьнең «җимерелмәс дуслык, таш кала, йомшак кул» төшенчәләрен янәшә куллануын, шул юл белән кызның нәфислегенә игътибар иттерергә тырышуын да онытырга ярамый. Шагыйрь «эштә сөялләнеп беткән каты куллы кыз» дип сурәтләсә, кыз образының нәфислеге югалмас идеме соң?

Соңгы юлның да әһәмияте бик зур. «Йомшак кулларың белән кочакла», дип,

шагыйрь безгә кызның яратуын, ягымлылыгын тагын да тулырак житкерә. «Кечкенәм һәм зур Идел» антитезасын (каршы кую) файдалану да урынлы. Кыз, әлбәттә, Иделне кочаклап ала алмый, ләкин сурәт кызның мөлаем сынын тулыландыра.

Ниһаять, егетнең «көнләшмәвенә» килик. Ни өчен «көнләшмим» ди соң ул? Әлбәттә, мәхәббәт көнләшүсез була алмый. Ләкин аңа көнләштерерлек сәбәп кирәк. Егетнең «көнләшмим» дигәне исә кызның саф күңелле, турылыклы булуын белдерү өчен килә. Алай гына да түгел, сәбәп була калса, ул егетнең әлбәттә көнләшәчәген үк белдереп тора, югыйсә егет көнләшү хакында сүз дә йөртмәс иде.

Соң шигырьдә бер дә кимчелек юкмы әллә? Шигырьдә кимчелекләр бар һәм нәкъ менә шулар укучыны сәерсендерәләр дә инде. Беренче кимчелек — әсәрдә ясалмалык булу. Шагыйрь, һич кирәкмәгәндә, егеттән «көнләштерергәме әллә исәбең?» дигән сорау куйдырта һәм бөтен шигырьне шул сорауга җавап формасында төзи. Укучының игътибары көнләшү — көнләштерү мәсьәләсенә күчеп китә. Ә бит шагыйрьнең сүзе бөтенләй ул хакта түгел иде. Икенче кимчелек — форманың катлауландырылуы, ритмның урынсызга «кытыршыландырылып» язылуы. Димәк, иптәш Ихсанованың зарлануы бөтенләй нигезсез үк түгел икән.

Күп кенә укучылар белән бергә, Сөембикә Ихсанова һәм Хәлил Мәхмүтов иптәшләрне Равил Фәйзуллин шигырьләре, бигрәк тә аның «Нюанслар иле» циклы гаҗәпләндерә.

Равил Фәйзуллин шигырьләре турында матбугатта күп кенә фикерләр, хәтта бәхәсләр дә булуын инде әйткән идек. Сүз күбрәк аның шигырьләрендәге форма турында, аерым алганда, иркен шигырь ритмикасын урынлымы-урынсызмы куллану хакындарак барды. Ләкин Р. Фәйзуллин шигырьләре турында сөйләшүне форма ягына гына кайтарып калдыру, аны ритмикада яңалыкка омтылып, эчтәлекне оныта, дип бәяләү берьяклырак булыр. Р. Фәйзуллинның күптән түгел басылып чыккан «Аҗаган» дигән беренче җыентыгы җитди сөйләшүне таләп итә, минемчә.

Нләр турында сөйли, кемнәрне сурәтли соң яшь шагыйрь. Җыентыкның беренче битендә түбәндәге шигырь урнашкан:

**Чын дуслар очратып, танышсам,**
**кемгәдер дөрес юл табышсам,**
**кемгәдер шат очкын кабызсам,—**
**яктырып,**
**нурланып,**
**очынып,**
**шигырьләр язаргаябышам.**

**Юлымнан барганда ялгышсам,**
**тайганда дошманга ябышсам,**
**сагыштан чирләргә сабышсам,**
**хисемне яшемә чылатып,**
**шигырьләр язарга ябышам.**

**Ул иң бәхетле, дип уйла син,**
**я иң бәхетсез, дип уйла син,**
**әгәр дә төннәрен уянып,**
**шигырьләр язарга ябышсам.**

Бу — яшь шагыйрьнең иҗат программасы. Һәм, чыннан да, яшь шагыйрь дөньяны киң караш белән күзәтергә, һәр яхшылык өчен шатланырга, һәр начарлык өчен борчылырга омтыла. Аналар йөрәге дә, балалар көлүе дә, аҗаганлы тыныч төннәр яме дә, сугыш хатирәләрен оныта алмаган сагышлы күңелләр дә һәм башка күп уйлар, фикерләр, шикләнү һәм ышанулар да бар аның шигырьләрендә. Р. Фәйзуллинның күп шигырьләрендә юкка гына җирдәге бар нәрсәне күреп торучы **кояш** образы сурәтләнми.

Р. Фәйзуллинның тагын бер үзенчә тотып алган, үзенчә сурәтләнгән ягы бар: ул гади кешеләрнең рухи байлыгын, алар хезмәтенең мактаулылыгын, алар йөрәгенең тирән кичерүен шигырьгә күчерергә омтыла, иң гади тормыш күренешләрендә шигърият күрә. «Гадиләргә гимн» шигыре — шуның мисалы. «Күмәч пешерүчеләр җыры» шуңа дәлил. «Җилфердәүче керләр җыры» — шуны раслый.

«Күмәч пешерүчеләр җыры» шигырендә Р. Фәйзуллинның иң уңай яклары тулы чагыла дияргә мөмкин.

**Сез кем, дип сорыйсызмы?**
**Күмәч пешерүчеләр без!**
**Кешеләрнең йөзләренә**
**шатлык төшерүчеләр без!!**
**Күмәч пешерүчеләр без! —**

дигән төзек һәм аз гына юмор салынган йөгерек ритм белән башлана шигырь. Күмәч пешерүчеләрнең үз сүзләре аша шагыйрь мул, тыныч тормышка, кешеләргә яхшылык китерүче иң гади хезмәткә, хезмәт кешеләренә дан җырлый. Шунысын да әйтик, Р. Фәйзуллин көнкүрешнең иң гади детальләрен дә шигъри максатка оста хезмәт иттерә бирелә:

**Күмәч кебек йомшак түгел,**
**үзебез каты куллыбыз:**
**изә, баса, туглыйбыз;**
**йоп-йомшак камырны**
**кайнар мичкә юллыйбыз.**
**Күмәчләрнең йөзе килсә,**
**бөркелеп хуш исе килсә,**
**нечкәрә күңелебез:**
**сөенәбез, көләбез —**
**бик сабый күңелле без.**

Әгәр яшь шагыйрьнең барлык шигырьләрендә дә Р. Бернсларны хәтерләтә торган шушы матур, тирән эчтәлекле, шигърияте гадилек саклаган янсә шуңа ирешелгән булса, бүген Р. Фәйзуллин шигырьләре турында бәхәсләшеп торучылар да булмас иде. Хикмәт шунда, Р. Фәйзуллинның тавышы әле урнашып, утырып җитмәгән. Ул еш кына, үз аһәнен табып җиткермәгән җырчы төсле, яшелле-зәңгәрле тавышлар да чыгара, ул эзләнә әле.

Яшь шагыйрьләрнең эзләнүе — тәнкыйть ителергә тиешле нәрсә түгел. Яшьләр эзләргә һәм эзләгәннәрен тапканга кадәр эзләргә тиешләр. Әмма үз тавышыңны эзлим дип артык кискен, артык кычкырып җырлау, бер

җырны башлау белән ташлап, икенчесенә керешү кебек хәлләр дә булгалый.

«Равил Фәйзуллинның «Нюанслар илен» (әлегә яңа алымдыр инде үзенчә), — дип яза С. Ихсанова, — берничә мәртәбә укып та гыйбрәт алырлык та, үрнәк алырлык та, искитәрлек тә, көләрлек тә, уйланып нәтиҗә ясарлык та түгел. Истә бернәрсә калмый, башта җилләр исеп тора. Тапкыр сүзләр, метафоралар, афоризмнар болай язылырга тиеш түгелләр» һәм ул, нәтиҗә итеп, бу әсәрләр «көнбатыштагы абстракционизм юлына баскан художникларның әсәрләрен хәтерләтәләр», дип белдерә.

Хәлил Мәхмүтов иптәш тагын да кызып китә. «Бәлкем, бу — шагыйрьләр өчен яңа алым, стильләр. Ләкин бу стиль халык өчен түгел, әлеге психозлар өчен», дигән сүзләр яза.

Иң элек шуны әйтик. «Нюанслар иле» циклы — Р. Фәйзуллинның үз тавышын эзләү юлында ясалган бер тәҗрибә. Югарыда күргәнебезчә, ул шактый төзек, ачык фикерле, кызыклы шигырьләр дә яза, шул ук вакытта, кайбер очракларда үтә-үтә метафорик сурәтләүләрдән торган, образлар, фикерне каплап китә язган әсәрләр дә бирә. «Гөштә», «Әгәр мине телефонга чакырсалар» кебек шигырьләр үз вакытында дөрес тәнкыйть ителделәр. «Нюанслар иле» циклында да Р. Фәйзуллинның куе сурәтле буяулар белән мавыгып китүе, шул сәбәпле шагыйрь әйтергә теләгәннәрнең укучыга тулы барып җитмәве характерлы. Ләкин циклда уңышлы тотып алынган шигъри детальләр дә булуын әйтми китәргә ярамый.

«Тулай торакта» дигән этюдка карыйк:

**Кызлар күптән йоклый.**
**Кефир шешәсендә гөлләр**
**Таңны көтә.**

Игътибар итеп карасаң, монда Р. Фәйзуллинның үз тенденциясе — гади генә детальләрдә шигърият күрергә омтылуы ярылып ята. «Кыш. Кечкенә авылда» парчасында да шул ук хәл:

**9 баллы давыл кичкән**
**Карт моряк**
**(Тельняшкасы бәби өстендә)**
**Бишек тирбәтә.**

Шагыйрьнең кемнәрне яратуы, нинди күренешләргә карап сокlануы ачык. Күпләр әйткәнчә, нюанслар — язучы блокнотына теркәп барылган, киләчәк әсәрләрдә файдаланырга исәп ителгән, композиция һәм ритм ягыннан эшкәртелмәгән өзек-өзек детальләр. Яшь шагыйрь, циклны матбугатка тәкъдим иткән тәкъдирдә дә, аны бик сайлап, аеруча уңышлыларын гына калдырып тәкъдим итәргә тиеш булгандыр.

Әмма шунысы бар, Р. Фәйзуллинның бу эскизлары һич кенә дә абстракционизм әсәрләре белән янәшә куела алмыйлар. Абстракционистларның асыл сыйфаты — кешедән, дөньядан бизү, антигуманизм булса, Р. Фәйзуллин бөтен җаны-тәне белән кешеләрне ярата. Һәм без яшь шагыйрьдә нәкъ шушы сыйфатның тагын да үсүен, тавышының көрәеп, утырган тавышка әйләнүен телик. Эзләнгән вакытта ясаган сөртенүләреннән яшь шагыйрь дөрес нәтиҗә чыгарсын һәм үз юлыннан ныграк басып атласын.

С. Ихсанова һәм Х. Мәхмүтов иптәшләрнең хатларында әйтелгән бер фикер мине сагаерга мәҗбүр итте. «Мондый әсәрләрне басмаска кирәк!» диләр алар. Әлбәттә, яшьләрнең әсәрләрен матбугатка тәкъдим иткәндә зур таләпчәнлек күрсәтергә кирәк. Каты балчыкта, коры туфракта тамыр җибәргән үсенте чыдам була. Яшь үстентене күләгәдә генә шыттырып, җил-яңгырдан саклап, су сибеп кенә үстерергә уйлау зур хата булыр иде. Ләкин яшь үсентеләрне хәвеф-хәтәрдән сакламый да ярамый. Күз-колак булырга да кирәк. Шуңа күрә яшь шагыйрьләрнең уңышлы әсәрләренә, нинди генә формаларны сынауларына карамастан, мөмкин хәтле киңрәк матбугат мәйданы бирергә кирәк. Үзләрен сынап карасыннар, кирәксә, борыннары бераз катыга тисен. Укучыларыбызның яшьләр иҗаты белән кызыксынып торуы да бу яктан бик файдалы. Өлкән шагыйрьләрнең, тәнкыйтьчеләрнең исенә төшереп тору өчен дә бу бик кирәкле. Ә безнең поэзиябез кырында яшь үсентеләр, әйткәнебезчә, соңгы елларда хәйран мул шыталар. Р. Фәйзуллин һәм Р. Гатауллин да, Р. Рәхимов һәм Рәшит Әхмәтҗанов кебекләр дә, Р. Миңгалимов һәм Ш. Маннаповлар да, М. Садыйков, Ф. Яруллин һәм К. Мостафиннар да үсәләр анда. Хәерләре белән үсеннәр, мул энҗе бөртекләр бирсеннәр.

## СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

# ДУСЛЫКНЫҢ МАТУР ҮРНӘГЕ

Пролетар интернационализмның ленинчыл принципларына нигезләнгән туганнарча дуслык, бердәмлек һәм үзара ярдәмләшү Советлар иле халыклары тормышында хәлиткеч көчләрнең берсе булып тора. Совет властеның ярты гасырга якын тарихында без моның бик матур үрнәкләрен күрә алабыз.

Киев, Харьков һәм Украина ССРның башка шәһәрләрендәге партия һәм дәүләт архивларында татар халкы белән украин халкы арасындагы дуслыкны, үзара ярдәмләшүне чагылдырган бик күп документлар саклана.

1921 ел. Яшь совет власте ачлыктан һәм империалистик сугыш китергән бәлаказалардан җәфа чигә. Эчке һәм тышкы дошманнар хезмәт ияләренең авыр көрәштә яулап алынган азатлыгын буарга һәрьяклап кул сузалар.

Шушы авыр шартларда В. И. Ленин, Коммунистлар партиясе илебез халыкларын тыныч төзелеш эшен башларга, социалистик экономиканың нигезен салуга, эшчеләр һәм крестьяннар союзын һәм төрле милләт хезмәт ияләренең бердәмлеген тагы да ныгытуга юнәлдерә, аларны җимереккә, ачлыкка каршы көрәшкә туплый алды.

Советлар иле халыклары алдындагы интернациональ бурычын яхшы аңлаган Украина хезмәт ияләре Идел буенда, шул исәптән Татарстанда ачлык китергән бәлаказаларны бетерүдә рус һәм башка халыкларга зур ярдәм күрсәтте. Бу елларда Украина партия оешмасы бөтен масса-политик эшне Советлар илендәге тугандаш халыкларга ярдәм итү буенча чын-чынлап интернациональ йөкләмәне үтәүгә юнәлдерде.

Үзе җитди авырлыклар кичерүгә карамастан, украин халкы сыйныфташ туганнары белән, социалистик киләчәк өчен көрәштәшләре белән барлык нәрсәсен бүлеште.

«Идел буена ярдәм — теләктәшлек белдерү генә түгел, — дип язды Донецкида чыга торган «Всероссийская кочегарка» газетасы (17. IX. 1921 ел). — Без Идел буе язмышына бөтен Россия язмышы бәйле икәнен беләбез. Идел буе һәлакәткә дучар була икән, без дә бетәбез... Идел буен коткарып, без революцион бурычыбызны гына үтибез».

Коммунистлар партиясе чакыруы буенча, Украина эшчеләре яңа хезмәт вахтасына бастылар, йөзләрчә өмәләр үткәрделәр. Алардан килгән акча ачлык белән җәфа чигүчеләр фондына җибәрелде. Екатеринослав шәһәрендә генә дә 1921 елның сентябрь аенда хезмәт ияләре өмәләрдә 10 миллион сумлык эш башкаралар.[1] Араларында меңнәрчә татарлар булган Донбасс шахтерлары өмәләр ясап 4 миллион пот өстәмә күмер чыгаралар. В. И. Ленин һәм Коммунистлар партиясе чакыруы буенча, Украина крестьяннары да Идел буе хезмәт ияләренә зур ярдәм күрсәтәләр.

1921 елда Украинада Татарстан өчен 138 502,32 пот борчак, 3100 пот вика, 28 627,23 пот арпа, 595 пот көнбагыш җитештерелә[2]. 1922 елның ноябрь аенда гына да Подольск губернасыннан тугандаш татар, мари һәм калмык халыкларына икмәк белән 83 олау җибәрелә. Совет Украинасы хезмәт ияләре Татарстан республикасына һәм Идел буендагы башка өлкәләргә күп кенә махсус дәвалау һәм туклану пунктлары оештырып җибәрәләр.

Украина хезмәт ияләре Идел буеннан килгән ун меңнәрчә балаларны ачык чырай белән кабул итә. Винницк губернасына Татарстаннан 1924, Харьков шәһәренә 602 бала килә. Украина эшчеләре һәм крестьяннары аларны тәрбияләү һәм укыту өчен бөтен мөмкинлекләрне тудыралар. Гражданнар сугышы герое, турылыклы ленинчы В. Примаков җитәкчелегендәге Кызыл казачество корпусы сугышчылары бу балаларны тәрбияләүдә зур кайгыртучанлык күрсәтәләр. Кызыл казаклар үз акчалары һәм болай да аз паеклары хисабына күп

---

[1] Украина КП ҮКның партия тарихы институты партия архивы, фонд 32, оп. 1, сак. бер. 173, 49 бит.

[2] И. М. Климов. Совет хөкүмәтенең һәм бөек рус халкының 1921—1922 елларда ачлыкка каршы көрәштә Татарстан хезмәт ияләренә ярдәме. Казан университеты гыйльми язмалары. 114 том, 5 китап, 1954 ел, 121 бит.

кенә балалар йортлары тоталар. Украина язучысы, шул корпус составындагы полк командиры И. Дубинский Литин шәһәренә китерелгән татар балалары турында болай дип яза: «Шәһәрдән саегып калган Згар елгасы тамагына таба, шау-гөр килеп, чуар киемле балалар колоннасы килә. Алар кызыл казаклар тарафыннан күптән түгел генә оештырылган балалар йортыннан. Анда тәрбияләнүчеләр ачлыктан интегүче Татарстаннан китерелгәннәр. Колонканың башында аларның начальнигы, взвод командиры, элеккеге Кривой-Рог шахтеры Почекайбрат бара. Ул кечкенәләргә азыкны да үзе әзерли, ертык-портыкларын да тегә, киендерә һәм, яшь казак Семен Вовков белән бергәләп, хәреф танырга да өйрәтә. Балалар үзен яхшырак аңласын өчен, ул еш кулланыла торган татар сүзләрен өйрәнеп алган. Кама һәм Идел буйларында туган балаларга Украина гүзәле — Днепр, шахтерлар хезмәте, кызыл казакларның данлыклы эшләре турында сөйли. Бәлки менә нәкъ шуңа күрәдер дә, Почекайбратның түбәтәйле тәрбияләнүчеләре, кызыл лампаслы галифе чалбарлар киеп, үзләренчә фыртаеп йөриләр».[1]

1921 ел башында Украинада татар балалары өчен 120 балалар учреждениесе оештырыла. Аларда тәрбия эшләре һәм укыту балаларның үз ана телләрендә алып барыла.

«Правда» газетасы ул көннәрдә татар балаларын Украинадан туган илләренә озату күренешен түбәндәгечә сурәтли:

«...Ниһаять, авыр аерылышу сәгатьләре килеп җитте. Балалар киенеп бетеп, тәрбиячеләр һәм үзләренең украин дуслары белән саубуллаша башлагач, елашу китте — һәм бу табигый да, чөнки май аеннан бирле алар шатлыкларны да, авырлыкларны да уртаклашып яшәделәр... Иң мөһиме шул, балалар биредә үзләренә карата эчкерсез, самими аналарча мөнәсәбәт күрделәр. Хәтта, менә кадәр гел кырыс йөзле булып күренгән карт сугышчы казак, хәзерге хуҗалык мөдире дә елап алды, анпары исенә килеп, олаулар әзер икәнлеген белдерде».

Украина хезмәт ияләре гражданнар сугышыннан соң Украинада яшәп калган татар халкы вәкилләренә карата да һәръяклап туганнарча кайгыртучанлык күрсәтте, ачлык һәм җимереклек елларында Татарстаннан күчеп килгән меңнәрчә эшчеләрне ачык чырай белән каршы алды. Бу туганнарча бердәмлекнең, пролетар интернационализмның конкрет чагылышы иде.

Архив материалларыннан күренгәнчә, 1921 елда Украина территориясендә 90 мең татар булган. Шуларның 40—50 меңе Донбасста, калганнары Киев, Харьков, Одесса һәм башка шәһәрләрдә яшәгәннәр. 1921 елда Донбасска көн саен йөзгә якын татар эшчеләре килеп торган.

Татар хезмәт ияләре арасында масса-тәрбия эшләре алып бару өчен Украина партия оешмалары каршында татар секцияләре оештырыла. Шундый ук секция республикабызның Мәгариф халык комиссариатында да була. Бу секцияләр Украинадагы татар халкы арасында милли культура тәзелеше, культура агарту мәсьәләләрен, мәктәп һәм мәктәпкә кадәрге тәрбия учреждениеләре эшләрен киң җәелдерүдә актив роль уйныйлар.

Украина Коммунистлар партиясе, татар хезмәт ияләре арасында политик-масса эшләрен алып барганда, бөек рус халкы һәм Советлар илендәге башка халыклар белән берлектә революцион көрәштә чыныккан татар коммунистларына таяна. Татар коммунистлары пролетар интернационализм идеяләрен эзлекле рәвештә тормышка ашыру буенча күп эш башкаралар, үзләрен хезмәт ияләре массасы арасында политик-масса эшләрен җәелдерү буенча Коммунистлар партиясенең турылыклы ярдәмчеләре итеп танытапар.

Коммунистларның һәм татар хезмәт ияләренең алдынгы вәкилләренең идея-теоретик әзерлек мәсьәләләренә җитди игътибар юнәлтеп, Украина Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты һәм партиянең губерна оешмалары партия мәгарифе системасы буенча аларның марксистик белемнәрен күтәрүдә зур кайгыртучанлык күрсәтәләр. Украина Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты каршындагы югары партия мәктәбендә укырга күп кенә татар коммунистлары алына. Украинада татар телендә совет-партия мәктәбе оештырыла, ә Донецк губерна совет-партия мәктәбендә татар бүлеге ачыла. В. Куйбышев күрсәтмәсе нигезендә, 1922 елның маенда Донбасстан 50 татар коммунисты, укуларын дәвам иттерү өчен, Казанга, берләштерелгән югары совет-партия мәктәбенә җибәрелә. Донбасс шахталарындагы татар коммунистлары ячейкаларын ныгыту өчен Харьковтан, Киевтан һәм Татарстан республикасыннан тәҗрибәле коммунистлар чакыртыла.

Татар хезмәт ияләре арасында марксизм-ленинизм һәм пролетар интернационализм идеяләрен пропагандалауда 1921 елның башыннан татар телендә чыга башлаган «Эшче тавышы» газетасы зур роль уйный. Газетаны бастыруда һәм кирәкле материалларны булдыруда Украина Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының агитация-пропаганда бүлеге зур ярдәм күрсәтә. «Эшче тавышы» УКП Үзәк Комитетының рәсми органы «Коммунист» газетасы типографиясендә басыла. Татарстаннан 42 пот татар хәрефләре китерелә.

Татар хезмәт ияләренә шулай ук турыдан-туры Татарстаннан «Эшче», «Татарстан хәбәрләре», «Эш», «Чаян» һ. б. газета-журналлар алдырырга мөмкинлек тудырыла. Бары 1921 елның 1 апреленнән 1 июненә кадәр вакыт эчендә Донецк губернасындагы татар хезмәт ияләре арасында 12583 газета, журнал һәм китап таратыла.

Партиянең Донецк губерна комитеты каршындагы татар секциясе татар совет-партия матбугаты файдасына даими ярдәм фонды оештыру инициаторы була. Татар милләтендәге Донбасс шахтерлары 1922 ел-

[1] И. Дубинский. Сурмачі сурмлять тривогу. 1961 ел, 171 бит.

ның декабре, 1923 елның январь ае хезмәт хакларының бер өлешен «Эшче газетасы файдасына җибәрергә карар чыгаралар.

Республиканың партия комитетлары, хәрби частьлары, предприятие һәм заводлары каршындагы татар секцияләре Украинада яшәүче татар хезмәт ияләрен яңа экономик политиканы тормышка ашыруга, совет җәмгыяте тормышын яңа социалистик башлангыч нигезендә коруга мобилизацияләү буенча зур политик һәм оештыру эшләре башкаралар.

Татар хезмәт ияләренең идея-теоретик һәм гомуми белемнәрен күтәрүдә татар клубларында үткәрелгән чаралар да зур роль уйный. УКП Үзәк Комитеты һәм Украина совет хөкүмәте шундый алты клуб оештырырга мөмкинлек таба. Бу клублар тиздән чын-чынлап политик-масса һәм культура-агарту, татар хезмәт ияләренең политик аңын күтәрү үзәгенә әвереләләр. Клубларда Советлар иленең эчке һәм тышкы политикасына багышланган тематик кичәләр, митинглар, җыелышлар үткәрелә, лекцияләр һәм докладлар укыла, җанлы газеталар оештырыла. Бигрәк тә Харьков шәһәрендәге татар эшчеләре һәм кызылармеецларның Үзәк политик клубы бу өлкәдә актив эшли. 1921 елның өч ае эчендә генә дә (1 апрельдән 1 июньгә кадәр) бу клубта 5 митинг-концерт, татар яшьләре өчен махсус митинг үткәрелә. Анда Беренче Май бәйрәме тантаналы рәвештә билгеләп үтелә, бәйрәм унае белән махсус листовка чыгарыла һәм шәһәрдәге барлык татар хезмәт ияләре арасында таратыла. Шулай ук партиянең Луганск өязе Брянск район комитеты каршындагы клуб, Дебальцев өязе Петровск клубы, Юзовкадагы В. И. Ленин исемендәге гарнизон клубының татар секциясе дә уңышлы эшләп килгән.

1922 елны партиянең губерка комитеты каршындагы татар секциясе Донбасстагы татарлар арасында революцион хәрәкәт тарихы, Бөтенроссия кочегаркасын торгызу өчен аларның хезмәттәге энтузиазмы турында материаллар җыярга керешә.

Татар клубларында педагогия, әдәбият, драма, музыка түгәрәкләре эшләп килә. 1920 елның ахырында Харьков шәһәрендә ачылган алты айлык татар студиясе әзерләгән артистлардан татар театр труппасы оештырыла. Алар башкаруында татар эшчеләре өчен күп кенә спектакльләр куела.

Украинада яшәүче татар хезмәт ияләре арасында мәгариф эшен яхшырту өчен 1920 елда 8 миллион сум, 1921 елда 15 миллион сум акча бүленә. Шул ук елны татар мәктәпләренә чит илләрдән дәреслекләр сатып алу өчен республиканың мәгариф органнары алтын белән 1000 сум акча бирәләр. 1921 елның башында татар укытучылары һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар тәрбиячеләре өчен курслар ачыла.

Эшчеләр өчен тау эшләре, слесарьлык һәм авыл хуҗалыгы бүлекләреннән торган татар телендә һөнәр мәктәпләре оештырыла. Шулай ук татар хезмәт ияләрен укыргаязарга өйрәтү буенча күп кенә махсус пунктлар ачыла, клублар каршында кечке мәктәпләр эшләп килә. Донбасстагы татар мәктәпләрендә эшләү өчен Татарстаннан 25 татар укытучысы чакыртыла.

Республиканың партия оешмасы татар коммунистларына татар һәм украин халыклары арасындагы дуслыкны какшатырга тырышучы буржуаз милләтчеләрнең астыртын эшләрен фаш итүдә ярдәм итә. Шулай ук Украина буржуаз милләтчеләре дә Украина халкының башка тугандаш халыкларга ярдәмен тоткарларга маташалар. Украина Коммунистлар партиясе буржуаз милләтчеләрнең башка милләт халык вәкилләрен республиканың дәүләт, экономика һәм культура төзелеше эшләренә катнаштырмау һәм шуның белән Советлар иленең әһәмиятле әйдәүче көчен—халыклар дуслыгын какшатырга тырышуларына каршы көчле отпор бирә.

Татар секцияләре, җирле партия оешмалары ярдәмендә, мәктәпләрне руханилар йогынтысыннан аралау буенча зур эш башкаралар. Мәсәлән, Донбасста башында реакцион руханилар һәм милләтчеләр торган советка каршы оешма фаш ителә [1].

Татарлар арасында диңгә каршы көрәш буенча Донецк комсомол оешмалары зур эш башкаралар; лекцияләр, әңгәмәләр, демонстрацияләр үткәрелә.

Татар эшчеләре Донбасс шахталарында, рудникларында, республиканың завод һәм фабрикаларында фидакарь хезмәт активлыгы күрсәтәләр, Советлар Украинасының халык хуҗалыгын торгызуда үзләренең интернациональ һәм сыйнфый бурычларын намус белән үтиләр.

Юзов районында яшәүче татар шахтерларының (1921 елда анда 5 мең татар шахтеры эшләгән) героик хезмәте аеруча игътибарга лаек. 1921 елның апрель аенда гына да анда 500 өмә үткәрелә. Ул өмәләрдә 70 мең кеше катнаша. Хезмәттәге батырлыклары өчен 1921 елда РСФСР Үзәк Башкарма Комитеты Юзов шахтерларын Кызыл Байрак белән бүләкли.

Донбассның Альчевский рудннгындагы татар шахтерларының гомуми җыелышы резолюциясендә: «Без, татар эшчеләре, барлык халыкларга яңа, ирекле тормыш төзүдә тигез һәм азат хокуклар биргән Совет властен сакларга сүз бирәбез. Яшәсен Совет власте! Яшәсен Коммунистлар партиясе!» дип күрсәтелә [2]. Криндачев, Ирмен, Екатеринодон, Луганск һ. б. рудникларда һәм шахталарда эшләүче татар эшчеләре дә шундый ук резолюцияләр кабул итәләр.

Донбассны торгызуда составларында йөзләрчә татарлар булган хезмәт отрядлары зур роль уйный. 1921 елда махсус оештырылган ВУЧК дивизиясенең 90 проценты татарлардан торган [3]. Бу дивизия Донбасс

---

[1] Октябрь революциясенең УССР Үзәк дәүләт архивы, фонд 539, оп. 1, сак. бер. 827, 42 бит.

[2] УКП ҮКның партия тарихы институты партия архивы, фонд 3, оп. 1, сак. бер. 306, 57 бит.

[3] Октябрь революциясенең УССР дәүләт архивы, фонд 539, оп. 1, сак. бер. 445, 91 бит.

шахтерларына — миллионнарча тонна күмерне тоядә һәм бушатуда, кучерудә; губерна крестьяннарына — чәчү һәм урып-җыю кампанияләрен үткәрүдә зур ярдәм күрсәтә.

Губерна халкы арасында дивизия сугышчылары зур аңлагу эшләре алып баралар. Дивизиянең команда һәм политик составы барлык кызылармеецларны халык арасында политик агарту эшләренә тарта. Кызылармеецлар авыл халкы арасында Коммунистлар партиясенең һәм Совет хөкүмәтенең карарларын актив пропагандалыйлар. Украина буржуаз милләтчеләренең идеологиясен, банкротлашкан анархизмның үрнәге булган махновщинаны фаш итүдә зур роль уйныйлар.

Украина хезмәт ияләре өчен тыныч төзелеш шартлары тудыру эшендә татарлар турыдан-туры һәм актив катнашалар. Мәсәлән, 1920—1921 елларда Донецк губернасы территориясендә хәрәкәт иткән Махно һәм Петлюра башкисәрләрен тар-мар итүдә ВУЧК дивизиясенең роле гаять зур. Шуның белән бергә дивизиянең политик составы губернадагы крестьяннарны кулак бандаларына каршы көрәшкә күтәрү буенча да зур эш эшли.

Махсус хәрби частьлар составындагы йөзләрчә, меңнәрчә татар сугышчылары Украина милләтчеләренә, кулак-бандаларына каршы көрәштә зур батырлыклар күрсәтә. «Рәхим Гыйматуллин, Исмәгыйл Ишмбаев, Гали Мурзин — 7 Кызыл казаклар полкы үзенең даны белән әнә шул сугышчан бөркетләргә, куркусыз батырларга бурычлы» дип яза элекке полк командиры, югарыда исеме әйтелгән язучы И. Дубинский.

Петлюра башкисәрләренә каршы операция вакытында татар балаларының якын дусты — балалар йорты директоры Панас Почекайбрат батырларча һәлак була. «Коммунист» газетасы язганча, «бандитизмга каршы көрәштә һәлак булган төрле милләт вәкилләре илебез халыкларының туганнарча союзын үз каннары белән ныгыттылар»[1].

Архив документлары Совет властеның беренче елларында ук украин эшчеләре һәм крестьяннары белән татар хезмәт ияләре арасындагы эчкерсез дуслык мөнәсәбәтләрен бик ачык күрсәтәләр. Бу дуслык һәм туганнарча бердәмлек социалистик бишьеллыклар чорында тагы да ныгыды, Бөек Ватан сугышы елларында тагы да чыныкты, тагы да беректе.

Социалистик интернационализмның ленинчыл принципларына нигезләнгән Советлар иле халыклары арасындагы дуслыкны какшатырлык көч юк. Бу дуслык тугандаш халыкларның гүзәл киләчәккә, коммунизмга бару юлын көчле факел булып яктырта.

Ю. РИМАРЕНКО,
Киев.

---

[1] «Коммунист» газетасы, 19 март, 1922 ел.

—●—


## ИҢ-ИҢ...

Дөньяда иң кыйммәтле җир участоклары Англиянең финанс-промышленность магнатлары резиденциясе урнашкан Лондон Ситиенда. Ситиның һәр квадрат метрдан чак кына артыгран мәйданын 1950 елның сентябрь аенда өч йөз мең фунт стерлингка сатканнар. Шул акчаны бер фунт стерлингтан торган банкнотларга әйләндерсәң, сатып алынган мәйданга берничә кат итеп җәеп чыгарга җитәр иде!

●

Дөньядагы рәсем сәнгате әсәрләренең кайсысы иң кыйммәт тора? Бу сорауга төгәл генә җавап бирү һич тә мөмкин түгел, чөнки дөнья музейларындагы һәм картина галереяларындагы иң әйбәт әсәрләрне сатмыйлар. Шулай да ул рәсемнәргә якынча бәя бирел була икән. 1963 елда, Луврдан Нью-Йоркка һәм Вашингтонга күргәзмәгә алып барылуы уңае белән, Леонардо да Винчиның «Джоконда»сын йөз миллион долларга страховать иткәннәр.

Яңарыш чорының бөек художнигы тарафыннан 1507 елда эшләнеп бетмән бу рәсемне 1517 елда Франция короле Франциск I дүрт мең алтын флоринга сатып алган һәм аның белән үзенең ванна бүлмәсен бизәгән булганлыгын да искәртеп үтик.

*Л. Кизя*

# ПАРТИЗАН МОРАТ



*Легендар Сидор Артемьевич Ковпак җитәкчелек иткән партизаннар берләшмәсендә 1942 елның 25 маенда татар халкының һәм бөтен совет халкының турылыклы улы, Теләче районы Олы Кибәхуҗа авылы егете Морат Әхмәтсафа улы Мостафин геройларча һәлак булды.*

*Мин Мостафинны яхшы белә идем, аның белән күп мәртәбәләр сугышта булдым. Мостафин кыю, социалистик Ватанга чиксез бирелгән егет иде. Ул, Алтын Йолдызы булмаса да, чын герой иде.*

*Бу турыда туганнарына хәбәр итүегезне үтенәм...*

**Чын күңелдән хөрмәт белән — С. А. Ковпак берләшмәсендәге элеккеге политрук, Украина ССР Югары һәм махсус урта белем министры урынбасары — Л. Е. Кизя.**

Соңгы шартлау тавышлары куе чыршы урманына җәелеп таралдылар да тирә-як кинәт тынып калды. Куркынып як-якка карана-карана, урман кырыеннан бер төркем немец солдатлары узды. Морат, куаклар арасына яшеренгән килеш, аларның чит-ят телдә нәрсә турындадыр гәпләшүләрен аермачык ишетеп ятты. Тиздән ул тавышлар да тынды. Урманны үлем тынлыгы биләп алды.

«Безнекеләр тагын чигенделәр,— дип уйлап куйды Морат.— Менә, сау-сәламәт була торып, дошман тылында кал, имеш. Яраланган булсаң, бер хәер иде. Әти-әниләргә, нәни кызым Флүрәгә нәрсә язарлар инде? «Хәбәрсез югалды», дипме? Эш анда гына да түгел. Эш шунда: сугышып булмый, бер генә дә патрон калмады бит. Ни эшләргә?»

Шул вакыт ул, якында гына яфраклар кыштырдавын ишетеп, куак арасына тагы да эчкәрәк посты. «Кем булыр икән бу?» Ул арада кыштырдау якынайды, яфраклар арасыннан пилотка кигән таныш йөз күренде.

— Хәерле кич,— дип, кинәт каршына килеп чыккан Мостафинны күргәч, рядовой Сережа Санков югалып калды.

— Исәнмесез, иптәш политрук!

Бу очрашуга икесе дә бик куаныштылар.

— Утыр әйдә,— дип чакырды ул куак арасына Сережаны.— Ни эшләргә уйлыйсың хәзер?

— Ни эшләргә булсын? Фашистларны дөмбәслибез! — Санковның уйлап та тормастан, бик кыю әйткән бу җавабы Мостафинга ошады.

Алар шулай сөйләшеп утырганда, урман авызыннан сыерлар көтүе

килеп чыкты да якындагы авылга таба юнәлде. Көтүче — борын астына әле мыек та чыга башламаган яшүсмер малай гына иде. Көтүче малайны үзләре янына чакырып алдылар. Мостафин планшетыннан карта алды да малайдан:

—. Авылыгызның исеме ничек? — дип сорады. Малай шартлатып җавап бирде.

— Сумы өлкәсенең Урта Буд районы Красичка авылы,— диде.

— Кара әле, егет кеше, авылда ни хәлләр барын белешеп, безгә хәбәр итә аласыңмы?

— Нишләп алмаска, ди?! — һәм малай, көтү артыннан йөгереп китеп барды.

Морат муенына эленгән биноклен салды да Сергейга сузды:

— Менә сиңа бинокль, Санков. Агач башына мен дә авылдан килә торган юлны күзәт. Барысы турында да миңа хәбәр итәрсең.

— Тыңлыйм.

Мостафин картаны өйрәнергә кереште. Район үзәгенә егерме километрлар булыр. Тоташ массив булып җәелеп киткән Брянск урманнарына кадәр дә шуннан ким түгел...

— Авылдан бер хатын чыкты,— дип хәбәр итте агач башыннан Санков.— Ашыкмый гына монда таба килә. Үзе тирә-ягына карангалый.

— Үзе генәме?

— Үзе генә.

— Килә бирсен.

Менә хатын урманга килеп җитте. Бөтен тирә-юньгә күз йөртеп чыкты. Ләкин беркемне дә күрә алмады.

— Күрәсең, шикләнгәннәр, — диде хатын үз-үзенә, — китеп тә барганнар... Аһ-у-у...

— Без биредә, апай,— дип Мостафин, җир тишегеннән чыккандай, хатын алдына килеп басты. — Исәнмесез!..

Моратның эчендә күптән «бүре улый» иде инде. Ике тәүлек авызга азык алып карамаган. Хатын, моны белгәндәй, аңа икмәк кисәге һәм бер шешә сөт сузды. Морат ипине икегә сындырды да яртысын Санковка бирде, шешәнең кукуруз бөкесен ачты. Икәүләп тамак ялгап алдылар. Мостафин күтәрелеп әлеге хатынга карады. Аның алдында берничә дә апай түгел, нечкә, зифа гәүдәле чибәр генә кыз басып тора иде.

— Рәхмәт сезгә, бик зур рәхмәт, — диде Мостафин аңа. — Кияүдәме?

— Юк әле. Комсомолка. Күптән түгел генә урта мәктәпне тәмамладым.

— Авылда немецлар күпме?

— Күп иде. Хәзер инде күп түгел. Кечкенә генә бер төркем. Алар да авылның аръягында. Бүтәннәре мәетләрен күмделәр дә тагын көнчыгышка киттеләр. Мәетләрен чишендереп тә тормадылар, шинельдән, итектән, мылтыклары белән күмделәр.

— Бик яхшы. — диде Морат. — Безгә кайда яшәп торырга, баш-күз алырга мөмкин булыр икән?

— Безнең күршеләребез бик әйбәт, ышанычлы кешеләр, — дип җавап бирде кыз.

— Исемең ничек соң синең?

— Дуся. Фамилиям Володько.

Караңгы төшә башлады. Күзгә энгер-менгерне бик тиз күз караңгылыгы алыштырды.

— Киттекме авылга,— диде Морат, Сережага карап.

Төнге караңгылыкка сыенып, алар авылга килеп керделәр. Дуся, Мостафин белән Санковны ышанычлы кешеләргә урнаштыргач, өенә кайтып китте. Украиналылар татар һәм рус егетен ачык чырай күрсәтеп каршыладылар.

Ике айлап вакыт үтеп китте. Кызыл Армия авыл һәм шәһәрләрне калдыра-калдыра чигенүендә дәвам итә иде. Ниһаять, немецларның Мәскәү астында тар-мар ителүе турындагы шатлыклы хәбәр авылга да житте...

Тышта чатнама салкын булса да, Моратның күңеле кайнап-ашкынып тора иде. Утын киссенме, кар көрәсенме, ул эченнән генә һаман бер җырны җырлый:

**«Идет война народная,**
**Священная война...»**

Кар шыгырдавыннан да, ярыкларга кереп җил сызгыруыннан да шул җырның көе ишетелгәндәй тоела иде аңа.

Озак та үтмәде, тагын бер шатлыклы вакыйга булды: авылдан якында гына С. А. Ковпак житәкчелегендәге зур партизаннар берләшмәсе узуы турында хәбәр ишетелде. Партизаннар берләшмәсенең разведкасы хәтта Красичка авылына да килде. Мостафин озак уйланып тормады, хуҗаларга рәхмәт әйтеп саубуллашты да Ковпак отряды эзеннән чыгып китте. Шулай эз буйлап бара торгач, Ковпак берләшмәсе составындагы Колевецкий житәкчелегендәге отрядка юлыкты. Аны бу отрядта партизаннар группасы командиры итеп билгеләделәр.

Ковпак партизаннары сугышларда дан казандылар. Төрле милләт вәкилләреннән булган коммунистлар, комсомолецлар һәм партиясез патриотлар дошман тылында яңадан-яңа батырлык үрнәкләре күрсәттеләр.

1942 елның Беренче Май бәйрәме. Бу бәйрәмне партизаннар тантаналы итеп үткәрделәр. Иске Гута авылында уздырылган партизаннарның хәрби парадына Морат Мостафин да катнашты. Парадны берләшмә командиры С. А. Ковпак һәм комиссар С. В. Руднев кабул итте. Киселгән агач төпләренә баскан килеш, алар пехотачыларны, артиллеристларны, кавалеристларны Беренче Май бәйрәме белән котладылар.

Бердәм «Ура!» тавышлары тынуы белән, тынгылык белмәгән командир партизаннар алдына яңа бурыч куйды: Украина жиренә тирән рейд ясарга! Язгы юлсыз вакыт иде: ни арба, ни чана. Шулай да май урталарында Ковпак партизаннары дошманнар белән сугыша-сугыша борынгы Путивль шәһәренең стеналары янына килеп життеләр...

24 майда коеп яуган янгыр астында күзгә төртсән дә күренмәслек төнге караңгыда Литвиновичи авылына кердек. Авыл халкы партизаннарны ачык күңел белән каршы алды. Шунда безгә Иске Шараповка авылына урнашкан дошман гарнизонын тар-мар итәргә приказ килде. Безгә билгеле булган хәбәрләр буенча, анда яхшы коралланган ике йөзләп дошман солдатлары һәм офицерлары булырга тиеш иде. Ә безнең партизаннар аларның яртысы кадәр дә юк иде диярлек.

— Кинәттән һөжүм итәбез, — диде отряд командиры Василий Кудрявский,—искәрмәстән һөжүм итәбез икән, бу инде ярты жиңү дигән сүз.

Янгыр һаман коеп ява иде. Алдыбызда Клевань елгасы. Төн инде таңга авышты. Иртәнге 3 ләр чамасы. Сызылып 25 майның таңы беленде. Таң яктысында алда Иске Шараповка авылындагы йорт, каралты күләгәләре күренә башлады. Елга аша жәяүләп кенә чыгарлык иске күпер бар иде. Дошман партизаннар һөжүм итәсен көткән һәм елга ярларына миналар куйган икән, кинәт бик көчле шартлау тавышы янгырады, һава дулкыны дистәләп партизанны жиргә екты, туфрак катнаш мина ярчыклары әллә кайларга чәчрәде. Берничә партизан һәм отряд комиссары Онопченко шунда мәңгегә ятып калды.

Шартлау тавышыннан дошман гарнизоны аякка басты. Искәрмәстән һөжүм итү планы юкка чыкты.

— Шулай да приказны үтәргә кирәк, — диде командир һәм безне һөҗүмгә алып китте.

Көн яктыргач, яңгыр туктады, күк аязды, офык тирәсендә сирәгәеп калган болытлар чыгып килгән кояш нурларыннан кан төсенә керде.

Иртәнге тынлыкны пулемет такылдавы бозды, минометлар дошман өстенә мина яудырырга тотындылар, өстебездән дошман ягына Ковпак артиллериясе снарядлары очты.

Ләкин дошман партизаннарны бар төр коралларыннан ут ачып каршы алды. Аяусыз сугыш кызганнан кызды. Тиздән безнең сирәгәйгәннән сирәгәя барган сафларыбыз чигенә башлады. Дошман безне урманга кысты. Ә урман — партизаннар крепосте, анда дошманнарга хакимлек итәргә юл куярга ярамый. Шулаен шулай да, ләкин... көчләр тигез түгел.

Сугыш һаман кызганнан кыза барды. Дошманнар инде безне камап алып, тәмам тар-мар итеп бетерер кебек иде.

Шул вакыт кинәт дошман солдатлары арасында безгә аңлашылмаган ниндидер тәртипсезлек башланды. Немец солдатлары һөҗүм иткән җирләреннән кинәт ни алга, ни артка йөгерергә белмичә аптырап, каушап калдылар, берьюлы диярлек дистәләгән дошман җиргә тәгәрәде. Гүя әкиятләрдә генә була торган ниндидер көч, безгә ярдәм итәргә теләп, дошманнарны үзенең дәһшәтле сулышы белән өтә, яндыра кебек иде.

Моның сәбәбен тикшереп торырга вакыт юк иде, партизаннар кинәт дәртләнеп киттеләр, пулеметчылар, минометчылар, уңайлырак позицияләр сайлап, дошманга көчле, бердәм ут ачтылар. Дошман солдатлары кырга чигенде. Безгә шул гына кирәк, тигез болын өстендә алар уч төбендәге кебек иде. Немецлар Иске Шараповка авылына чигенде. Урманда, кырда һәм яр буйларында немецларның йөздән артык үле гәүдәләре калды. Бик күп кораллар кулга төшердек.

Бу тигезсез сугышта безгә җиңү китергән сәбәп нәрсә булды соң? Без моны соңыннан гына белдек.

Морат Мостафин урман арасыннан үрмәләп, дошманның тылына чыга. Немец пулеметчысын атып үтерә дә, пулеметны һөҗүм итүче дошман сафларына төбәп, ут ача.

Партизаннарның бу җитди операциясен уңышлы башкарып чыгуга Морат Мостафинның кыюлыгы гаять зур ярдәм итте. Ләкин безнең шатлык озакка бармады: сугышның соңгы минутларында дустыбызны, кадерле батыр Моратыбызны дошман пулясы безнең арабыздан алып китте.

Һөҗүм башланыр алдыннан гына Морат миңа сугыштан соң, Красичка авылына барып, авыр минутларда ярдәм кулы сузган украинлы дусларына рәхмәт белдерәсе килүен әйткән иде. Ләкин бу теләген тормышка ашыра алмады ул, Украина җирен азат итү өчен башын салды...

Татар һәм бөтен совет халкының турылыклы улы Морат Әхмәтсафа улы Мостафинны Шараповка авылы янындагы Спадщань урманындагы туганнар каберлегенә күмдек.

— Ватан сине бервакытта да онытмас, Морат, — диде командирыбыз Кудрявский. — Партизанга, сугышчыга, коммунистка, чын кешегә мәңгелек дан!

Партизаннар винтовкалардан, пистолетлардан атып өч тапкыр салют бирделәр. Залп тавышлары урман эчендә, кайтаваз булып, озак яңгырап торды...

**Редакциядән.** Иптәш Л. Е. Кизяның хатын һәм очеркын алгач та, без, батыр якташыбыз Морат Мостафин турында тулырак мәгълүмат алу өчен, аның туган авылына — Саба районы, Олы Кибәхуҗа авыл Советына хат яздык. Ул хат батырның Астрахань шәһәрендә яшәүче сеңелесе Ләбибә ханым Мостафинага барып җиткән. Ул безгә Морат Мостафинның рәсемен җибәрде һәм түбәндәгеләрне хәбәр итте:

*«Этиебез, Мостафин Әхмәтсафа, укытучы иде. Пенсиягә чыкканның соңында үзебезнең Олы Кибәхуҗа колхозында башта агротехник, Бөек Ватан сугышы башлангач, колхоз председателе булып эшләде. 1943 елны авырып үлде. Әниебез, Мостафина Зәйнәпбикә, хәзер 80 яшендә, исән-сау, минем белән тора. Морат абыем өчен 29 сум 70 тиен пенсия ала...*

*Морат абыем 1916 елда туган. Берничә еллар укытучы булып эшләде. Саурыш, Олы Кибәхуҗа һәм Югары Кибәхуҗа авылларында укытты. Аннан соң Теләче районы газетасына күчерделәр. Армиягә шуннан алынды. Армиядә укырга керде. Укуын тәмамлагач, политрук урынбасары булып хезмәт итте. Сугышның башында ук аны фронтка җибәрделәр. Бик озак вакытлар хаты килми торды. Ниһаять, 1942 елның 2 маенда язылган хатын алдык. Бу аның соңгы хаты булды.*

*Абыемның 1936 елда туган кызы Флүрә хәзергә вакытта исән-сау, Кустанай өлкәсендә тормышта, ике баласы бар.*

*Морат абыемның соңгы хатына каршы җавап язган идем. Әмма минем хат барып җиткәндә, абыем инде... Хатымның буш калган урынына абыемның һәлак булуы турында партизан иптәше язган кыска гына җавап килде. Шуннан бирле аның турында бер хәбәр дә ишеткәнебез юк иде.*

*Менә бу яңа хәбәрне ишетү әниемне, мине һәм барлык туганнарны бик шатландырды. Без аның яшьтән үлеп китүенә еласак та, фашистларга каршы сугышта күрсәткән батырлыкларына горурланабыз. Абыемны искә алып, аның туган илебез өчен ничек һәлак булуы турындагы хәбәрне җибәргәне өчен абыемның дусты Л. Е. Кизяга туганнарча рәхмәт белдерәбез һәм рәхмәтебезне аңа җиткерүегезне сорыйбыз...»*

## Морат Мостафинның соңгы хаты

*«Дошман тылыннан хат.*

*Исәнмесез!*

*Барыгызга да сагынып сәлам. Күрше-колан, кардәш-ырууларның барчасына да сәлам диярсез. Сәлам соңында—үзем исән-сау. Менә нәкъ сигез айдан соң сезгә хат язарга мөмкинлек алдым. Узган елның октябреннан бирле үзем дошманның тылында фашист этләренә каршы көрәш дәвам иттерәм. Көннәр җылыну белән безнең көрәш аеруча җанланып китте. Партизан отрядыбыз көннән-көн йөзләгән кадрлар белән тулылана килә.*

*Без фашистларны көннәр һәм төннәр буенча кыра бирәбез, кая керер урыннарын таба алмыйлар, алар хисабына коралланабыз, туенабыз һәм киенәбез. Ләкин хатын-кыз һәм бала-чагаларны бик күп үтерәләр, яндыралар. Без юк урынга барып чыгып, авылларны барлык халкы белән утта яндыралар... Партизан исеме аларның йөрәкләренә инә урынына кадала...*

*Шулай без көрәштә көннән-көн чыныга килабез. Тәҗрибә арта, условиелар яхшыра.*

*Ярый, хуш, сау булыгыз. Без хәзергә Украинаның Сумская областенда. Барыгызга да яхшыдан яхшы теләк теләп калам. Тигез яшәгез, һәм нык ышаныгыз: дошман якын киләчәктә безнең җиребездән үзенең соңгы сөякләрен алып качар. Шул чагында без дә ерак тылдан үзебезнең туган Кызыл Армиябезнең кулын кысарбыз. Картлар да, хатын-кызлар да, бала-чагалар да — бар да безгә булышалар.*

*Тирән дошман тылында сезне сагынып кулыгызны кысучы улыгыз—партизан Морат. Хушыгыз. 2.V 42 ел.»*

*С. Алишев*

# ПУГАЧЕВ ПОЛКОВНИГЫ

## I

Казан ханлыгы бетерелгәч, татар халкы ике төп категориягә бүленеп калган: аларның берсен «ясаклы», икенчеләрен «йомышлы татарлар» дип йөрткәннәр.

Казан ханлыгында ясак түләүчеләр, Казан яулап алынгач, Мәскәү патшаларына ясак түли башлаганнар. Петр I ясак түләүне җан башыннан салым түләү белән алыштырганнан соң да, аларны барыбер «ясаклы татарлар» дип йөрткәннәр.

Йомышлы татарлар исә (элекке морзалар, хәрби кешеләр) патша хөкүмәтенә хәрби, дипломатик һ. б. төрле хезмәт күрсәтергә тиеш булганнар. XVI гасырның икенче яртысында һәм XVII йөздә алар рус дәүләтенең көнчыгыш чикләрен саклауда, күчмә халыкларны бастырып тотуда, крепостьлар салуда һ. б. хезмәтләрдә файдаланылганнар. Бу хезмәтләре өчен аларга җир участоклары бүләк итеп бирелгән. Алар арасыннан кайбер морзалар зур җир участоклары биләгәннәр һәм рус алпавытлары кебек крепостник булганнар. Ләкин «йомышлы татарлар»ның күпчелеге XVII гасырда да гади крестьян сыйфатында яшәгән. XVIII гасырда исә хәл бөтенләй үзгәргән. Билгеле булганча, патша хөкүмәте, Казанны яулап алгач ук, татарларны көчләп чукындыру, руссификаторлык политикасы үткәрә башлаган. Ә 1713 елда исә Петр I: «Йомышлы татарлар» ярты ел эчендә чукынып бетсеннәр, чукынмасалар, алардан крестьяннарын алырга», дип указ чыгарган. Бу указны тормышка ашыру нәтиҗәсендә, кайбер морзалар чукынып, рус дворяннары составына кереп калганнар. Ә күбесе исә, крепостнойларсыз калып, җирләрен сатып, сәүдәгәр яки гади крестьян булып әверелгәннәр. Аларны халык «чабаталы морзалар» дип тә йөрткән. Шулай итеп «йомышлы татарлар»ның иң зур күпчелеге дәүләт крестьяннарына әйләнгәннәр. Петр I хөкүмәте йомышлы татарларның хәрби хезмәтенә инде мохтаҗ булмаган, чөнки дәүләт чикләре көнчыгышка таба ераклашкан булган. Әнә шул йомышлы татарларны 1718 елда Казан адмиралтействосына корабльләр төзү өчен урман кисү эшенә беркеткәннәр.

Казан адмиралтействосы, Петр I указы буенча, шул ук 1718 елда Казанка елгасы буенда, Елан тавы монастыре һәм Бишбалта бистәсе территориясендә (хәзерге Киров районы) төзелгән. Адмиралтейство Идел һәм Каспий флотилияләре өчен корабльләр төзү һәм корабль урманнарында агач әзерләү белән шөгыльләнгән.

Иң авыры, әлбәттә, әнә шул корабль урманнарында йөз еллык имән һәм наратларны егу, чистарту, су юлларына тарттыру, сал агызу эшләре булган. Шул эшләргә беркетелгән татарлар XVIII йөз документларында «корабль урманы эшләренә» яки «адмиралтействога беркетелгән татарлар», һәм искечә «йомышлы татарлар», дип тә йөртелгәннәр. Ә XIX гасырда аларга инде «лашманнар»[1] дигән исем тагылган.

Лашман итеп 15 яшьтән 60 яшькә кадәр булган кешеләрне көз көне 6 айга, кирәк булса, бер елга эшкә куганнар. 6 айга алган вакытта,

[1] Лашман — урман эшчесе (немсәчә)

чират тәртибендә, 9 кешедән бер атлы, бер җәяүле крестьян; бер елга булганда, 25 кешедән бер атлы, 2 җәяүле кеше алынган.

1718 елдан 1728 елга кадәрге беренче 10 елда ел саен уртача 6 айлык срокта 2182 атлы һәм 1863 җәяүле кеше, ә еллык срокта 27 атлы 82 җәяүле эшләгән. XVIII гасыр ахырына урманнарда эшләүчеләрнең саны өчләтә арткан.

Казанның татар бистәләрендә яшәүче татарлар да (шәһәрнең үзендә яшәргә ул вакытта татарларга рөхсәт ителмәгән) барлыгысы 1133 ир кеше адмиралтействога лашман хезмәтенә беркетелгән булганнар. Лашман булып беркетелгән татарларның саны XVIII йөз буена үсә барган. Әгәр 1719 елда аларның саны 23750 ир кеше булса, 1794 елда бу сан 112 337 гә җиткән.

Беренче вакыт алар урман кискән өчен бер тиен алмыйча эшләгәннәр. Соңрак аларга көнлекләп атлыга 10 тиен, җәяүлегә 5 тиен акча түли башлаганнар. Ләкин бу акча үзләрен һәм атларын туйдыруга да җитми торган булган.

Ясаклы татарлар белән беррәттән, лашманнар җан башыннан налог та, башка күп төрле салымнар да (мунча өчен, өйләнгән өчен һ. б.) түләгәннәр, рекрут биргәннәр. Патша хөкүмәтенең мондый милли-колониаль изү политикасына каршы татар крестьяннары төрлечә көрәш алып барганнар. Лашманнарның каторга хезмәте турында халык арасында бәетләр таралган. Алар үзләренең авыр язмышларыннан зарланып, гасырлар буена бу эштән коткаруны ялварып патшаларга үтенечләр язганнар. Ләкин аларның берсе дә һичнинди уңай нәтиҗә бирмәгән.

Лашманчылар күп мәртәбәләр баш күтәрәләр, качып китүләр, чиновник-күзәтүчеләрне үтерүләр дә еш булып тора.

* * *

...1773 елның ноябрь ае. Менә бер төркем татар крестьяннары Шәмәрдән урманы эчендә зур нарат һәм имән агачларын егалар. Алар янына Казан адмиралтействосы конторасыннан комиссар Наумов килгән. Ул эшләүчеләрне тизләтә, кирәк тапса, камчылый да. Менә кинәт кенә алар янына урман юлыннан бер төркем атлылар килеп чыга. Атлы отрядның җитәкчесе әле 30 яшькә дә җитмәгән таза ир Габделфаик Госманов, җикеренеп торган Наумовка күрсәтеп: «Тотып бәйләгез шуны», — дип, иптәшләренә әмер бирә.

Күз ачып йомганчы урмандагы барлык крестьян-лашманнар бу төркем янына җыелып өлгерәләр. Габделфаик Госманов аларга: «Мин патша хәзрәтләре император Петр Федоровичның полковнигы Мәсәгуть Гомәров тарафыннан җибәрелдем. Аның әмере буенча, сезне бу җәфалардан коткарам», — дип мөрәҗәгать итә. Тирәсендәге кешеләр: «Без Оренбург янында патша Петр Федоровичның килеп чыгуын күптән ишеткән идек, аның кешеләрен көтәбез. Ул халыкка ирек, җир-су бирәм дип әйтә икән, дөресме шул?» — дип, шау-гөр килеп, сорашырга керешәләр.

Госманов өелгән утын әрдәнәсенә менеп баса да: «Туганнар! Мин сезгә патша император Петр Федоровичның безгә җибәргән хатын укыйм, тынычланыгыз!» — ди һәм көчле тавыш белән укый башлый:

«Мин, бөек государь, патшалар патшасы вә данлыклы император Петр Федорович, үземнең турылыклы подданныйларыма бу указымны игълан итәм.

...Сезнең борынгы буыннарыгыз, бабаларыгыз һәм аталарыгыз минем бабам батыр государь Петр Алексеевичка хезмәт иткән кебек миңа хезмәт итегез; аларны минем бабам хөрмәт иткән кебек, мин дә сезне киләчәктә дә хөрмәт итәрмен. Һәм сезне җир-су, тоз, догалары-

гыз һәм диңгез белән, мөлкәт вә акча жалованиесе белән бүләклим; аның өчен сез мина үлгәнчегә кадәр хезмәт итәргә тиешсез...

Кем буйсынмый һәм каршы килә — бояр, генерал, майор, капитан — аның башын кисегез, байлыгын тартып алыгыз...

Бер вакыт алар сезне, минем колларымны, ашадылар вә коллыкта тоттылар, үз кешеләремне җәлләп, тулган айга, якты йолдызга охшап, хәзер мин тудым... Кем бояр колы, кем залимнар кулында крестьянлыкта тора — хәзерендә азат итәлә, кемнәр төрмәгә ябылган — барысы да чыгарыла»[1].

Е. И. Пугачев манифесты белән танышкан лашманнарның бер өлеше Госманов отрядына кушыла, ә икенче өлеше, Тәтеш ягыннан килгән 31 крестьян, без үз авылларыбызга кайтабыз, анда да восстание күтәрергә кирәк бит, дип кайтып китәләр. Патша ялчысы Наумовны һәм аның ярдәмчеләрен Пугачев полковникы Мәсәгуть Гомәров карамагына җибәрәләр, ә ул аларны, Уфа шәһәрен камап торучы Пугачев полководецы «граф Чернышев» — Чика-Зарубин карамагына, күрсәтмәләр ала баручы восстаниечеләр күзәтүе астында, хөкемгә җибәрә[2].

Шундый ук кузгалышлар башка урман участокларында һәм авылларга җәелеп китә. Баш күтәрүчеләрнең бер отряды Кариле авылында Наумовның Казаннан килгән хатынын кулга төшерә һәм ул түбәндәге «билет» белән Казанга озаттырыла:

«Армиядән старшина итеп билгеләнгән Субай Солтанов, Кимей Смайлов вә гайре иптәшләре тотылган урман комиссары хатынын вә аның янындагы ике хатынны азат иттек, аларны үткәреп җибәргәйсезләр, Казанга кадәр алмашлап 3 олау белән озаткайсызлар; әмма ләкин, кем каршы килсә, ул хатыннарны үзендә тотар, үзенеке белән ашатыр вә эчертер.

Инанмак өчен мин старшина Субай Солтанов кулым куйдым»[3]. Бу хатыннарны чыннан да, бер авылдан икенче авылга алмашлап, крестьяннар Казан стеналарына кадәр озаталар. Димәк, восстаниечеләрнең власте Казан шәһәре янына кадәр үк таралган була.

Түбән Читай авылы крестьяны старшина Әпсәләм җитәкчелегендәге бер отряд прапорщик Иван Федоров командасын коралсызландыра һәм, лашманнарны урман эшеннән коткарып, Балтач — Малмыж араларында хәрәкәт итә башлый.

Ә икенче бер отряд Иске Мичән авылында эксплуататор Үтәгәновны тотып, Куршино авылында торучы полковник Мәсәгуть Гомәров хөкеменә алып килә.

Курса, Төрнәле, Олыяз, Тимерлик, Әшнәк, Чапшар, Норма, Сасмак һ. б. бик күп авылларда да крестьян отрядлары оеша.

Бу отрядлар белән Пугачев үзе яки аның ярдәмчеләре тарафыннан билгеләнгән яисә баш күтәрүчеләрнең үзләре тарафыннан сайланып куелган полковниклар, старшиналар, сотниклар җитәкчелек итәләр.

* * *

Билгеле булганча, Дон казагы Емельян Иванович Пугачев, үзен император Петр Федорович итеп танытып, Җаек казаклары арасында 1773 елның сентябрендә күтәрелеп чыга. Бу күтәрелеш тиздән крестьяннар сугышына әйләнеп китә. Октябрь аенда инде татар крестьяннары да берләшеп, бу сугышка кушылалар һәм бу отрядлар арасында 1773 елның ноябрь аенда оешкан Мәсәгуть Гомәров отряды зур игътибарга лаеклы.

[1] БАУДА (Борынгы актлар үзәк дәүләт архивы), фонд 6, оп. I, сак. бер. 416, II бүл., 327 бит.

[2] ХДФУДА (Хәрби диңгез флоты үзәк дәүләт архивы), фонд 212, сак. бер. 430, 36—40 битләр.

[3] ХДФУДА, фонд 212, сак. бер. 430, II бүл., 42 бит.

Мәсәгуть Гомәров Кукмарадан 7—8 чакрымдагы Псәк авылында Гомәр Әширов семьясында 1746 елда туган, яшьтән үк лашман эшендә җәфа чигеп, феодаль изелүнең бөтен ачысын татыган. Крестьяннар сугышы башлангач, Мәсәгуть Гомәров, беренчеләрдән булып, азатлык өчен көрәш юлына баса. Сугыш барышында ул үзен талантлы оештыручы, крестьяннарның кыю җитәкчесе итеп таныта. Бөтенләе белән үзен азатлык өчен көрәшкә багышлаган Гомәров крестьяннар сугышы лозунгларын тормышка ашыру өчен көрәштәш иптәшләрен дә дәртләндерә белә.

Мәсәгуть Гомәров, иң элек, үзендә татар һәм рус телләрендә язылган Пугачев манифестларын булдыра. Аларның копияләрен тарата, үзе булган авылларда крестьяннарга укый. Без югарыда күрсәтеп үткән отрядлар Пугачев указларын анардан алган булсалар кирәк. Крестьяннар аны һәр җирдә олылыйлар, аш-су, икмәк-тоз белән каршы алалар һәм җир, азатлык турындагы манифестларны йотлыгып тыңлыйлар, аның отрядына күпләп кушылалар. Ләкин патша гаскәрләре белән сугышырга корал җитми. Мәсәгуть Гомәров, үз отрядын коралландыру өчен, заводларга йөри башлый. Иң элек ул, Осокинның Бемыш заводына килеп (Татарстан һәм Удмуртия чигендә), 3 туп, берничә мылтык һәм дары, 15 ләп ат кулга төшерә, заводта интегүче күп кенә эшчеләрне азат итә. Мәсәгутьнең исеме халык арасында киң тарала, үзеннән күп алда йөри. Бемыш заводыннан Гомәров Кобелевларның Пижман заводына юнәлә. Завод эшчеләре делегациясе аны, 20 чакрым ераклыктагы Кизнәр авылына килеп, икмәк-тоз белән каршы алалар. 1773 елның 2 декабрендә М. Гомәров бу делегациягә: «Завод император Петр Федорович хәзрәтләренә баш иде, эшче кешеләр аның хезмәтенә әзер торалар», дип билет бирә[1]. Пижманда ул 7 туп, күп кенә мылтыклар һәм атлар кулга төшерә, заводка беркетелгән рус крестьяннарын азат итә; теләгәннәрне һәм коралы булганнары (барлыгы 25 кеше) аның отрядына кушыла.

Бу заводтан китеп, Гомәров отряды рус, татар, удмурт авылларында, крестьяннарны восстаниегә күтәреп, изүчеләрне җавапка, кирәк була икән, җәзага тартып йөри. Кулыги, Куршино, Вятские Поляны, Сасмак, Тойма һ. б. авылларда була, аннары Туеш заводына (Кукмарадан ерак түгел) юнәлә. Аның отряды бу вакытта зурайган, аның үзенә инде полковник исеме бирелгән була.

Барлык авылларда да крестьяннарның Пугачев ягында патша гаскәрләренә каршы сугышка катнашырга зур теләкләрен һәм аларның изүчеләрне юк итә башлаганлыкларын күреп, үз кул астындагы отряд 1000 кешегә якынайгач, ул үзенә ярдәмчеләр итеп старшиналар һәм сотниклар билгеләп, аларга Пугачев манифесты копияләрен биреп, төрле якка чыгарып җибәрә. Старшина Назиров (Чапшар авылы крестьяны) Балтач тирәсендәге авылларга, Казандагы III батальоннан качкан солдат Әбдерәшит Бикеев Арча тирәсендәге авылларга, Салавыч авылы крестьяны Әбдүш Уразаев Питрәч ягына, Сасмак авылы крестьяны Гали Назиров һәм башкалар, 10 ар кешелек кечкенә отрядлар белән, төрле якка җибәрелә. Пугачев манифестын тыңлаган крестьяннар, төркем-төркем булып, бу отрядларга кушылалар. Гомәровтан алдарак Иноземцевларның Туеш заводына килгәндә патша гаскәрләренә әсир төшкән 9 кеше допроста баш күтәрүчеләр турында болай дип күрсәткәннәр: «...Заводка Гомәровтан команда килде һәм алар 4 пушка, 6 мылтык алдылар, самозванецтан указ һәм аларның башлыгы Гомәровтан боерык укыдылар... Эшче кешеләрдән барлыгы 50 кеше восстаниечеләр гаскәренә кушылды... һәм аларны Мәсгуть Назиров, Абдул Абдразяков командаларына бирделәр... Назировның ту-

[1] БАУДА, фонд 6, оп. 1, сак. бер. 467, X бүл., I кисәк, 155 бит.

ган авылы Чапшарга килгәч, Петр Федорович хезмәтенә бик күп татар алынды. Шул ук көнне татар авылы Соснага киттек»[1].

Әбдерәшит Бикеев допроста Мәсәгуть Гомәров тарафыннан татар һәм удмурт «авылларына указлар укырга һәм... патша хезмәтенә озату өчен кешеләр җыярга» җибәрелгәнлеген әйткән һәм: «Гумеров миңа, юлга чыгар алдыннан, син үзеңне унтер-офицер дип ата, кешеләр, шулай дигәч, сиңа күбрәк ышанырлар, дип әйтте», дигән[2].

1773 елның декабрь аенда Кама алды бөтенләе белән восстаниечеләр кулында була. Исән калган алпавытлар авыллардан гына түгел, Казанның үзеннән дә качып китеп бетәләр. Губернатор үз семьясын Казаннан Козьмадемьянскига илтеп куя. Чиновниклар яки кечкенә гаскәри командалар юлларда йөри алмыйлар, урыннарда крестьяннарның үз властьлары урнаша. Мәсәгуть Гомәров власте Мамадыштан Малмыжга, Малмыждан Казанга һәм Казаннан Мамадышкача булган территорияне үз эченә ала.

Гомәровка буйсынган отрядларның составы күп милләтле була. Руслар, татарлар, удмуртлар һ. б. милләт вәкилләре бер үк отрядта кулга кул тотынышып көрәш алып баралар. Әгәр отряд зураеп китсә, алар бер отряд эчендә рус, татар, удмурт сотняларына бүленгәннәр һәм житәкчеләре итеп үз араларыннан башлыклар сайлап куйганнар. Шундый сотниклардан рус крестьяны Иван Андреевны (кушаматы «Бабушкин»), удмурт Семен Ивановны, татар Аккулай Пулатовны һ. б. күрсәтергә мөмкин.

Милләтләр арасында дуслык, сыйнфый теләктәшлекне түбәндәге фактлардан да күрергә мөмкин. Мәсәгуть Гомәров янына алпавыт Свеинның крепостной крестьяны Артамонов килгәч, полковник аннардан: «Син нинди кеше?» дип сорый. Артамонов үзенең крепостной крестьян икәнен әйткәч, Гомәров: «Безгә шундый кешеләр кирәк тә!» дип[3], кешеләрне милләте буенча түгел, ә бәлки сыйнфый яктан гына аерганын белгерткән. Гомәровның рус крестьяннары белән бер булып көрәш алып баруын аның хатыны Мәрфуга Исмәгыйлова күрсәтүеннән дә аңлап була: «Минем ирем бер мәртәбә 20 ләп татар һәм рус белән кайткан иде, ләкин сөйләшергә вакытыбыз булмады. Соңыннан күршеләр, ул Пугачев партиясенең полковнигы, дип әйттеләр»[4], ди ул допроста.

Пугачевчылар да, аларның дошманнары да моны ачык раслыйлар. Мәсәлән, Казан адмиралтействосы балта остасы Иван Костылев: «Алар Минзәлә һәм Уфа өязе старшиналары һәм И. Н. Чернышев (чын фамилиясе Зарубин, кушаматы Чика. — С. А.) белән хат языштылар. Хатлар алгач, Мәсәгуть Гомәров, сотник Аккулай Пулатов, удмурт сотник Семен Иванов киңәшмә ясый иделәр»[5], дип күрсәтә.

Бу шаһитнең күрсәтүе, икенче яктан, баш күтәргән крестьяннар һәм аларның сугыш хәрәкәтләре белән житәкчелекнең ничек алып барылганын да ачыклый. Бу зур территориядә, Оренбург һәм Казан губерналарында, җәелгән сугыш хәрәкәтләре белән восстаниечеләрнең ике штабы — Оренбург янында Пугачев житәкчелегендәге — Берда һәм Уфа янында Чика-Зарубин житәкчелегендәге Чесноковка штаблары — житәкчелек итә. Аерым районнарда төрле отрядларның башлыклары шул штабларның күрсәтмәләрен тормышка ашыралар. Мәсәгуть Гомәров та, шулай ук Татарстанның башка районнарында хәрәкәт иткән башлыклар: Каранай Моратов, Муса Мостафин, Енгалычев, Әбҗәлил Сөләйманов, Юскәй Кулашев һ. б. бик күпләр дә шул штаблар белән элемтә тотып эш итәләр. Мәсәлән, шул күрсәтмәләр нигезендә, Гомәров

[1] БАУДА, фонд 6, оп. 1, сак. бер. 467, X бүл., 1 кисәк, 149—150 битләр.
[2] БАУДА, фонд 349, оп. 1, сак. бер. 7410, 2 кисәк, 21 бит.
[3] БАУДА, фонд 6 оп. 1, сак. бер. 467, 1 бүл., 4 кисәк, 304 бит.
[4] БАУДА, фонд 349, оп. 1, сак. бер. 7410, 2 бүл., 23 бит.
[5] Пугачевщина. Т. II, 437 бит.

Минзәләне алыр өчен Каранай Моратовка сотник Гали Кадыйров җитәкчелегендә 1 500 кеше һәм туплар, Алабуганы алыр өчен Шәрип Якуповка 250 кешелек Мухай Сәгыйтов отрядын җибәрә. Бакырчы авылы ясаклы крестьяннарының күрсәтүләре буенча, «Гомәров явызларга[1] ярдәмгә алар кебекләрне хисапсыз күп җибәрде»[2]. Мондый фактлар Гомәровның крестьяннарның көчләрен бергә тупларга тырышканлыгын, сугышның җирле (локаль) характерын бетерергә омтылганын раслыйлар.

Январь башында, отряды 3 мең кешегә җиткәч, Гомәров Казанга таба һөҗүм башларга ниятли һәм походка әзерләнергә керешә. Шул ук Иван Костылев болай дип күрсәтә: «Гомәров гаскәре... Арчаны алып, шунда явызның (Пугачевның — С. А.) Оренбург янындагы төп көчләреннән ярдәм килгәнне көтәргә, аннан соң Казанга поход ясарга дип юлга чыккан иде»[3].

Пугачев әле ерактa, Оренбургны камап торган вакытта ук Гомәровның үз инициативасы белән уйланылган бу бик кыю план Казан өязендә крестьяннар восстаниесенең бик җитди һәм зур көчкә ия булганлыгын күрсәтә; ул властьларны зур куркуга төшерә. Казанга килгән хөкүмәт гаскәрләре баш командующие генерал-аншеф А. И. Бибиков: «Бөгелмәгә үтеп булмый һәм безнең өскә киләләр», дип яза. Әмма Гомәровның бу кыю планы тормышка ашмый кала. Хөкүмәт гаскәрләренең зур һөҗүме башланган вакытта ул, югарыда әйтелгәнчә, үз отрядының бер өлешен Минзәләне һәм Алабуганы алу өчен җибәрә, бер өлеше белән Камышлы авылында оборона оештыра, ә ана буйсынган һәм аның кешеләре тарафыннан оештырылган отрядлар төрле җиргә таралган, тупланмаган хәлдә булалар.

Шөн авылы крестьяннары Әхмәр Ишменев һәм Гали Галиев яшерен комиссия допросында болай дип күрсәтәләр: «Безне Камышлыга алып килделәр, анда 1700 кеше бар иде. Алардан күбесе Казаннан килү юлларын бикләү өчен засекалар ясау эшенә беркетелделәр. Бер төркемне авыл тирәсендәге карны таптарга җибәрделәр»[4].

Гомәров, бүтән башлыклардан да шундый ук оборона чараларын үтәүне таләп итеп, Әбдүш Уразаевка: «Урман юлларына агачлар аударыгыз»[5], дип язган. Крестьяннарның хәрби эшне белмәүләре һәм кораллары бик аз булуы нәтиҗәсендә, Мәсәгуть Гомәров табигый шартлардан киң файдалануны шарт итеп куя.

Баш күтәрүчеләр сыйнфый дошманнары белән исәп-хисапларын өзүне дәвам иттерәләр. Отставкадагы губерна секретаре алпавыт А. Афанасьевның Вознесенское авылы (Арча юлы буенча Казаннан 80 чакрымда) крепостной крестьяннары яшерен комиссиядә түбәндәгечә сөйләгәннәр: «1774 елның 4 январенда иртә белән авылга рус булмаган 8 казак җитәкчелегендә бик зур төркем татарлар килде... Алар арасында Мөрәле, Поник, Чапшар, Кормалы, Көек, Норма, Кили, Ташкичү һәм Ерак Сиза авылы татарлары да бар иде.

Килеп җитүгә, алар туп-туры алпавыт йортына кереп киттеләр, ә алпавыт шул көнне кичен генә Ташкичү һәм Ерак Сиза авыллары аша Казаннан кайткан иде. Алпавытны кыйнап ташладылар, өен таладылар, атларны һәм үзен алып киттеләр. «Аны кая алып барасыз», дип сорауга: «Кукмарага (Асәф Иноземцевның бакыр эретү заводына), анда безнең башлыгыбыз Гомәров тора», дип җавап бирделәр»[6].

---

[1] Восстаниечеләрне дошман лагере кешеләре һәм допрос алучылар «явызлар», «разбойниклар» дип атаганнар һәм язганнар.
[2] БАУДА, фонд 349, оп. 1, сак. бер. 7410, 2 бүл., 22 бит.
[3] Пугачевщина. Т. II, 427 бит.
[4] БАУДА, фонд 349, оп. 1, сак. бер. 7410, 2 бүл., 24 бит.
[5] БАУДА, фонд 6, оп. 1, сак. бер. 467, X бүл., 1 кисәк, 147 бит.
[6] БАУДА, фонд 6, оп. 1, сак. бер. 507, 1 бүл., 97 бит.

Христиан динен көчләп тагучы поп-миссионерларны да шундый язмыш көткән. Керәшен авыллары барысы да диярлек үзләренең попларын кырып бетергәннәр. Баш күтәрүчеләр властен танымаган муллалар шулай ук юк ителгән.

Декабрь аенда хөкүмәт гаскәрләренең баш күтәрүчеләргә каршы икенче зур һөҗүме башлана. Бу гаскәрләр Татарстан территориясе аркылы Оренбург ягына Пугачевка каршы юнәләләр, ләкин аларга восстаниечө отрядларның нык каршылыгын ерып үтәргә туры килә. Восстаниечеләр күрсәткән каршылык хөкүмәт гаскәрләрен ялыктыра, аларның көчләрен зәгыйфьләндерә, бу исә баш күтәрүчеләрнең төп көчләренә зур ярдәм була.

Беренче удар Гомәров отрядларына төшә. Бу отрядлар хәрәкәт иткән территориягә беренче булып полковник Хорват командасы гусарлары январь аенда бәреп керәләр. Алар Казаннан җибәрелгән капитан Кардашевский гусарлары белән бергә һөҗүм итәләр. Хорват генерал Галицынга язган рапортында: «Кариле авылына килдем, минә капитан Кардашевский татарлар тарафыннан тотылган 27 явызны һәм үзе тоткан 11 кешене китерде. Алар бу яктагы разбойниклар, начальнигы Мәсәгуть Гомәров шайкасыннан икән. Юлда барганда, Кардашевский купец Иноземцев заводы мужикларының явыз яклы икәнлекләрен күреп, бик каты җәзалаган»[1].

Гомәров отрядлары, бу вакытта бер урынга тупланмаган булганлыктан, туплар һәм мылтык залпларына каршылык күрсәтә алмыйча, җиңеләләр. Назиров, Ә. Бикеев, Әбдүш Уразаев һ. б. кайбер отряд командирлары белән күп кенә крестьяннар әсир төшәләр. Аларның җиңелүендә авыл байлары һәм куштаннары да шактый роль уйнаган... «Кариле, Югары Читай, Балтач байлары, киңәшмәгә дигән булып, Абдул Абдразяковны, Ибрай Бакировны, Әбдерәшит Үтәгәновны һәм башкаларны берәмләп чакырып алдылар да тотып бәйләделәр»[2], дип күрсәткән сорау алу вакытында кайбер әсирләр. Полковник Хорват: «Ул разбойник семьясын кызганып килеп бирелмәсме»[3], — дип, Псәк авылына килеп, Мәсәгутьнең 80 яшьлек әтисе Гомәр Әшировны, хатыны Мәрфуга Исмәгыйлованы, 55 яшьлек туганы Максудны кулга ала һәм, башка әсир крестьяннар белән бергә, барысын бер арканга тезеп бәйләп, Казанга, пугачевчылар эшен тикшерүче яшерен комиссиягә озаттыра. «Башкаларга сабак булсын», дип, Назировны Норма авылында тирә-як халкын җыйнап астыра; гусарлар крестьяннарны рәткә тезеп, яткырып камчы белән аңнарын югалтканчы кыйныйлар.

Озакламый Казанда яшерен комиссия гомәровчылар эше буенча карар чыгара: гади баш күтәрүчеләрне «халык алдында камчы белән аяусыз суктырырга һәм губерния канцеляриясенә казенный эшкә җибәрергә», ә Әбдерәшит Бикеевны «ул Гомәровка 1500 кеше җыеп алып килергә вәгъдә иткән өчен ...Арча кырында асарга, гәүдәсен ике атна буена дар агачыннан алмаска... Губернаторга Арча кырында дар агачы; чыбыркы һәм камчы белән кыйнау өчен баганалар куюны йөкләргә»[4].

Әбдерәшит Бикеев — Казанда пугачевчылардан беренче асылып үтерелгән кеше. Аннан соң инде Арча кырындагы дар агачларында кыш буе патша палачлары тарафыннан асылган гәүдәләр, җилдә шак-шок килеп, бер-берсенә бәрелешеп торалар.

Мәсәгутьнең әтисе яшерен комиссиядә үзен хәлсез, бернәрсә белми торган һәм саңгырау карт итеп тота, сорауларга җавап бирми. Аны азат итәргә мәҗбүр булалар. Мәсәгутьнең хатыны белән абыйсыннан да юньләп җавап ала алмыйлар. Аларны төрмәдә калдыралар.

---

[1] БАУДА, фонд 6, оп. 1, сак. бер. 467, X бүл., 1 кисәк, 139 бит.
[2] Шунда ук, 148 бит.
[3] Шунда ук, 139 бит.
[4] Шунда ук, VIII бүл., II кис. 133—140 битләр.

Камышлы авылындагы восстаниечеләр лагере һөҗүм итеп килүче хөкүмәт гаскәрләренә каршы тора алмагач, крестьяннарның бер өлеше, Мәсәгуть Гомәров җитәкчелегендә, Вятка елгасының аръягына чигенә, күп өлеше таралып бетә, ә кайберләре әсир төшә.

Мәсәгуть инде семьясы турында ишеткән. Менә ул Вятканың аръяк ярында, ак аргамакка атланган килеш, дворяннар оясы булган Казан ягына нәфрәт белән карап, тирән уйга чумган. Нәрсә эшләргә? Кан эчкеч алпавытларга каршы һөҗүм итеп барыргамы, я булмаса, «семьямны җибәрегез, алар гаепсез, менә мин үзем килдем», дип дошманга бирелергәме?

Һөҗүм итү өчен көчләр тигез түгел: алпавытлар хөкүмәте гаскәрләре баштанаяк коралланган һәм өйрәтелгән, туплары күп. Ә баш күтәрүчеләрнең нәрсәләре бар?.. Кешеләре күп, ләкин коралсыз, туплардан түгел, мылтыклардан ата белүчеләр дә сирәк... Шулай да көрәш эле дәвам итә. Юк, бирелергә ярамый... Һәм ул башын күтәрә, камчысы белән Казанга таба селкеп: «Килербез әле без сезне туздырырга, халык канын эчеп симерүчеләр, үзебезнең патшабыз белән килербез!» — ди.

Мәсәгуть Гомәров Пугачев янына барырга, аңа кушылып восстаниечеләрнең төп көчләре сафында көрәшне дәвам иттерергә карар бирә. Ул, сотник Пулатовны зур булмаган отряд белән Минзәлә янында торучы Каранай Моратов һәм Сянфин карамагына җибәреп, үзе берничә иптәше белән Нагайбәк аша Пугачев янына юнәлә. Ләкин Нагайбәк крепостенда (Татарстан белән Башкортстан чигендә, Ык суы буенда) Вәлит Торнов[1] аны үзендә калырга күндерә. Пугачев яныннан кайткан Торнов: «Падишаһ хәзрәтләре Петр Федорович: «Барлык булган көчегез белән дошманны Оренбург ягына җибәрмәс өчен көрәшегез», дип әйтте. Озакламый үзе дә бу якка таба килергә тиеш», ди. Гомәров февраль-март айларында һөҗүм итеп килүче хөкүмәт гаскәрләренә каршы көчле сугышларда В. Торнов отряды сафларында полковник дәрәҗәсендә батырларча сугыша.

Аның әтисе Гомәр Әширов, Казан төрмәсеннән кайткач, карт булуына карамастан, улының дөрес юлдан китүен хуплап, аның урынына баса һәм тирә-як авылларда пугачевчыларның актив агитаторы булып китә, восстаниенең төп лозунгларын яклап, крестьяннарны көрәшкә өндәп йөри. Аның турында властьлар яклы булган татар сотнигы:

«Халыкны котыртып йөри башлады. Явызлар шайкасындагы малае Мәсәгуть кайтмыйча, җан башыннан салымны түләмәскә, рекрут бирмәскә кирәк, дип сөйләп йөри. Аның, Гомәрнең, шулай котыртулары аркасында, безнең сотняның барча кешеләре азгынландылар, тынламый башладылар», дип губерна канцеляриясенә язган. Гомәр Әшировны апрель аенда икенче мәртәбә кулга алып, яшерен комиссиягә китерәләр. Икенче сорау алу вакытында Гомәр картның саңгырау да, зәгыйфь тә түгеллеге ачыла. Ул үзен газаплаучы сорау алучылар белән ватып-җимереп булса да русча әйткәләшә, эксплуататор сотникларны, байларны, власть кешеләрен гаепли[2].

Гомәр картның да, Мәсәгутьнең хатыны Мәрфуга Исмәгыйлованың һәм туганы Максудның да шуннан соңгы язмышлары турында билгесез. Бу турыда документлар сакланмаган. Мөгаен, төрмәдә җәзаланып үтерелгәннәрдер. Мәсәгуть үзе март аенда Бишкураз авылы янында хыянәтче башкорт старшинасы Кидрач Муллакаев отряды тарафыннан кулга алына, кулы-аягы бәйләнеп, Уфага озатыла.

---

[1] В. Торнов, күренекле пугачевчылардан берсе булып, Пугачев белән бергә 1775 елның 10 гыйнварында Мәскәүдә җәзаланып үтерелә.

[2] БАУДА, фонд 6, оп 1, сак. бер. 467, VIII (1), 138 бит.

Март восстаниечеләр өчен авыр ай була: 22 мартта Татищево крепостенда Пугачевның төп көчләре, 24 мартта Уфа янында Чика-Зарубин тар-мар ителәләр. Сугышның беренче чоры шулай тәмамлана. Ләкин баш күтәрүчеләр корал ташламыйлар. Башкортстан һәм Татарстан территориясендә, Идел буенда сугыш киң колач ала. Әмма Мәсәгуть Гомәров сугышның бу чорын, Пугачевның Казанга походын һәм аны алуын, туган-үскән җирләрендә крестьяннарның Пугачевны ничек шатланып каршы алуларын, ана кушылуларын күрә алмый. Аны 1774 елның сентябрь аена кадәр Уфа төрмәсендә тотып, яшерен комиссиянең таләбе буенча, башка күренекле 11 пугачевчы белән, көчле каравыл астында, Бөгелмә аша Казанга озаталар. Бөгелмәдә полковник Кожин, арканланган һәм аяк-куллары богауда булган бу восстаниечеләрне крестьяннарның азат итүеннән куркып, конвойны тагын да көчәйтә. Казанда палачлар алардан кабат сорау алалар. Ләкин Мәсәгуть ахырынача нык тора, сыйнфый дошманнарның үч алуларын батырларча кичерә. Ул иң әһәмиятле, мөһим фактларны юкка чыгара, үзен дә, башкаларны да патша палачлары алдында аз гаепле итеп күрсәтә. Татар халкы алдында властьлар, барлык тикшерү эшләре законлы рәвештә бара дигән тәс тудыру өчен, аның гаебен, киресенчә, күпертеп күрсәтергә тырышалар: 46 шаһиттән аның турында таныклык алалар. Шунысы кызыклы: Башкорт халкы герое Салават Юлаев та соңрак сорау алулар вакытында үзен нәкъ менә шулай тота, үзенең «гаепләрен» танымый, алардан ваз кичә. Ул гына да түгел, «хөкем карары» буенча, аларга бирелгән җәзалар да бер үк төстә. Мәсәгуть Гомәровны да ул восстание башлаган урыннарда чыбыркы белән суктыралар (Псәк авылында 150 мәртәбә), аннан соң палач аның уң як яңагына Б (бунтовщик), сул як яңагына И (изменник), маңгаена З (злодей) литерларын кызган тимер белән тамга итеп баса. Яшерен комиссия, татар халкы алдында «шәфкатьлелек» күрсәтүенә басым ясап, үзенең хөкемендә болай дип белдерә: Мәсәгуть Гомәровны «үлем җәзасына хөкем ителергә тиешле булса да, императрица хәзрәтләре Екатерина II нең мәрхәмәтлегеннән чыгып» югарыда күрсәтелгән җәзаларга тартырга һәм «мәңгелек вакытка иң авыр каторга эшләренә җибәрергә» [1].

М. Гомәровның каторгага кая җибәрелүе һәм аның соңгы көннәрен кайда үткәрүе хәзергә билгесез. Бәлки киләчәктәге эзләнүләр бу мәсьәләне ачыклар.

М. Гомәров бик күп крестьян отрядлары җитәкчеләре арасында күренекле башлыкларның берсе һәм ул лаеклы рәвештә тарих битләрендә үз урынын алырга тиеш.

Мәсәгуть Гомәров, Бахтияр Канкаев, Муса Мостафин, Канзафар Усаев, Аит Уразмәмәтов, Туктамышев, Әбҗәлил Сөләйманов, Юскәй Кудашев, азатлык өчен көрәшкә тормышларын биргән башка Пугачев полковниклары һәм старшиналарының образлары, аларның азатлык рухы үлмәде, халыкның күңелендә тирән сакланып, яңа көрәшчеләр тудырды.

—◆—

[1] БАУДА, фонд 349, оп. 1, сак. бер. 7110, 2 бүл., 34 бит.

## Сәнгать кешеләре

*Юрий Бейлькин*

# ҖЫРЫМ БУЛСЫН БҮЛӘГЕМ

Кеше — һәрвакыт балачагы узган, беренче мәртәбә эчкерсез сөю хисләре белән янган, үзен бәхетле иткән җирләргә тартылучан. Моның өчен кемгәдер урам аша чыгу җитә, икенче кешеләргә шәһәрнең үзәгенә яки читенә үк барырга кирәк, өченче берәүләргә исә йөзләрчә, меңнәрчә километр юл үтәргә туры килә. Ләкин кайда, нинди ераклыкта гына булмасын, кеше бөтен күңеле белән шул җирләргә омтыла, беркайчан да әйләнеп кайтмый торган яшьлек еллары узган якларны күрергә ашкына. Зур өметләр һәм якты идеаллар белән янган, теләсә нинди киртәләрне җиңел генә үтеп булырдай тоелган, хыял канатларында кошлар җитә алмаслык ераклыкларга очкан яшьлек еллары...

Композитор Рөстәм Яхинның шундый еллары Мәскәү каласында уза. Менә шуңа да, Казаннан Мәскәүгә килгән саен, ул иң элек гүзәл һәм зур музыка дөньясына юл күрсәткән таныш йортка ашыга. Мерзляков тыкрыгындагы бу иске йортта Мәскәү консерваториясе каршындагы музыка училищесы урнашкан. 1937 елның җәендә 16 яшьлек татар егете Рөстәм беренче тапкыр шушы йорт каршына килә, училищеның фортепьяно бүлегенә укырга керә. Татарстанда кызу темплар белән яңа, социалистик культура үскән еллар иде бу. Республикага милли сәнгать әһелләре — рәссамнар, җырчылар, музыкантлар, композиторлар кирәк. Шул чорда Мәскәүгә, бай культура традицияләре булган тарихи шәһәргә, белем алырга җибәрелгән талантлы яшьләрнең берсе Рөстәм Яхин була.

* * *

Рөстәмнең музыкага һәвәслеге бик яшьләй беленә, һәм, әйтергә кирәк, ул шактый үзенчәлекле, сәер формада чагыла. Җыр тавышы, берәр көй ишеттеме, малай шунда ук елап җибәрә торган була. Бераз үсә төшкәч, музыканы ул бөтенчәрәк кабул итә башлый. Зур игътибар белән, күңел биреп, музыкаль әсәрләрне тыңларга өйрәнә, үзе дә авыз эченнән генә җырлап йөрергә гадәтләнә, аны репродуктор янынна́н кузгатып җибәрү торган саен авырая бара. Рөстәмнәр өендә искерәк бер пианино да була. Рөстәмнең туганнан туган апасы Фәридә уйнаштыргалаган анда. Шулай бер вакыт энесен ул пианино алдында очрата. Бәләкәй кулларын кысып йомарлаган да, ашкынып-дәртләнеп, малай клавишларга суга һәм, бик үк гадәти булмаган шундый юл белән, матур-матур көйләр чыгара. Апасы аны беравык сүзсез генә, читтән күзәтеп тора. Аннан, янына килеп, кулларын энесенең иңенә сала һәм иплəп кенә сорый:

— Пианинода уйнарга өйрәнәсең киләме?

— Килә! — ди малай, уйлап та тормыйча.

Иртәгесен апасы Рөстәмне музыка укытучысына илтә. Кызганычка каршы, укытучысы янына күп дигәндә өч-дүрт мәртәбә генә барып калырга туры килә. Әшне әтисе сизеп ала һәм моңа бик тиз чик куя. Музыкага өйрәнүне юк нәрсә, бушка вакыт уздыру дип исәпли әтисе:



— Пианино дыңгырдатып йөрү — ирләр эше түгел,— ди.

Күпме генә кыен булмасын, эти кеше әмеренә буйсынудан башка чара калмый.

Әтисе вафат булып, байтак еллар узгач, әнисенең ризалыгы белән, ул яңадан музыка өйрәнә башлый. Бу болай була. Коннарнең берсендә аларга якын кардәшләре Мәрьям Рахманкулова килеп чыга. Билгеле, аны көтеп алынган кунак кебек олылап, шатланып каршылыйлар. Арада иң куанган кеше танылган җырчының һәр чыгышын зур кызыксыну һәм ярату белән тыңлап-күзәтеп барган Рөстәм була. Тик бу юлы яраткан апасы эш белән килгән икән.

— Шәһәрдә балалар музыка мәктәбе ачылачак икән,— ди ул Рөстәмгә.— Мин синең шунда укырга керүеңне теләр идем. Белмәссең, үзеңнән юньле генә музыкант чыгар, бәлки.

Шатлыгыннан нишләргә белми Рөстәм. Шулай да, бераздан, шактый җитди тонда, сорап куя:

— Мине алырлармы соң?

— Укырга теләгең зур булса, алырлар...

Тагын күпмедер вакыттан Рөстәм Казандагы беренче музыка мәктәбенә имтихан тота. Малайда искиткеч музыкаль сәләт барлыгы беленә. Мәктәп директоры Рувим Львович Поляков малайга виолончель классына укырга йөрергә тәкъдим ясый.

— Фортепьяно өчен яшең бераз олырак икән,— ди директор.— Аннан соң, дөресен әйтим, виолончель һич кенә дә фортепьянодан ким музыка коралы түгел.

Ләкин Рөстәм үз сүзендә нык тора. Аңа, янәсе, булса фортепьяно булсын, юк икән — ул укып та йөрмәячәк. Ниһаять, директор килешергә мәҗбүр була:

— Ярар, син теләгәнчә эшләрбез, тик кара аны, отличнога укырлык булсаң гына...

Ләкин «отличнога» уку җиңел түгел икән шул. Һәркөн иртән башта музыка мәктәбенә барасың, аннан — гомуми белем бирү мәктәбенә. Башкалар кебек үк, аңа да география белән тарихны да, физика белән алгебраны да, тел белән әдәбиятны да укып-өйрәнеп барырга кирәк. Ә вакыт һич җитми.

Шулай да Рөстәм сынатмый. Кичләрен кабат музыка мәктәбенә килә, яңадан-яңа көйләр өйрәнеп, кара төнгә кадәр пианино янында утыра.

Укытучысы Антонина Васильевна Чернышева музыка сәнгатенең чикләнмәгән мөмкинлекләре турында сөйли, зур түземлелек, такт белән, башкару техникасын камилләштерү юлларын өйрәтә. һәм, укучысының һәрнәрсәне бик җиңел үзләштерә алу сәләтен күреп, куанып бета алмый...

Тик, ни генә булмасын, яшьлек яшьлек икән — үзенекен итә. Әнә бит, Рөстәмнең иптәшләре һәр көн, теләсә кайчан коенырга чабалар, футбол уйныйлар, кызлар белән дуслашалар, бергәләп кино-театрларга йөриләр. Ә ул иң күп вакытын фортепьяно янында уздырырга мәҗбүр. Мондый вакытта аның да саф һава сулыйсы, Иделдә коенасы, берәр кызыклы китап укыйсы, инде һич югында, бер генә мәртәбә булса да, шәһәр урамнарын гизәсе килә.

Рөстәм торган саен музыкадан ераклаша, бизә бара. Әкренләп дәресләр калдыра башлый. Бервакыт музыка мәктәбенә йөрүдән бөтенләй туктый. Ни булды икән, әллә авырып киттеме, дип борчыла Антонина Васильевна. Ә аның авырырга уйлаганы да юк. Дөрес, музыканы ул әле дә ярата, тик башкалар уйнаганда. Репродукторлардан яңгыраган шашкын музыка авазларын ул әле дә әсәрләнеп тыңлый, пианистның җиңел бармаклары клавишлар буйлап йөзеп-йөгереп узуын сокланып карап торырга ярата. Ләкин клавишлар өстеннән шулай җиңел генә йөгертеп узарлык камиллеккә ирешү өчен, зур түземлек һәм ныклык, көн-төн күнегүләр алып барырга кирәклеген генә аңлап җитмәрми. Ул фортепьяно янына утыруга, инструмент җиңел генә аның ихтыярына буйсынсын да, берсеннән-берсе гүзәл моңнар таратып, музыка агылсын. Аныңча, шулай булырга тиеш. Тик менә көй агылмый, бармаклар йөрәккә буйсынмый, әйтерсең, алар катып калганнар. Шулай итеп, аның музыкадан күңеле кайта.

Антонина Васильевна малай белән ачыктан-ачык сөйләшеп карарга була һәм, аны эзләп, ул укый торган мәктәпкә бара. Мәктәп коридорында, пыр тузып, бер төркем малайлар чабыша. Барысыннан да алда — Рөстәм. Анны караны белми йөгергән уңайга, үзе дә сизмәстән, ул Антонина Васильевнага килеп бәрелә. Күтәрелеп караса, каршында музыка укытучысы басып тора. Җир тишегенә керердәй була малай. Укытучысы берни әйтми. Тик матур күзләре генә, ничектер, уйчан, моңсу карыйлар:

— Рөстәм, мин синс көтәм. Кил, яме!

— Ярар. Әлбәттә барырмын,— ди, оятыннан бөтенләй кызарып чыккан малай.

Шул вакыйгадан соң ул кинәт олыгаеп, җитдиләнеп киткәндәй була. Иге-чиге булмаган күнегүләр дә артык куркытмый башлый. Ул торган саен җиңелрәк уйный, үз көченә ышанычы арта, бармаклар да тыңлаучанрак була бара, инструмент янына көчләп утыртуның да кирәге калмый. Киресенчә, Рөстәмне фортепьяно яныннан куып җибәрү кыенлаша. Малайның уңышлары шулкадәр сизелерлек була, музыка мәктәбендәге берничә еллык программаны ул бер елда тәмамлый. Яшь музыкант сольфеджио һәм ритмика белән мавыга, музыканы аңларга һәм башкаларга җиткерергә өйрәнә. Аерым күнегүләр белән генә чикләнмичә, фортепьяно өчен язылган пьесалар, концертлар өйрәнә башлый. Григ, Рубинштейн, Бетховен аның яраткан композиторларына әйләнә. Ә укытучысы, һәр дәрестән соң, Рөстәмне кисәтә тора:

— Инструментта уйнарга түгел, ә җырларга өйрәнергә тиешсең.

Инструментта җырларга... Осталыкның иң югары критериесе — әнә шул.

Рөстәм өч ел ярым вакыт эчендә музыка мәктәбен тәмамлый. Яшь башкаручының сәләтен күрми калмыйлар. Мәктәпнең педагогия советы аны Мәскәү консерваториясе каршындагы училищега җибәрергә карар чыгара.

— Осталыгыңны Мәскәү музыкантлары ярдәме белән камиллаштерергә тиешсең,— ди аңа Антонина Васильевна.— Миннән өйрәнгәннәрең — эшнең башы гына әле. Синең бөтен килачәгең — алда.

Әнә шулай өметле һәм сәләтле яшь музыкант Мәскәүгә килә. Аның юлы — Мерзляков тыкрыгына, консерватория каршындагы училищега.

Училищега килүгә аңардан:

— Сез Татарстаннан бит әле? — дип сорыйлар.

— Әйе, Казаннан.

— Ул чагында, документларыгызны педагог Руббах классына тапшырыгыз. Ул үзе дә күптән түгел генә Казаннан күчеп килде.

Аврелиан Григорьевич Руббах сабыр табигатьле, үтә игътибарлы һәм яхшы күңелле кеше булып чыга. Әйе, таләпчән, педагог, акыл өйрәтүче генә булып калмый, Рөстәмнең якын киңәшчесе, чын дусты булып китә ул. Өстәвенә, Аврелиан Григорьевич менә дигән музыкант та икән. Ул еш кына төрле концертларда катнаша, һәм тамашачылар аның һәр чыгышын алкышлап каршылый. Үзенең бай тәҗрибәсен, күп серләрен ул, бик теләп, Рөстәм белән дә уртаклаша. Руббах сәләтле татар егетеннән олы музыка дөньясына чыгарлык профессиональ башкаручы тәрбияләргә хыяллана. Ә профессиональ пианист булу — бу инде зур эш. Моның өчен үзең уйный торган инструментны камил үзләштерү, музыкаль әсәрне җиңел аңлый алу гына җитми. Башкара торган әсәргә йөрәк җылыңны, күңел байлыгыңны сала белергә дә кирәк.

Рөстәм бөтен вакытын, яшьлек кайнарлыгын музыкага багышлый, күп укый, күп

төрле күнегүләр ясый. Зур башкару осталыгы сорый торган катлаулы, күләмле әсәрләргә тотына. Бетховен, Шопен, Бах, татар композиторларыннан Сәйдәшев әсәрләрен уйный. Музыка аның бөтен барлыгын биләп ала, канатландыра, бәхетле итә. Аны инде училище стеналарында ишеткән музыка гына канәгатьләндерми. Ул башка җирләргә, беренче чиратта, Мәскәү консерваториясенең Зур концерт залына йөри башлый. Бу концертлар аны музыка сәнгатен аңларга өйрәтә, иҗат эшенә дәртләндерә.

Күп мәшәкатьләре, шатлык-кайгылары белән студент еллары узып та китә. Чыгарыш имтиханында Рөстәм Яхин Шопен концертын башкара һәм дәртләнеп, илһамланып уйный. Әйтерсең, күңелендә туган инсез-чиксез шатлык хисләрен башкалар белән дә уртаклаша, башкалар белән дә бүлешә ул. Имтихан комиссиясе члennары бу юлы да яшь башкаручының бик сәләтле булуына игътибар итәләр, аның уенына лирик җылылык, фикер хөрлеге, эчкерсезлек хас, диләр. Киләчәк аңа бәхетле язмыш вәгъдә итә. Зур аренага чыгарга, менә дигән башкаручы булырга бөтен мөмкинлекләр ачыла. Ләкин ул башка юл белән китә.

Тормышта еш кына шулай була бит. Ниндидер очраклы бер вакыйга, көтелмәгән очрашу кайчак синең планнарыңны бутап ташлый, бөтен язмышыңны үзгәртеп җибәрә. Бервакыт Рөстәмнәр классына, А. Г. Руббахка иярен, танылган композитор Генрих Ильич Литинский керә. Рөстәмнең уенын тыңлап торганнан соң, Генрих Ильич аны бик мактый һәм, бер дә искитмәгән тон белән, сорап куя:

— Әйтегез әле, очраклы рәвештә, үзегез дә музыка язмыйсызмы?

— Юк,— ди егет.

— Кызганыч. Тиздән татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы булырга тиеш. Әйбәрләрегез концертларда яңгырар иде...

Рөстәм дәшми. Бер секундта аның күз алдыннан халык белән шыгрым тулы тамаша залы, аның әсәрен башкарырга әзерләнүче оркестрантлар уза, ул елмаеп җибәрә.

— Әйдә, тотын булмаса, язып ташла берәр пьеса,— ди Литинский.

— Яхшы, тырышып карармын,— ди ул.— Ләкин чыкмас дип куркам.

Трифоновскадагы тулай торакка кайтуга, Рөстәм пианино янына утыра. Әсәр язганым юк, булмас дип курыкса да, еллар буе музыка белән «җенләнеп» йөрүләр юкка булмаган, егетнең күңеле тулы моң икән ич. Әйтерсең, күңел түрендә күптән тупланып, ташып чыгарга җиткән хисләр дулкыны шушы көнне генә көткән: хатирәләп кенә өлгер, язып кына өлгер.

Берничә көннән Генрих Ильич янына Рөстәм бер дәфтәр ноталар күтәреп килә. Карап чыкканнан соң, Литинский ноталарны бер читкә этәрә һәм елмаеп җибәрә:

— Менә бит, булдыргансың! Казанга җибәрербез, декадага өйрәнә торсыннар.

Ләкин яшь композиторның бу беренче әсәрләре концерт залларында яңгырый алмый. Шулай ук татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы да уздырылмый кала. Тыныч илебезгә баштанаяк коралланган фашист илбасарлары басып керә, сугыш башлана. Ул Мәскәү консерваториясенә керергә, ил буйлап концертлар биреп йөрергә хыялланган иде. Планнар, хыяллар ярты юлда тукталып кала.

1941 елның ахырында Рөстәм Яхин Казанга кайта, Татарстан радиосында концертмейстер булып эшли башлый. Нәкъ шул айларда Елена Фабиановна Гнесина да Казанга килеп төшә. Җирле музыкантлар Рөстәмне атаклы пианистка белән таныштыралар. Яшь музыкантның ничек уйнавын тыңлап карагач, Гнесина аны шефлыкка ала. Рөстәм аның янында һәр килүендә баштанаяк музыка дөньясына чумып, канатланып кайта. Елена Фабиановна нечкә күңелле, бик мөләем кеше, шул ук вакытта артык таләпчән педагог була.

— Кара аны, бишенче бармагың белән дә кеше төсле уйнарга өйрәнмәсәң, Оборин сиңа үзенә алмас,— ди ул Рөстәмгә.

Кызганычка каршы, бу бәхетле көннәр күпкә бармый. Елена Фабиановна Мәскәүгә китеп бара. Тагын күпмедер вакыт узгач, Рөстәмгә повестка килә: сугышка солдат кирәк. Фронтка Мәскәү аша китәргә тиеш булалар алар. Сугышчан отрядлар шунда тәзелачәк икән. Алгы сызыкка китәр көннәр дә килеп җитә. Рөстәм соңгы мәртәбә Мерзляков тыкрыгына бара. Бирегә һәрнәрсә элеккечә, берни дә үзгәрмәгән диярлек. Тик тәрәзә пыялалары гына кәгазьләр белән ябыштырылган. Снарядлар, бомбалар шартлавыннан чәрдәкләнгәч булганнар, күрәсең. Рөстәм Елена Фабиановнаны

исена төшерә һәм кереп саубуллашып чыгарга уйлый: «Кем белә, башка күрешергә дә туры килмәс, бәлки. Сугыш бит...».

Рөстәмнең фронтка китәчәген ишеткәч, икеләнеп торырга берничнди урын калдырмыйча, бик катгый һәм таләпчән тонда Гнесина болай ди:

— Сез Мәскәүдә калырга тиешсез. Кешеләргә сезнең талантыгыз кыйммәтрәк. Бирәдәге гарнизонның җыр һәм бию ансамблендә калдырырга тырышып карармын.

Билгеле, егет каршы килә. Ләкин Гнесинаның үз сүзе сүз.

— Ышаныгыз, талантсыз бер кеше булсагыз, тырышып йөрер идеммени,— ди ул.

Билгеләнгән вакытка чакыру пунктына килүгә аңа:

— Сез Мәскәү фронтының һава оборонасы частьлары каршындагы җыр һәм бию ансамбленә билгеләндегез,— диләр.

Бу хәбәрне әйткән офицер көлеп җибәрә һәм, күзләрен шаян уйнатып, болай ди:

— Хәзер ничек язалар әле? Туплар сөйләшкәндә дә музалар тынарга тиеш түгел, диме. Шулай туган, музыка фронты өлкәсендә уңышлар телим сезгә.

Шул көннән башлап, Рөстәм Яхин хәрби ансамбльдә концертмейстер вазифасын башкарырга керешә. Ә эш муеннан, дияргә була. Көн дә концерт, көн дә яңа частьлар. Берөзлексез концертлар куеп, ансамбль фронтның барлык бүлекләрен йөреп чыга. Рөстәм солистларны өйрәтә, хор белән репетицияләр ясый, сирәк эләгә торган ял сәгатьләрендә иҗат эше белән шөгыльләнә, музыкаль әсәрләр яза.

Бер көнне, фронт поэзиясе үрнәкләре белән танышып утырганда, Цезарь Солодарның зенитчылар турында язылган шигыренә тукталa ул: «Шушы шигырьгә көй язып карасаң, ничек булыр икән?» Озакка сузмыйча, эшкә дә тотына. Шигырьнең эчке рухына, пафосына ятышлы көй эзләп, уннарча вариантлар язып карый. Ниһаять, эзләгән, кирәкле мелодия табылган көн була. Шулай, сугыш елларында зур популярлык казанган «Зенитчылар маршы» языла.

Ансамбль җитәкчесе Константин Сергеевич Виноградов яшь авторның тәҗрибә рәвешендә язылган беренче әсәрләрен хуплап каршылый. Рөстәмнән ансамбль өчен тагын берничә көй язуын үтенә. Озакламый сәләтле концертмейстер Мәскәү һәм Ленинград шәһәрләренә багышланган яңа җырларының әзер ноталарын китерә.

Ватан сугышының азагына кадәр Р. Яхин әлеге ансамбльдә эшли. Шул еллар эчендә ул дистәләрчә солдат җырлары иҗат итә. Һәм аларның барысы да гади, конкрет булулары белән аерылып торалар, сугышчылар ул җырларны теләп, яратып башкаралар. Шушы беренче, өйрәнчек әсәрләрендә үк Яхинның үз йөзен, индивидуаль почеркын чамаларга, композиторның музыканы сөйләм интонацияләренә мөмкин кадәр ятышлырак, гармониграк итәргә омтылуын сизәргә була.

Әкренләп ил тыныч тормышка кайта. Яңадан техникум, институт ишекләре ачыла. Мәскәү консерваториясе яңа студентлар кабул итә. Консерваториягә сугыштан соң кабул ителгән беренче студентлар арасында Рөстәм Яхин да була. Ләкин бу юлы инде ул югары уку йортының композиторлар әзерләү бүлегенә, профессор Виктор Аркадьевич Белый классына укырга керә. 1946 ел була бу. Шул елдан яшь композиторның иҗади тормышында гаять нәтиҗәле этап башлана, аның талант көче аеруча нык һәм көчле булып ачылып китә. Кешене музыка язарга беркем дә, хәтта бик талантлы педагог та өйрәтә алмый, билгеле. Хаерс, Виктор Аркадьевич үз алдына андый максат та куймый. Ул үзенең иҗат тәҗрибәсе белән уртаклаша, Рөстәмне композиторлык техникасы, музыкаль жанрларның үзенчәлекләре белән таныштыра. Һәм иң әһәмиятлесе: мөстәкыйль рәвештә фикер йөртергә, киң, зур итеп уйларга өйрәтә.

Үзенең күпчелек әсәрләрен Рөстәм нәкъ шул елларда яза. Фортепьяно өчен 4 кисәктән Сюита, күп санлы сонаталар, юморескалар, лирик җырлар... Аның бөтен язганнары нәфис моң, уйчан сурәтлелек белән сугарылган, аларда авторның йөрәк кайнарлыгын һәм кичерешләрен, тормышка, гади кешеләргә булган чиксез мәхәббәтен тоясың. Нәкъ шул елларда композиторның иҗат стиле формалаша, тагын да камилләшә төшә. Ул халыкның бай һәм саф музыка чишмәсеннән торган саен күбрәк файдалана, үзенең әсәрләре өчен музыкаль аһәң, нәфис сурәтләү чаралары ала. Авторның скрипка һәм фортепьяно өчен язылган Поэмасы әнә шул турыда сөйли. Тирән лиризм белән сугарылган бу Поэма халык музыкасының эмоциональ тәэсир көчен раслаучы матур дәлил була ала.

Рөстәм Яхин — халык арасында киң таралган лирик җырлар һәм бик күп романслар авторы. Шигъри әсәрләрдән композитор үз кичерешләренә, үз хисләренә таңгал килерлек юллар эзли, мәхәббәт, тормыш һәм бәхет турындагы карашларына аваздаш булырлык поэтик фикерләр табарга тырыша. Аның иҗаты торган саен күпкырлырак, музыкаль формалар ягыннан баерак, поэтик сүзне музыкада гәүдәләндерү ягыннан эчталеклерәк, тирәнрәк була бара.



Р. Яхин авторлык концертында.

1949 елда җәйге каникул көннәрендә композитор Казанга, туганнары янына кайта. Шәһәр үзе дә, дуслар да шулкадәр сагындырган, шулкадәр юксындырган. Рөстәм композиторлар янында була, шагыйрь дусларын очрата. Шундый очрашуларның берсендә М. Ногман аңа үзенең яңа шигырьләрен күрсәтә. Арадан берсе аеруча ошый композиторга. Бераз моңсурак тонда язылган, эчке дулкынлану белән сугарылган ул шигырьдә яратып сөйгән ярыннан аерылган яшь егетнең көчле сагыну хисләре турында сөйләнелә. Пианино янына бер-ике утыруга, композитор аны җиңел генә көйгә сала. «Оныта алмыйм» дигән бу романс Казан, Мәскәү һәм башка шәһәрләрнең эстрада концертларында еш башкарыла.

III курста Р. Яхин профессор Юрий Александрович Шапорин классына күчерелә. Яңа педагог чикләнмәгән иҗат фантазиясенә ия композитор, эре колачлы, масштаблы эпик жанрлар остасы була. Укытучысы тәэсирендә яшь композитор да зуррак жанрларга күчә. Башкорт шагыйре Кадыйр Даян сүзләренә язылган «Урал» кантатасы — шундый әсәрләрнең берсе. Кантата халык җырларының ритм-интонацияләренә нигезләнгән, анда замандашларыбызның дулкынландыргыч образлары гәүдәләнә.

Кеше гомерендә төрле еллар була. Аларның кайберләрен уздыра алмый җәфа чигәсең. Икенчеләренең, эш белән мавыгып, ничек үткәнен дә сизми каласың. Консерваториядә Р. Яхин шундый тормыш белән яши, 5 еллык вакыт сизелми дә узып китә.

Дәүләт имтиханнарын ул фортепьяно һәм оркестр өчен язылган Концерт белән каршылый. Фортепьяно һәм оркестр өчен язылган Концертны тыңлаганда, композиторның күп төрле лирик настроениеләр аша акренләп, ләкин ышанычлы адымнар белән зур иҗтимагый яңгырашлы, тирән һәм драматик темаларны чишүгә таба килүен сизәсең. Әсәрдә авторның гражданлык хисләре һәм тормышка мөнәсәбәте конкретлашкан, кеше язмышлары, яшәүнең мәгънәсе турындагы уйланулары тагын да ачыклана төшкән. Капма-каршы хисләр бәрелешенә корылган, урыны-урыны белән минор тоннарда яңгыраган бу концерт тормышны раслаучан якты буяулар, оптимистик пафос белән сугарылган.

Мәскәү консерваториясен тәмамлаганнан соң, Р. Яхин укытучылык эшенә күчә, бернихадәр вакыт Казан дәүләт консерваториясендә композиция классын җитәкли. Ләкин күңелнең кайсыдыр почмагында акрынлап профессиональ иҗат эшенә күчәргә кирәк дигән омтылыш, теләк өлгерә. Профессиональ иҗат эшенә күчкәннән соң, Рөстәм Яхин гаять күп санда музыкаль әсәрләр иҗат итте. Шуларның зур өлеше лирик җырлар һәм романслар. Характерлары белән дә, темалары ягыннан да алар төрлетөрле. Ләкин барысына да эмоцияләр байлыгы, хис-кичерешләр тирәнлеге хас. Менә Гамир Насрый сүзләренә язылган «Күңелемдә яз» романсы. Аны, күбрәк, СССРның халык артисты Эрмәк Серкебаев башкаруында тапшыралар.

Ә мин, иркәм, сине көтәм,
Көтә-көтә зарыгып бетәм
Гөлчәчәкле бакча янында...

Югары пафос, йөрәк кайнарлыгы белән язылган бу романс табигать матурлыгы, сөйгән яр белән кавышу шатлыгы турында сөйли.

Илленче еллар башында татар шагыйре Муса Җәлилнең тиңдәшсез батырлыгы бөтен дөньяга мәгълүм булды. Гитлерчылар кулында һәлак булган керәшче шагыйрь образы Совет кешесенең рухи ныклыгын раслаучы якты гуманизм символына әверелде. Муса Җәлил поэзиясе сәнгатьнең барлык тармакларында эшләүче кешеләрнең, шул исәптән композитор Рөстәм Яхинның да, игътибарын үзенә тарта, иҗатка рухландыра. Композитор «Моабит дәфтәреннән» дигән гомуми баш астында романслар циклы тудыра. Җәлил әсәрләре арасыннан драматик яктан аеруча көчле эшләнгән биш шигырь сайлап, Р. Яхин герой шагыйрь образын мәңгеләштерүгә багышланган музыкаль новеллалар яза. Цикл тирән нәфрәт хисләре белән сугарылган «Катыйльгә» исемле драматик монолог белән башлана. Монологтагы трагик пафос, революцион героизм бөтен циклның эчке рухын билгели.

Рөстәм Яхинның халык шагыйре Габдулла Тукай, герой шагыйрь Муса Җәлил сүзләренә язган гүзәл романслары татар совет музыка сәнгатенең казанышы булып саналырлык әсәрләр белән бер рәттә торалар.

Күптән сугышлар тынды. Ил үзенең яраларын төзәтеп килә. Ләкин илен саклау өчен гомерләрен биргән кешеләрнең якты истәлеге халык күңелендә мәңге саклаңыр. Исәннәр каен төпләрендә мәңгегә ятып калган иптәшләрен онытмаска тиешләр. Композиторның «Каеннар шаулый» исемле романсы дөнья халыкларын сугыш уты кабызучыларга каршы көрәшкә өнди.

Композитор Р. Яхинның тагын бер әһәмиятле үзенчәлеге шунда, үзенең һәр әсәрен ул гаять җентекләп, тәмам камил хәлгә килгәнче эшкәртә. Кайчандыр беренче укытучысы аңа:

— Һәр музыка әсәре җырлап торырга тиеш,— дигән иде. Укытучысының бу сүзләрен ул бервакытта да истән чыгармый. Нинди генә әсәргә тотынмасын, лирик җырмы, романсмы, я булмаса, инструменталь пьесамы ул, композитор аларның һәркайсын җырлап торырлык дәрәҗәгә җиткергәнче эшкәртергә тырыша.

Р. Яхин әсәрләре — авторның уйланулары. Ул яшәү һәм үлем турында уйлана, Ватаныбыз кичкән авыр сынау еллары турында уйлана, туган җир матурлыгы һәм кеше бәхете турында уйлана. Шулай да, композиторның иҗат үзенчәлеге күбрәк мәхәббәт темаларына багышланган әсәрләрендә чагыла. Аның җыр-романслары, яз, нәфислек, саф мәхәббәт юлдашлары булып, илебез сәхнәләре буйлап йөриләр. Авторның «Ышанам» исемле әсәре шундый җырлар рәтенә керә. Ышанам: бер-беребездән никадәр генә еракта яшәсәк тә, без очрашырбыз. Ышанам: таулар, елгалар, урманнар безнең юлыбызда киртә була алмаслар, ди композитор бу әсәре белән.

Купьеллык иҗат эшчәнлеге дәверендә композитор 200 гә якын музыкаль әсәр язды. Шуларның 100 дән артыгы вокаль жанрына карый. Аның җыр-романсларын илебезнең бик күп танылган артистлары теләп, яратып башкаралар: Э. Сәрмебаев, М. Рахманкулова, М. Булатова, А. Аббасов, И. Шакиров, Э. Җәләлетдинов һәм башкалар, һәм башкалар.

Р. Яхинга Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе һәм Габдулла Тукай премиясе лауреаты дигән мактаулы исем биреп, Почет билгесе ордены белән бүләкләп, хөкүмәтебез аның композиторлык һәм җәмәгатьчелек эшчәнлеген билгеләп үтте.

Музыкант-башкаручы буларак та Рөстәм Яхин төрле концертларда бик еш катнаша. Пианист Яхинны Ленинград һәм Свердловск, Алма-Ата һәм Ташкент, Саратов һәм Днепропетровск, Советлар Союзындагы башка күп шәһәрләрнең музыка сөючеләре яхшы беләләр. Ә Казан турында сөйләп тә торасы юк. Һәм композитор һәм башкаручы буларак, Рөстәм Яхинны Казан халкы күптән үз итте, күптән яратты.

Рөстәм Яхинның күңеленә аеруча якын тагын бер шәһәр бар. Мерзляков тыкрыгы, Герцен урамнары белән күңел түрендә саклана торган бу шәһәр — Мәскәү исемле... Кеше һәрвакыт яшьлегенә үзгән, үзен бәхетле иткән җирләргә тартылучан.

# ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

## БУ ШИГЫРЬНЕҢ ШАГЫЙРӘСЕ КЕМ?

*(XVIII нче гасыр татар поэзиясе үрнәкләреннән)*

Казан да Тубыл [1] арасы
Ятыр да гәүһәр парәсе,
Алладин фәрман булгандин соң
Аның ла нәдер чарасы.

Юктыр ла аның чарасы,
Күнелдә фирак [2] парәсе,
Хәсерәт утын көйдереп,
Йөрәккә төште карасы.

Иртә-кич өйрә ашымдыр,
Күземдә канлы яшемдер,
Калын ла бистә эчендә
Адашкан гарип башымдыр.

Алтынлы сырга башларым,
Ләгылле гәүһәр ташларым,
Наллы да үскән җаннарым,
Күз өстендә лә кашларым.

Яулык ла тектем нәгыштән,
Күчердем бер үк багыштан,
Гөлдәй лә нәзек җаннарым
Саргаеп сәнең сагыштан.

Күңлемдә күптер сагышым,
Сездәдер минем багышым,
Сезне лә барып бер күрсәм,
Китәр лә ирде сагышым.

Ай-һай ла көннәр яз булды,
Китәр лә юллар саз булды,
Бу гариплэрнең төшкән җире
Чыкмас ла тирән баз булды.

Казанга барган бар микән?
Казандин килгән бар микән?
Казан да дигән шәһәрдә
Безне дә белгән бар микән?

Казандин килгән солдатның,
Сәч кенәсе лә төрмәдер [3],
Казанда булган туфырак
Күз гекәмә лә сөрмәдер.

Казан да дигән хуш шәһәр
Бездин лә калды күп ерак,
Казанда булган җаннардин
Арада булды әлфиракъ [4].

Тәңрем лә канат бирсәче,
Канатым кагып очсамчы,
Газиз дә Казан шәһәренә
Очып та барып төшсәмче.

Пигамбәр җифте Хәдичә,
Әүүәлдә килде исламга,
Юсыф та берлән Зөләйхәнең
Кыйссасы калды дөньяда.

. . . . . . . . . . . . .[5]

Кавырсыны катмаган,
Бала коштай җаннарым,
Иртә торып карасам,
Дөньяда күргән күзләрем.

Нәзек тә үскән буеңыз
Борылып үскән талдаең,
Сөйләгән дә сүзеңез
Татлы шикәр-балдаең.

Бармыдыр сезнең малыңыз?
Бәндин лә нәдер хәлеңез?
Әнекәчеңез югыйндин
Борыла бугай җаныңыз.

---

[1] Т у б ы л — Тобольск.
[2] Ф и р а к — аерылу
[3] Т ө р м ә — төрелгән, ягъни солдатлар маңгай чәч чугы йөрткәннәр.
[4] Ә л ф и р а к ъ — аерылу үкенече вакытында әйтелә торган сүз.
[5] Бу урында дүрт юллык шигырь бозылган. Аңлашылмады. Н. И.

# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗГА БЕР ҮТЕНЕЧ

Бу шигырь 1964 нче елның җәендә Ленинград көнчыгыш телләр Институты китапханәсенең кулъязмалар бүлегендә күчереп алынган иде. Ул «Чингизнамә» һәм башка дастаннар тупланган бер җыентык артына урнаштырылган. Җыентыкның өстенә «Сахибәһү, маликәһү Әбүбәкер бине Ибраһим» дип язылган. Әбүбәкер бине Ибраһим бине Юсыф бине Ишбулад дигән бу кеше исә Казан мулласы булып торган. 1793 елда вафат. (Риза Фәхретдин. Асар 2 том, 62 бит.) Шулай итеп югарыда без китергән шигырь дә XVIII нче гасыр язмасы булып чыга.

Шигырьдән аңлашылуынча, аны, ни өчендер, Казаннан Себердәге Тубыл каласына киткән яки анда сөрелгән бер татар хатыны язган. Бу хатын, шигырьдән күренүенчә, алтынлы сыргалар таккан, аның әле үзенең дә матур, яшь, «күз өстендә каш» кебек чагы. Шулай да шагыйрә өзлексез хәсрәт утлары эчендә яна. Ул үзен «гарип» (ил-йортыннан аерылган, юлларда ялгыз калган) кеше дип саный. Аның йөрәге үзенең туган шәһәре Казанга, андагы туганнарына тирән мәхәббәт сагышы белән яна. Безнең өчен иң әһәмиятлесе дә шагыйрәнең үз туган ватаны Казанга мәхәббәтен ничек тәгъбир итүендәдер.

Ләкин әсәр үзенең теле һәм шигъри формасы ягыннан да тарихи әһәмиятле. Аның башына «Илаһи бәет» дип куелган. Биредә «бәет» сүзе халык җырлары алымында язылган шигырь дигән мәгънәне аңлата (аның шундый мәгънәсе дә бар). Бездә соңгы вакытта татар шигыре Тукайдан гына башланган, аңа кадәрлесе аермасыз, гомуми бер төрки теле генә булган, шулай булгач, аны татар әдәбиятының тарихи мирасы итеп караргa да ярамый дигән фикерләр ишетелгәли. Бу тарихи материал исә андый фикерләрнең фәнни нигезсез икәнлеген, Казан татарларының әдәби теле XVIII гасырда һәм аннан да элек күптән формалашып килгән булуына бик матур мисалларның берсе була ала.

Кызганычка каршы, әлегә кадәр миңа бу шигырьне иҗат иткән шагыйрәбезнең үз исемен ачыклау насыйп булмады. Борынгы әдәбият тарихы буенча материал туплаучылар кулында бу хакта өстәмә материаллар табылмасмы? Алар Себер-Тубыл якларында да табылуы мөмкин. Шундый мәгълүматларны кулына төшерә алучылар булса, журнал аркылы игълан итүләрен үтенәм.

Нәкый ИСӘНБӘТ.

## ИҢ-ИҢ...

Иң күп музыкант катнашкан оркестр Норвегиянең Тронхейм шәһәрендә 1958 елның август аенда үткәрелгән милли тынлы оркестрлар очрашуы вакытында уйнаган. Ул гадәттән тыш оркестрда уникe меңнән артыграк музыкант катнашкан.

●

«Клеопатра» — үзен төшерү өчен тотылган расходы ягыннан дөньядагы иң кыйммәтле кинофильм. Элизабет Тейлор уйнаган бу фильмны төшергән «XX — сен-чури-фокс» фирмасы, тамашачыларны шаккатыру максатыннан чыгып, һич кирәге булмаган төрле зиннәт әйберләре, массовый сценалар кертеп, кырык ике миллион доллар акча тоткан. Әмма атаклы кино йолдызы да, түгелгән миллионнар да бу фильмның тозсызлыгын каплый алмаган — бик күңелсез, мәгънәсез булып чыккан ул.

●

Дөньяда иң күп сигарет каплары җыйган кеше — Копенгагенда яшәүче Нильс Вентегодт. Ул 1965 елның 30 июненә йөз җитмеш җиде илнең утыз бер мең ике йөз егерме җиде сигарет кабын җыйган иде. Хәзер бу санны тагын да арттыргандыр инде ул, мөгаен.

●

Хәрби заказлар — монополияләр өчен бик зур байлык чыганагы. Бу елкада бер еллык доход күләме буенча рекордны «Дженерал моторс» концерны куйган. Концерн 1964 елны 1 734 781 555 доллар табыш алган.

# Китап күзәтү

## Халыклар дуслыгы турында сөйләүче китап

Бу ике автор 1964 елның язында Урта Азия республикалары белән танышып йөргәннәр. «Гөлстан язы»[1] шул сәяхәт турындагы очерклардан тора. Аларның сәяхәте бик уңайлы вакытка — Үзбәкстанда сәнгать бәйрәме үткәрелгән көннәргә туры килә. Иске Россиянең артта калган бер окраинасы исәпләнгән Үзбәкстан бүген тормышның һәр өлкәсендә гүзәл уңышларга ирешә. Республикада культура һәм сәнгатьнең торышы белән таныштырганнан соң, авторлар безне Урта Азия тормышының төрле-төрле якларына алып китәләр.

Анда без мамык һәм ефәк мастерларын, каракул җитештерү һәм газ үткәрү осталарын, кыргый Вахш елгасын авызлыклап, аны коммунизм арбасына җигүче батырларны күрәбез. Бу төзелешләр һәм шул тирәдәге яңа тормыш учаклары бездән никадәр генә ерак булмасыннар, күңелгә алар бик якыннар, безнең укучыларны да бик дулкынландыралар.

Нурек төзелешендә эшләүче якташыбыз Мөҗибулла Габитов турында сөйләгәндә, авторлар аның бик матур бер сыйфатын күрсәтәләр. «Ул илебездә булган барлык төзелешләр белән кызыксынып тора икән. Үзенең махсус картасы бар. Башлаган һәр төзелешне шунда билгеләп куя. Газета-журналлар буенча аның үсешен күзәтеп бара һәм төзелеш тәмамлануын белгәч, ул объектка кызыл флаг ясап куя икән...» (145 бит).

Шулай инде, безнең ил халыкларының шатлыгы да, кайгысы да уртак. Китапта без төрле милләт улларының һәм кызларының кулга-кул тотынып эшләүләрен күрәбез. Тормышларының иң авыр чорларында, якты киләчәк өчен көрәшкәндә, алар бер-берсенә дусларча ярдәм кулы сузганнар иде. Бүгенге бәхетле тормышны күрсәткәндә, шуңа ирешү юлында үтелгән беек сынауларны искә алу хәзерге бәхетнең кадерен яхшырак белергә ярдәм итә. Урта Азия халыклары социализм юлына аяк басканда, безнең егетләр дә аларга бик ярдәм иттеләр. Шагыйрь Сибгат Хәкимнең «Ленин фарманы белән» поэмасында комиссар Гинцбург җитәкчелегендә сугышкан Казан полкының батырлыклары матур күрсәтелгән.

Гражданнар сугышы елларында комиссар Якуп Чанышев, Хөсәен Мәүлүдов, Гали Касыймовлар җитәкчелегендә акларга, интервентларга һәм басмачыларга каршы сугышып, Бохараны әмир коллыгыннан коткарган татар бригадасының батырлыклары безнең әдәбиятта үзенең гәүдәләнешен көтә. Ә Бөек Ватан сугышы елларында фашизмның беренче ударларын өсләренә алган республикаларның эвакуацияләнгән кешеләрен Ташкент, үзбәк халкына хас кунакчыллык белән, үзенә кабул итте. Һәм менә хәзер 1966 елның язында җир тетрәүдән зарар күргән Ташкентка бөтен республикалар туганнарча ярдәм

---

[1] К. Фәсәхов, А. Салахетдинов. Гөлстан язы. 1966 ел. Татарстан китап нәшрияты.

нталәр. Төрле халыклар арасындагы Ленинча дуслыкның матур үрнәге бу.

Урта Азия халыкларының бүгенге матур тормышы турында сөйләү белән бергә, авторлар безгә ул халыкларның михнәтле, авыр үткәне турында да күп мәгълүмат бирәләр. Үткән тарихны бәяләгәндә хәсрәтле якларны гына түгел, халыкның бетмәс-төкәнмәс иҗат көчләрен дә күрсәтергә кирәклеге турында матур гына фикерләр әйтелә:

«Тарихыңның ул шаһитләре ерак үткәнеңнең изелгәннәр күз яше һәм корбаннар каны белән юылуын гына түгел, халкыңның иҗат хыллы тудырган сәнгать энҗеләре белән бизәлгәнлеген дә ачтылар» (172 бит).

Бер фактик хата: китапның 75 битендә «Сумск компрессор заводы» телгә алына. Илдә генә түгел, дөньяда да юк бу шәһәр исемен авторлар каян алганнардыр. Дөресе — Украинадагы Сумы шәһәре.

Китапның теле матур, җыйнак. Бу төр очерклар шундый җиңел, сурәтле тел белән язылырга тиешләр дә, бусы авторларның уңышлы хезмәте. Ләкин кимчелекләр дә юк түгел. Бигрәк тә бу башка теллардән алынган сүзләрнең һәм исемнәрнең язылышына кагыла. Эш шунда ки, бер телнең әйтелеш һәм язылыш нормалары икенче телгә өлге булып бетә алмый. Китапта «Ташкент бахоры» исемле бер бүлек бар. «Яз көне» мәгънәсендәге «бәһар» дигән фарсы сүзен безнең авторлар шулай алганнар икән. Дөрес, үзбәк әйтелеше буенча бу сүзнең уртасында «х»га якын аваз ишетелә, ләкин язылышта үзбәкчәдә дә безнең «һ» хәрефенә туры килә торган хәреф кулланыла. Язуларында «һ» хәрефе булмаган кайбер телләргә ияреп, бу сүзне бозып язу безнең әдәби традициябезгә игътибарсыз карау була. «Качан соң и фәныйрь милләт бәһарың...» дип укыйбыз без Тукай шигырендә.

Башка теллардән алынган сүзләрне куллану һәр телдә прогрессив бер күренеш. Ләкин бирелә дә җыйнаклык һәм матурлык беренче кагыйдә булырга тиеш. Авторлар «регулярлаштыру» сүзен кулланырга яраталар. Шул ук сүзне «тәртипләү» дип кулланганда мәгънәсе дә дөрес, җыйнак та була, «упаковкалау цехы» урынына «упаковка цехы» килешлерәк бит.

Сурәтләү чараларына карата. Болар бик кирәкле, бик файдалы нәрсәләр. Ләкин урынын һәм җаен белеп кулланганда. «...барысы да ал да гөл дип әйтү тормышка үтә «кызыл» күзлектән карау булыр иде» (71 бит), дип язалар авторлар. «Аллы-гөлле күзлек» диелсә, мәгънәсе ягыннан дөрес, формасы белән русчадагы «розовые очки»га бик якын булыр иде. «Кәҗәсе кыйбат түгел, мөгезе кыйбат» (54 бит); «...дип үгезне мөгезеннән элэктерде бу» (57 бит). Боларның соңгысы уңышлы булса да, беренчесен алай дип булмый, бәлки кайбер районнарда шулай дип сөйлиләрдер, ләкин күбрәк таралган формасы «сачәге түгел, ялләкасе кыйбат» түгелме икән? Гомумән, мөгез белән артык мавыгып, кирәккә дә, кирәкмәскә дә мөгез чыгару килешми торгандыр. «...мең елларны кочаклаган тарих» (173 бит) — бу да уңышлы сурәт түгел. «Тарих» сүзенә карата «колачлау», «иңләү» дию уңышлырак булыр иде.

Югарыдагы кимчелекләр күпмедер дәрәҗәдә китапның гомуми кыйммәтен киметәләр, билгеле. Шул ук вакытта мондый төр китапларның бик файдалы, кирәкле булуларын һәм безнең өчен һава кебек кирәк булган халыклар дуслыгын ныгытуга хезмәт итүләрен дә истән чыгармаска кирәк.

С. ФӘЙЗУЛЛИН.

—✧—

# «Аҗаган»

Китап — кеше кебек ул. Аның белән сөйләшәсең, бәхәсләшәсең, аңардан киңәш сорыйсың. Әгәр китап син уйлаганча гына фикер йөртсә, күптән билгеле нәрсәләргә генә ишарә ясаса, аңгәмәне артык дәвам итеп булмый.

Күптән түгел Татарстан китап нәшрияты Равил Фәйзуллинның «Аҗаган» дигән шигырьләр җыентыгын чыгарды. Р. Фәйзуллинның күп шигырьләре, газета-журналларда басылып чыгып, шактый гына шау-шу купарып өлгергәннәр иде инде. Кайберәүләр авторны формализмда гаепләделәр, икенче берәүләр үтереп мактадылар. Минемчә, тегеләре дә, болары да үз фикерләрен яшь авторның бер-ике әсәренә карап кына әйттеләр, чөнки Фәйзуллин иҗатының чын йөзен күпмедер ачкан тулы җыентыгы юк иде әле. Ул хәзер бар. Бер-ике ел элек язылган шигырьләрдән торса да, ул укучыларга үз фикерләрен тегәлрәк итеп әйтергә дә мөмкинчелек бирә.

Ләкин минем максатым ул түгел. Мин, бит арты бит ача-ача, «Аҗаган»ны укыйм, аның белән танышырга теләп, сөйләшәм генә.

Болай тезсәң, йөз
дустың арта,
болай тезсәң, йөз
дошманың!

(*«Хәрефләр»*)

Дөрес, дөрес! Дөньяда җыр да, шигырь дә — көчле корал. Алар белән әруча сак эш итәргә кирәк. Аларны, уйлап җиткерминчә, кирәкмәгән урында кулланып дусыңны — дошман, дошманны — дус итәргә дә мөмкин ич. Хәрефләр, сез бу китапка шигырьләр булып тезелеп, минем, яшьташларемнең, әне-сеңелләремнең, абый-апаларның дусты була алырсызмы икән?

Сез балталар уйлап
таптыгыз. Башларыгыз
бүкәннәрдән тәгәрәде,
үзегез ишкән бауларда
маятник күк җилдә
чайкалдыгыз,
үзегез койган
ядрәләрне тәнегездән
әскәкләп чүпләдегез,
үзегез җыйган танклар
кулларыгызны сытып
узды,
үзегез очырткан корыч
кошлар өсләрегезгә
бомба койды...

(*«Гадиләргә гимн»*)

Сез хәрефләр, шушы хакыйкать булып тезелеп, шушы хакыйкать булып яңгырап, кешеләрне рәнҗетмисезме икән?

Тик шулай да
Җиргә җыр җитешми
әле.
Тормыш әле җырга
тиенмәгән,—

дип, Җирне ачуландырмыйсызмы, хәрефләр?

Ачулансыннар — кешеләр дә, Җир дә. Кайбер вакытта ачулану елмаю кебек үк мөһим нәрсә.

Шулай, энем,
иртәгесе иртән,
бүгенгесе кыйммәт
дөньяның... —

дип «акыл» өйрәтүчеләр дә, «ике куллап, кысып-кысып, кысып-кысып сыгасы» сагышлар да, ядрәне көчле диючә кешеләр дә, Бухенвальдлар да, «бер нәбахәт иренена ялгыш кунган» яхшы сүзләрнең аһ-зарлары да бар бу дөньяда.

Ләкин дөнья, бәхетка каршы, алардан гына тормый: елмаюына тереп конфетлар таратучы стюардесса да, карлыгач очуына карап, бар нәрсәләрен оныткан шагыйрь күңелле кешеләр дә, кер чайкаучы кызлар да, күзләренә болытлар, тургайлар, чәчәкләрне сыйдырган сылулар да, «котсыз суык кенне шыксыз булмага яз китерүче» иркәләр дә, яхшылык кына теләп алдалаучы хыяллар да бар бу дөньяда. Шулар безне мәхәббәт тулы мәһабәт йөрәкле кешеләр итәләр. Һәм без, Җир вәкиле буларак, гуманистлар буларак, Кояшка мөрәҗәгать итәбез:

Сөйлә, Кояш!
Бүтән елларда
минем кебек егерме
яшьлекләр
ни уйлыйлар?
Кырыкка җиткәч
нишләмәкчеләр?
Алтмышта?..

. . . . . . . . . . .

Сөйләп җибәр Җир
турында
илләр турында:
Анголада ни хәлләр
бар?
Лаоста?
Кубада?
Сиңа мин күбрәк
ышанам:
син барсына шаһит,
сиңа барсы мәгълүм.

(*«Керфек очындагы Кояш»*)

Без киләчәгебез турында борчылып, кешелеккә мөрәҗәгать итәбез:

Ярылырмы бомба баш
түбәмдә?
Белмим.
Әнием дә белми.
Кем белә?
Әйтегез сез аңа!
Әйтегез...

Һәм кешелек безгә җавап бирә:

Әгәр кемнәрдер дөньяга
сыймый икән,
аларга каршы,
инкәргә икке терәп,
кирәк икән,
пирамидалар күчерелер!

Ак иңгә — кара
сабыйны,
кара иңгә — сары
сабыйны,
сары иңгә — ак
сабыйны куеп,
тере нәфрәт стенасы
коелыр!..

Әйе, шулай булыр!

Кайберәүләр Р. Фәйзуллин шигырьләре авыр аңлашыла диләр. «Башваткычлар, шарадалар» диючеләр дә юк түгел. Бу сүзләр мине һич гаҗәпләндерми, чөнки заманында зур акыл иясе Вольтерның да кофеның агусыз булуына шик белдергәнен, заманында бәрәңге һәм помидорның да кешеләрдә шик тудырганын ишеткәнем бар минем.

Бу җыентыктагы шигырьләр, минемчә, аңлаешлылар, чөнки андагы фикерләр ачык, фикерләрне тудырган образлар гади. «Күзләр» исемле шигырьдә шундый юллар бар:

Чалкан яткан
күзләреңне үптем.
Иреннәрем белән гүя
орынып,
болытларны,
тургайларны үптем...

Бик матур, образлы әйтелгән, барысы да аңлашыла. Ләкин шагыйрь моның белән генә чикләнми, ул тагын да гадирәк итеп аңлатып үтү кирәк дип саный:

Алар барысы
күзләреңә сыйган иде...

Бәлки, «Аҗаган» шигыре аңлашылмыйдыр? Аҗаганга карт та, үбешүче яшьләр дә, музыка тыңлап ятучы кеше дә, оядагы кош та игътибар итмәгәнне сурәтләгәч, автор кинәт кенә:

Булмады быел
алмалар —
агачлар кысыр калды.
Әйтте барсы: «Чәчәген
аҗаган гына алды...» —

ди. Ничектер бәйләнешсезрәк килеп чыга кебек. Ләкин татар халык легендаларын һәм сынамышларын яхшы белгән укучыга бу «бәйләнешсез» әйтү дә куркыныч түгел. Шигырь бит ул, теләсә кайсы сәнгать әсәре кебек үк, тормышның бер кисәге һәм тормышның калган өлешләре белән дә тыгыз бәйләнештә тора. Димәк, укучы тирән белемле, киң карашлы кеше булырга тиеш.

Бәлки, шигырьләрнең төгәл бер калыпта һәм рифмалы булмаулары укучыга комачаулыйдыр? Ләкин шигырьне шигырь иткән чаралар рифма һәм калып ясый торган ритм белән генә чикләнмиләр ич. Әгәр дә шигырьдә бары шушы ике генә «җитешсезлек» бар икән — куркыныч түгел. Чөнки образлар һәм алар тудырган фикерләр чын мәгънәсендә шигърриләр һәм тормышчаннар. Бу турыда озак сөйләшеп булыр иде. Күрәсең, әңгәмәдәшем була алдың, «Аҗаган». Шулай икән, нигә безгә мәхәббәт турында да сөйләшеп карамаска? Нигә үз итеп кенә сиңа бераз тәнкыйть сүзе әйтмәскә?

«Сина багышланган юллар». Кем һәм нинди икән син, бер үзеңә җиде шигырь багышлаткан кыз? Нинди икән шул шигырьләрне багышлаучы лирик егетең?

Калгандыр нәрсә дә
булса
күңелең юшкынында.
Ахыр чиктә
шатлыгыңнан
елаган кич турында
хәтерендәдер...

. . . . . . . . . . . .

Калгандыр нәрсә дә
булса,
шулаймы? Әйт, яшермә!
Юк булса,— горур
китәрмен,—
куралмассың яшем дә!

*(«Бераз үзгә, бераз бүтән...»)*

Бик горур икән синең лирик героең, «Аҗаган». Шул ук вакытта бик нечкә күңелле дә икән.

Котсыз суык көнне
шыксыз булмәмә син
яз китердең.
Әгәр һәр кергән
бүлмәгә яз ясасаң,
миңа күңелле бухмас...
Тик шулай да
бүлмәләргә,
кемнекенә генә
булса да,
күз китермә, яме!

*(«Иңемә кулларың орынгач»)*

Шуның өстәвенә, ул бик олы җанлы һәм киң күңелле дә икән. Кыскасы, менә дигән егет! Тик бераз гына шаянлык та булса!..

Ә кыз мәсьәләсен, кичер, аңламыйм — алар ничәү соң? Соравымны ахмаклык дип санама — циклның исеме аны чын мәгънәсендә җитди итә. Минемчә, җиде шигырь дүрт кызга багышланган. Дөрес, заманында алар синең лирик героең өчен «син» булганнар, ә хәзер, бергә җыелгач, аларга фәкать күплек санында гына дәшеп була. Ләкин андый принципиаль егеткә алай сибелеп-чәчелеп йөрү һич килешми. Бераз гына шаярткангa, «Аҗаган», гафу ит. Ләкин циклның исеме дөрес булмау һәм аны дөрес төземәү — факт.

Авыз иронияле итеп ачылган икән, шунысын да әйтергә кирәк: җыентыктагы «Минем әти», «Җилфердәүче керләр җыры», «Самолетта. Биеклек — 8000 м.» дигән шигырьләр белән сөйләшә алмадым, сөйләшеп булмады. Алар, ничектер, ясалмарак килеп чыкканнар. Бәлки, аларны җыентыкка гомумән кертмәскә кирәк булгандыр?..

«Аҗаган»ны укыганда мин шагыйрь очраттыммы, әллә философнымы, әллә университет тәмамлаган яшь белгечнеме, әллә чәчләре көмешләнгән карт солдатнымы, әллә тормышның ачысын, баллысын татып өлгергән яшьтәшемнеме — белмим. Тик шунысы ачык — акыллы да, шул ук вакытта бәхәсле дә, күңелсез дә, шул ук вакытта кызык та фикерләр һәм образлар иясен очраттым, ә «Аҗаган» минем дустыма әверелде.

Ренат ХАРИСОВ.

———□———

# Габдулла Тукай альбомы

Сәгыйт иптәш Исәнбаевның күпьеллык тырышлыгы, Г. Халит, Р. Башкуров һәм башка иптәшләрнең ярдәме белән төзелеп, Татарстан китап нәшрияты тарафыннан дөньяга чыгарылган бу альбом[1] культурабыз үсешенә зур өлеш кертә. Г. Тукай үз эченә генә бикләнеп яшәгән шагыйрь булмаган кебек, аңа багышланган альбомда да Тукайга чаклы иҗат иткән, ул яшәгән чорда һәм аннан соңгы елларда культура тарихыбызда билгеле роль уйнаган күп кешеләрнең рәсемнәре, аларның халык шагыйре турында әйткән сүзләре, аның әсәрләренә багышланган сәнгать үрнәкләре, фотолар кертелү бик табигый чыккан һәм бөек шагыйрьнең тарихи ролен дөрес билгеләргә ярдәм иткән.

Яшь галимнәребездән Рөстәм Башкуровның матур һәм җыйнак язылган кереш сүзе, «Кушымта» рәвешендә рус телендә бирелгән аңлатма һәм искәрмәләр аны тагын да тулыландырганнар.

Һәрбер зур эштә булуы мөмкин кайбер кимчелекләр бу альбомда да юк түгел. Аларны берничә төркемгә бүлеп күрсәтергә мөмкин. Башта рәсем һәм иллюстрацияләр хакында.

XIX йөзнең күренекле галим һәм мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның рәсеме, аның мәхәббәт тудырырлык рәсеме, әле һаман да үзенең иҗатчысын тапмаган икән. Аның бу альбомдагы рәсеме дә, безнеңчә, шактый шыксыз чыккан.

Мәрҗани һәм Насыйрилар белән беррәткә тезелергә тиеш булган һәм Тукайның зур ихтирамын казанган Заһир Бигиевнең рәсеме, ни өчендер, төшеп калган. Шулай ук үз чорында Тукайга һәм аның фикердәшләренә зур бәя биреп, аларның рухларын күтәреп килгән зур галим Риза Фәхретдинов, соңгы сулышларына кадәр Тукай янында булган профессор Клячкин рәсемнәре дә альбомда күренми.

Художник Б. Альмеңов иптәшнең «Нәни Габдулла Кырлай авылына, Сәгъди абзый йортына килгәч» дигән рәсеме уңышлы түгел. Бу рәсемдә Тукай чатан картны күз алдына китерә, балалар да ул заманныкы түгел.

«Авыл мәдрәсәсе» исемле иллюстрацияне дә күптән басылып килүенә карамастан, уңышлы дип булмый. Тукай шигырьләрендә тасвирланган авыл мәдрәсәсе, хәзерге тел белән әйткәндә, 9—15 яшьлек балалар укый торган башлангыч мәктәп ул. Тукай «Мәҗнүн мөритләр хилкасе» дип әйткән икән, бу авыл мәктәпләрендәге укыту тәртипләренә карый. Ә рәсемдә исә 50—60 яшьлек картлар җыелып утырган. Әйтерсең, 1919 еллардагы ликбез мәктәбе укучылары!

Художник Якуповның «Габдулла Тукай крестьяннар арасында» картинасында да татар крестьяны юк. Тик бер «мәчет карты» гына бар. Калганнарын ул замандагы татар крестьянын белмәгән кеше ясаган.

Гомумән, мин художникларга элекке заманның типларын өйрәнеп, аларның үз кыяфәтләрен, кием-салымнарын художество картиналарында алып калырга киңәш бирер идем. Тарих югалмасын иде.

Рөстәм Башкуровның матур язылган сүз башын ямьсезләүче стилистик уңышсыз җөмләләрен, тарихи дөреслеккә туры килеп бетми торган фактларны күрергә теләмәгән идем. Ләкин кайберләрен әйтми үтеп булмый.

Өчиле һәм Кырлай тирәләрендә «асрарга» дип түгел, «асрамага» дип сөйлиләр иде.

Тукай үзе дә аны «асрамага» дип яза. Р. Башкуров исә, куш җәяләр эченә алып, димәк, Тукай сүзләре итеп, «асрарга» рәвешендә язган.

Тукайның иҗат эшчәнлеге 1902 елдан башлана дип күрсәтү дә дөрес үк түгел. Р. И. Нафиговның «Казан утлары» (1966 ел, 8 сан) журналындагы мәкаләсеннән күренүенчә, Тукай һәм иптәшләре 1903 елда Уральскида «Әл-мәгариф» исемле кулъязма газета чыгаралар. Аның Крыловтан һәм «Кәлилә вә Димнә»дән алып, «Мәҗмугаи мөфидә»не язуы да 1903 елга туры килә. Ә 1902 елда нинди әсәрләр язуы хәзергә билгесез.

Тукай турында сүз башлагач, тагын бер фикер әйтәсе килә. Безнең тәнкыйть әдәбиятында, Тукайны зурлау өченме, Мәҗит Гафурины гүя Тукайның шәкерте, Тукай мәктәбе кешесе итеп күрсәтү киң таралган. Р. Башкуров мәкаләсендә дә шул тенденция сизелә. Дөреслектә, М. Гафури Тукайдан элек матбугатка чыккан, аннан соң да 18 ел язу эшен дәвам иттергән, үзенә хас почерклы әдип. Моны үз заманында Р. Фәхретдинов билгеләп, бу ике шагыйрьне гарәбнең ике классигы белән тиңләштереп үткән иде. Ф. Әмирхан да Гафури стиле белән Тукай стиле арасында зур аерма булганын күрсәтеп үтте.

Идея-политик тенденцияләре берлегенә карап кына шагыйрь һәм гомумән әдипләрне бер-берсенә ярыту дөрес түгел, дип уйлыйм.

**Х. ХИСМӘТУЛЛИН.**

[1] Габдулла Тукай. Фотоальбом. Төзүчесе С. Исәнбаев. Татарстан китап нәшрияты. 1966 ел.

# УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

## ЖУРНАЛГА ТАГЫН ЯЗЫЛДЫМ

«Казан утлары» журналына мин беренче тапкыр үткән ел язылган идем. Журнал миңа бик ошады. Шуның өчен аңа быел да язылдым. 1966 елда журналда басылган зур күләмле әсәрләрдән Хәсән Сарьянның «Әткәм һөнәре» повестен яратып укыдым. Бер уйлаганда, анда әллә ни искитмәле вакыйгалар да юк, әсәрнең төп герое Гаяз да зур-зур эшләр куптарып йөрми. Ләкин шулай да повесть беренче юлларыннан ук үзенә тарта, укучыларда төрле уйлар уята. Чөнки аның нигезендә чын тормыш картиналары, сиңа да, миңа да очрый торган тормыш геройлары бирелгән. Хезмәтең, һөнәрең кешеләр өчен түгел икән, ул үзеңә дә шатлык, бәхет китерми, ди язучы. Һәм шул фикерен ул әсәрендә гади һәм ышандырырлык итеп үткәрә.

Хикәяләрдән Ә. Еникинең бераз моңсу, ләкин гаҗәп җылы итеп язылган «Әйтелмәгән васыять»ен аерып күрсәтәсем килә. Мин аны алтмыштан узган әниемә дә укып чыктым. Хикәя аңа да ошады. Минем белән бергә ул да язучыга чын күңелдән рәхмәт әйтә. Әйе, бар нәрсәдән кадерле әниләребезне, туган җиребезне, туган телебезне онытырга беребезнең дә хакы юк!

Шагыйрьләрдән Саҗидә Сөләймпнованың «Язылмаган җырлар» поэмасы күңелдә якты уйлар калдырды.

Журналда матур әдәбият әсәрләрен генә түгел, тәнкыйть мәкаләләрен дә мин кызыксынып укыйм. Бигрәк тә Фәрит Хатиповның 9 нчы санда «Ихтыярсыз геройлар һәм кырыс дөреслек» исемле мәкаләсен матур, әйбәт язылган поэма укыгандай укыдым. Анда тәнкыйтьченең һәр фикере тимердәй логика белән, аргументлы итеп бирелгән һәм, иң әһәмиятлесе, А. Гыйләҗевның «Өч аршын җир»е безнең заман күзлегеннән чыгып бәяләнгән. Иптәш Хатипов кайбер тәнкыйтьче иптәшләрчә «әсәрдә шундый-шундый яхшы яклар, фәлән-фәлән начар яклар бар» дип күрсәтеп, санап кына чыкмый, ә әсәрдәге проблемаларның ни өчен шулай, ә бүтәнчә чишелергә тиеш түгеллеген, теге яки бу хәлнең, хәрәкәтнең образга хас булуын, туры килүен дә аңлата. Тәнкыйтьче моның белән үзенең иң мөһим бурычларының берсен — язучыны, әсәрне укучыга җиткерү, аңлату бурычын үти.

И. Нуруллинның «Шагыйрьне өйрәнү юлында» исемле мәкаләсен журналда тәкъдим итү белән редакция бик үк зур ялгыш ясамаган, безнеңчә. Ни өчен! Беренчедән, Нуруллин бәхәс, уй тудыра торган мәсьәләләр күтәреп чыккан. Ә бит кайда бәхәс — шунда дөреслек табыла. Нуруллин мәкаләсе уңае белән журналда һәм «Социалистик Татарстан» газетасында Тукайның иҗатын, шәхесен өйрәнү буенча кыйммәтле фикерләр әйтелгән мәкаләләрнең чыгуы шуны раслый түгелме! Икенчедән, И. Нуруллинның мәкаләсендә, гәрчә анда дөрес булмаган кайбер положениеләр һәм нәтиҗәләр булса да, язучының шәхесен, иҗатын өйрәнүгә карата файдалы гына фикерләр дә бар һәм, монысын да онытмаска кирәк.

Г. Гобәйнең «Коръән серләре» бик кирәкле, бик күп көч куеп язылган әсәр. Тик аны аерым китап итеп бастырганда, пәйгамбәрләрнең җенси азгынлыклары турындагы сүзләрне күңелгә ятышлырак, бүтән мәгънәдәш сүзләр белән алыштырырга кирәк. Чөнки аны олылар белән беррәттән өлкән яшьтәге мәктәп балалары да укыячак бит.

Кыскасы, журналның һәр номерын көтеп алам, аны башыннан алып ахырынача, «валчыгына кадәр» зур кызыксыну белән укып барам.

САЛИХ ЗАҺРЕТДИНОВ,
укытучы. Аксубай районы.

Мин «Экранда күрсәк икән» дигән публицистик мәкаләне зур игътибар һәм кызыксыну белән укып чыктым. Аны язган Фаяз Дунай иптәшкә зур рәхмәтемне белдерәм.

Уйлап карасаң, чынлап та, бу өлкәдә артта калынган. Безнең бабаларыбыз һәм замандаш язучыларыбыз биргән әдәби байлыгыбыз бик зур. Тирән эчтәлекле, матур телле, татар халкы арасыннан чыккан легендар батырларны оста тасвирлап язылган матур әдәбиятыбыз башка милләт халкы әдәбиятыннан һич ким түгел.

Сәхнә осталарыбыз бар, композиторларыбыз бар, операторлар, сценаристлар, режиссерлар бар. Хәтта кинолента фабрикасы да Казанның үзендә. Бөтен шартлар булуына карамастан, шул байлыктан файдаланмыйча ничек түзәләр соң әдипләребез!

Язылган китаплар һәр кешегә барып җитә алмаска да мөмкин. Бигрәк тә Себер ягында. Ә менә татар халкы тормышыннан иҗат ителгән кино булса, мондагы халыклар ничек рәхәтләнеп карарлар иде!

Күңел кылларын калтыраткан «Кара йөзләр»не, «Мәңгелек кеше»не, җаннарны җилкетә торган «Башмагым»ны, «Галиябану»ны экранлаштырып Бөтенсоюз күләменә җибәрсәң иде! Түбәбез күккә тияр иде!

РАФАИЛ ЗАҺИДУЛЛИН,
Новосибирск шәһәре.

Язучы А. Гыйләҗевның «Берәү» повесте «Казан утлары» журналында 1966 елда басылып килгән әсәрләр арасында иң яхшы әсәр дип әйтергә тулы нигез бар. Чөнки автор тормыштагы барлык якларны да чын хакыйкатькә күз йоммыйча, кыю рәвештә, үз йөрәгә кушканча, иркен тон белән, дөрес фактларга таянып шома тел белән язган. Әлбәттә, бу повестьны татар әдәбиятының шедевры һәм уникаль әсәре дип әйтү иртә, әмма аның тантана итүе хәзерге көннән башлана. Озак көттеләр укучылар мондый әсәрләрне!

Мин бу сүзләрне журналда басылган Н. Фәттахның «Артта калган юллар» повестена карата да әйтер идем. Объектив закон буларак, тормышка һәм чорга, тарих юлларына буяу сөртеп калу мөмкин түгел; хәзерге көнебезнең ямен, тәмен татып яшәү өчен үткәнне белергә, сабак алырга кирәклекне искәртәләр алар.

Ф. ЗАҺИТОВ,
студент,
Чайковский шәһәре.

—◆—

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ



### М ҖӘЛИЛГӘ ҺӘЙКӘЛ

Узган елның өченче ноябрендә Казан Кремле каршындагы Беренче Май мәйданында Ленин премиясе лауреаты, Советлар Союзы Герое, атаклы шагыйребез Муса Җәлилгә һәйкәл ачылды. Һәйкәл ачу тантанасына багышланган митингта КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Ф. А. Табеев, шагыйрь З. Нури, Совет Армиясе капитаны В. Ищейков һәм Казан дәүләт университеты студенткасы Г. Новикова халкыбызның тиңдәшсез батыр улы Муса Җәлил турында дулкынландыргыч речьләр сөйләделәр. Аннары завод-фабрикалар, институтлар, җәмәгать һәм иҗат оешмалары исеменнән шагыйрь һәйкәле янына бик күп веноклар, чәчәкләр куелды. Шәһәребезгә ямь биреп торучы, җиде метр биеклегендәге бу һәйкәл, атаклы скульптор, СССР Художество Академиясенең член-корреспонденты, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Владимир Ефимович Цигаль проекты буенча, Мәскәүдәге СССР художество фондының производство комбинатында коелган.

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

Татарстан Язучылар союзы партоешмасының отчет-сайлау җыелышы булды. Отчет докладын партоешма секретаре язучы Г. Минский ясады.

Фикер алышуларда Г. Бакиров, М. Садри, С. Хәким, А. Булгаков, З. Нури, Ш. Маннур һәм М. Әмир катнашты.

КПСС өлкә комитеты секретаре иптәш М. Ф. Вәлиев Бөек Октябрьның 50 еллыгы, Татарстан АССРның төзелүенә 50 ел һәм В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән республикабыз язучылары алдында торган бурычлар турында сөйләде.

Татарстан Язучылар союзы партоешмасы секретаре итеп язучы Гариф Гобәй сайланды.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

### ХИКӘЯЛӘР ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Татарстан Язучылар союзы каршындагы проза секциясенең чираттагы утырышы хикәяләр турында сөйләшүгә багышланды. Утырышта күренекле өлкән буын язучылардан Ибраһим Гази, Әмирхан Еники һәм Гариф Галиев хикәя жанрына карата фикерләрен сөйләделәр, үзләренең хикәя язу тәҗрибәләре белән уртаклаштылар.

— Хикәянең түр башында, — диде И. Гази, — образ утырып тора. Димәк, хикәя үзәгендә психология, шәхес булырга тиеш. Хикәя сюжетлы да, сюжетсыз да була. Сюжетсыз хикәядә образ, психология төп рольне уйный. Сюжетлыларында вакыйга төп урынны тота. Хикәядә язучының дөньяга карашы сизелеп тора. Автор геройны үзенчә фикер йөртерә, үзе теләгән яктан күрсәтә. «Образ» дип укучы күңелен җәлеп итә алган, җанлы итеп сурәтләнгән кешеләрне генә әйтәм мин.

Бездә хикәяләргә образлылык җитми. Образ вакыйгаларны алып баручы булырга тиеш. Ә безнең язучыларның байтагы образны вакыйга сөйләү өчен генә хикәягә

кертәләр, шунлыктан образ шәхес буларак тулы ачылмый, эскизрак характерда була...

Без һәр вакыт образ җанлы булырга тиеш дибез. Ә җанлылык кайдан килә? Җанлылык образларның табигыйлегеннән килә, үзенчәлегеннән килә. Менә монда утырган кешеләр бер-беренә охшамаган кебек, образлар да бер-береннән аерылып торырга тиеш. Ягъни образның, Шолохов әйткәнчә, чудинкасы булырга тиеш. Чудинка образның тышкы кыяфәтендә дә, сөйләшендә дә чагылырга мөмкин. Әмма чудинка чудаклыкка әйләнергә тиеш түгел. Ул геройның характерыннан чыгарга тиеш.

Әгәр мин хикәя түрендә образ утырырга тиеш дип әйтәм икән, мин аны бары тик образлы хикәяләргә карата әйтәм. Хикәяләрнең образы эскиз белән генә бирелгәннәре дә булырга мөмкин.

Хикәяләрнең төре бик күп. Хәзер безнең әдәбиятта яңа төр хикәя туды. Һәм бу табигый да. Һәр язучы үзенчә яза, шулай булмаса, ул кызык та булмас иде. Менә А. Гыйләҗевнең «Берәү» повесте. Повесть түгел ул, хикәя. Мин аны нәфис-публицистик хикәя дип атар идем. Аяз монда образлар иҗат итми. Ул үз фикерләрен бирер өчен мәгълүм беркадәр эшләнгән образлардан гына файдаланган. Чын мәгънәсендә образлар иҗат итмәгән. Аязның бу хикәясендә матур-матур картиналар да күп, әмма сүзләр сайлауда очраклырак буяулар белән мавыгып киткән урыннары да бар...

— Мин,— диде Ә. Еники, — хикәя язуның берникди теориясен дә, кагыйдәсен дә белмим. Һәм аны эзләгәнем дә юк. Хикәяне теория өйрәнеп кенә язып булмыйдыр, минемчә. Язар өчен, табигать тарафыннан бирелгән талант, сәләт кирәктер инде, күрәсең. Әмма өйрәнер өчен материал бар. Ул — хикәяләр үзләре. Бер яхшы хикәя укысаң, аннан бик күп нәрсә өйрәнергә мөмкин. Мәсәлән, Чехов хикәяләреннән күп нәрсәгә өйрәнергә була. Үз әдәбиятыбызда да әйбәт хикәяләр бар. Әйтик, Ш. Камал, Г. Ибраһимов, К. Нәҗми хикәяләре. Хикәя жанры безнең әдәбиятта өлгергән, җитлеккән жанр... Мин үзем хикәя язарга хикәяләрнең үзләрен укып өйрәндем... Язучылар бер дә бер берсенә охшамыйлар. Һәр язучы үзенә бер дөнья, үзенә бер төрле кеше. Тагын шуны да әйтәсе килә: мал иясенә охшый дигәндәй, хикәя дә язучының табигатен, эчке кичерешләрен, дөньяга карашын чагылдыра...

Мин хикәяне уйлап чыгара алмыйм. Миңа хикәя язу өчен вакыйганы я ишетергә, я күрергә кирәк. Шул чакта гына күңелгә хикәянең орлыгы төшә. Минем күп кенә хикәяләр шулай язылды...

Инде хикәяне язуга килгәндә мин үз алдыма бик гади генә өч бурыч куям: 1) язган әсәремне кулына алгач, укучы аны ахырына тикле укып чыксын; 2) укып чыккач, аның хәтеренә сеңеп калсын; 3) хикәяләрдә сурәтләнгән вакыйгаларның дөреслегенә ышансын иде ул укучы, дим. Әмма шушы гади генә таләпләргә җавап бирерлек әйбер язу ифрат авыр. Моның өчен вакыйга гыйбрәтле яки кызыклы, образлар исә җанлы булырга тиеш. Ә моңа ирешер өчен бик һәйбәт тел кирәк. Менә шул тел кодрәте белән генә образларны җанлы, вакыйгаларны табигый итәргә мөмкин. Хикәянең ышандыру көче вакыйгаларның тормышчанлыгына бәйләнгән. Тормышчанлыкны атлаган саен очрый торган хәл дип аңламаска кирәк. Тормышчанлык вакыйгаларның табигый булуына кайтып кала. Образның бөтен эше, хәрәкәте табигый булырга тиеш, әсәрдә язучы үзе, аның ихтыяры сизелеп тормаска тиеш. Бу яктан мин Э. Хемингуэй әсәрләрен сокланып укыйм... Мин үзем язганда сүзнең кадерен белү, кирәген генә сайлау, аз сүз белән күп мәгънә бирү өчен тырышам...

Гариф Галиев тә үзенең чыгышында хикәяләрнең сюжетлы да, сюжетсыз да булырга мөмкинлеген, әмма аларның һәркайсы тел ягыннан да, әдәби эшләнеше ягыннан да югары художестволы булырга тиеш икәнлекләрен әйтте. Аннары ул, үз иҗат тәҗрибәсеннән чыгып, хикәяләрне һәрвакыт тормыш вакыйгаларына нигезләп язуын, берсен дә уйлап чыгармавын мисаллар өстендә сөйләде.

Секция утырышында катнашкан барлык иптәшләр дә хикәяләр турында бу сөйләшүнең бик файдалы булуын әйттеләр һәм киләчәктә дә мондый сөйләшүләрне оештыргалап торырга кирәк дигән теләк белдерделәр.

## ҖЫР ТЕКСТЛАРЫН ТИКШЕРҮ

Шагыйрьләр секциясенең Композиторлар союзы белән берлектә радиокомитетта үткәрелгән киңәйтелгән утырышы радио аша башкарыла торган татар җыр текстларын тикшерүгә багышланды. Бу мәсьәлә буенча чыгыш ясаган шагыйрьләр дә, композиторлар да соңгы елларда үз араларында иҗади дуслыкның тагын да ныгый төшүен һәм, әнә шул дуслыкның нәтиҗәсе буларак, яңа, әйбәт җырлар дөньяга килүен билгеләп үттеләр. Шул ук вакытта алар яңа җырларның шактый гына кимчелекләре булуын да искәрттеләр.

— Радио аша башкарыла торган җыр текстларының, — диде шагыйрь Сибгат Хәким, — күбесе безне канәгатьләндерми. Поэтик фикерләре ягыннан да, эшләнешләре ягыннан да бик йомшак алар. Ләкин, минемчә, гаеп ул йомшак текстларны язган авторларга гына түгел, билгеле бер дәрәҗәдә композиторларга да төшә. Алар таләпчәнрәк булса, дөньяга текстлары зәгыйфь җырлар тумас иде. Киләчәктә дә шул хәл кабатланмасын өчен, яңа җырларны тикшереп, аларга бәя биреп бара торган художество советы составына шагыйрьләрдән дә берничә иптәшне кертергә кирәк. Алар яңа җырларның текстларына объектив бәя бирүдә ярдәм итәрләр иде. Җыр өлкәсендәге теоретик һәм практик мәсьәләләрне ачыклау өчен, Композиторлар союзы белән Язучылар союзына бергәләп махсус пленум үткәрергә дә бик вакыт инде. Бу эшне гамәлгә ашыруда безгә Өлкә Комитеты да ярдәм итәр иде, минемчә.

— Җырларның сыйфатын яхшырту өчен, — диде композитор Җәүдәт Фәйзи,— иң яхшы җырларга һәм җыр текстларына конкурс оештырырга кирәк. Бу хәл музыкасы ягыннан да, тексты буенча да әйбәт, яңа җырлар туута этәргеч булыр иде. Җыр турында сүз чыккан икән, ул җырларны башкаручылар турында да берничә сүз әйтеп китәсе килә: күп очракта репертуарлары бик сай була аларның. Нигәдер, житдирәк җырларны читтә калдырып, җиңелрәк, бушракларын сайларга ярата төсле тоела ул иптәшләр... Безгә киң диапазонлы, интонацион яктан төрле җырлар кирәк. Моны шагыйрьләр дә искә алсын иде. Музыкада яңа ритмнарны чагылдырыр өчен яңа шигъри формаларның булуы шарт...

Җыр текстлары турында фикер алышуда шагыйрьләрдән Хәсән Туфан, Зәки Нури, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзиев, Мөхәммәт Садри, Гөлшат Зәйнәшева, Мөнир Мазунов; композиторлардан Заһид Хәбибуллин, Әхәт Хәйретдинов, музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗанов һ. б. катнашты.

Сүз алып сөйләгән иптәшләр радиокомитет адресына да байтак тәнкыйть сүзләре әйтеп, радио аша башкарыла торган җырларның еш кына бертөрле булуын, музыкаль монтажларның ярлылыгын һәм гомумән җырларга карата таләпчәнлек җитеп бетмәвен билгеләп үттеләр.

Радиокомитет адресына әйтелгән бу сүзләр дөрес һәм урынлы булуга карамастан, радиокомитет сотрудниклары Җамалетдинов һәм Әхмәтҗанова иптәшләрнең чыгышларында тәнкыйтькә җиңел караш сизелде. Алар үзләренең җитешсезлекләрен танырга теләмәгән сыманрак сөйләделәр.

Секция утырышында катнашкан иптәшләр җыр һәм җыр текстлары турында сөйләшүләрне киләчәктә тагын да киңрәк, житдирәк итеп дәвам итәргә дигән нәтиҗәгә килделәр.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Хәсән Туфан, Габдрахман Минский, Шәүкәт Галиев, Рәдиф Гатауллин һәм яшь язучы Нурмөхәммәт Хисамов Дербышка поселогы культура сараенда китап укучылар белән очраштылар һәм үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары турында сөйләделәр.

* * *

16 ноябрьда В. И. Ленин исемендәге республика китапханәсендә «Казан утлары» журналын укучылар белән очрашу булды. Очрашуда «Казан утлары» редакциясе работникларыннан Рафаэль Мостафин (җаваплы редактор), Нури Арсланов (поэзия бүлеге мөдире) һәм журналда үз әсәрләре белән актив катнашып килүче язучылардан Сибгат Хәким, Атилла Расих, Илдар Юзиев, Аяз Гыйләҗев, Рәдиф Гатауллин катнашты.

Китапханә библиографы Роза Ханнанованың 1966 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр турында кыскача информациясеннән соң, сүз журнал укучыларына бирелде. Чыгыш ясаучы укучылар журналның һәр санын көтеп алуларын, кызыксынып укуларын әйттеләр һәм шул вакытта редакциягә үзләренең теләкләрен дә белдерделәр. Укытучы Вәлиуллин, мәсәлән, журналда балалар өчен язылган әсәрләрнең сирәк басылуын әйтте, киләчәктә укытучылар тормышын сурәтләгән әсәрләрне дә укысак иде дигән теләк белдерде. Ә монтажчы Хәерова: «Мәктәптән производствога килгән яшь эшчеләр турында повестьлар, романнар укыйсы килә, әмма, кызганычка каршы, андый әсәрләрнең журналда басылганы юк әле. Безнең бу теләкне хөрмәтле язучыларыбыз искә алсыннар иде»,— диде.

Аннары Р. Мостафин укучыларны «Казан утлары» журналының 1967 елга перспектив планы белән таныштырды, сорауларга җаваплар бирде.

С. Хәким, И. Юзиев, А. Расих, А. Гыйләҗев, Н. Арсланов, Р. Гатауллин журнал укучыларына үз иҗат планнарын сөйләделәр, яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетында татар студентлары «Габдулла Тукай» исемле клуб оештырдылар. Студент Нәриман Фәтхуллин җитәкчелек иткән ул клуб әледән әле әдәби кичәләр, язучылар, артистлар һәм композиторлар белән очрашулар оештырып торачак.

Клуб тарафыннан әле күптән түгел генә үткәрелгән әдәби җыелышларның берсе «Казан утлары» журналы турында сөйләшүгә багышланган иде. Җыелышта «Казан утлары»ның җаваплы секретаре язучы Әхсән Баянов та катнашып, студентларның журнал турындагы фикерләрен тыңлады. Аннары ул клуб членнарын «Казан утлары» журналының 1967 елга планнары белән таныштырды, хәзерге татар әдәбиятына һәм язучыларына кагылышлы күп кенә сорауларга җаваплар бирде. Соңыннан Ә. Баянов студентларга үзенең яңа әсәрләрен укыды.

Клуб җыелышында язучы Шамил Бикчурин һәм яшь язучы Вахит Монасыйпов та катнаштылар.

* * *

Апас районы радиосы үзенең чираттагы тапшыруын «Казан утлары» журналына багышлады. Район культура йорты каршындагы үзешчән сәнгать түгәрәге членнары журналда басылачак әсәрләрдән өзекләр укыдылар һәм татар композиторларының журналда басылып килгән җырларын башкардылар. «Казан утлары» редакциясе сотруднигы, язучы М. Хәмитов журналның тарихы, 1967 елга планы, анда басылып килгән һәм басылачак әсәрләр турында сөйләде.

Шул ук районның Мулланур Вахитов исемендәге колхозы клубында «Казан утлары» журналы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Редакция сотруднигы М. Хәмитов конференциягә катнашучыларны журналның эше белән таныштырды. Колхозчы И. Камалиев, урта мәктәп уку-

чысы Н. Касыймова, укытучы Г. Гафиятова, китапханә хезмәткәре Р. Зиятдинова h. б. лар журналда басылган әсәрләргә карата үзләренең фикерләре белән уртаклаштылар, авыллардагы үзешчән түгәрәкләргә журнал аша ярдәмне көчәйтү буенча үзләренең тәкъдимнәрен әйттеләр.

* * *

Алабугада яшәүче язучы Эдуард Касыймов Актаныш районының Пучы культура йортында һәм урта мәктәбендә, Киров исемендәге совхозда китап укучылар белән очрашып, үзенең яңа әсәрләрен укыды, иҗаты турында сөйләде. Үз чыгышларында, укучылар да Э. Касыймов әсәрләре турында фикерләрен әйттеләр.

Э. Касыймов Сәфәр авылы клубында үткәрелгән культура работниклары семинарында катнашкан кешеләргә «Дин һәм халык» дигән темага лекция дә укыды.

* * *

Атилла Расих, Илдар Юзиев, Абдулла Сәләхетдинов һәм Касыйм Фәсәхов Ижевск шәһәрендә булып кайттылар. Алар анда татар урта мәктәбендә, машина төзү заводында һәм культура сарайларында китап яратучы татар укучылары белән очраштылар, бүгенге татар әдәбияты турында сөйләделәр, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Әлмәт районының Абдрахман авылында «Казан утлары» журналына багышланган зур әдәби-музыкаль кичә үткәрелде.

Авыл үзешчәннәре журналда басылган әсәрләрдән аерым өзекләрне сәхнәләштереп уйнап күрсәттеләр, анда урнаштырылган җырларны, шигырьләрне, көлке-мәзәкләрне башкардылар.

Кичәдә катнашкан язучылардан Гариф Ахунов, Әдип Маликов, Рафаил Төхфәтуллин, Гамил Афзал, Энҗе Мөэминова үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

Кичә ахырында «Казан утлары» журналына подписка үткәрелде, аңа багышланган лотерея уеннары оештырылды. Болардан тыш, колхоз идарәсе алдынгы 17 колхозчыны «Казан утлары»на берәр һәм яртышар еллык подпискалар белән бүләкләде.

## С. ГАБӘШИНЕҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

«Эшче», «Сания» опералары һәм күп кенә җырлар авторы, татар совет музыка сәнгатен нигезләүгә һәм үстерүгә зур өлеш керткән композитор Солтан Габәшинең туына үткән елның ноябрь аенда 75 ел тулды. Шул уңай белән язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубында композитор иҗатына багышланган кичә үткәрелде.

Композиторның тормыш һәм иҗат юлы турында З. Хәйруллина һәм М. Нигъмәтҗанов сөйләде. Солтан Габәшине күреп белгән кешеләрдән язучы Н. Исәнбәт, скульптор Б. Урманче, композитор З. Хәбибуллин, артист К. Шамил, артистка С. Садыйкова, музыкант И. Билялов истәлекләр белән чыгыш ясадылар. Соңыннан артистлар һәм композиторлар көче белән Солтан Габәши әсәрләреннән төзелгән концерт булды.

## Х. ӘБҖӘЛИЛОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Татар совет театрының нигезен салуда актив катнашкан, онытылмас образлар иҗат итеп, СССРның халык артисты дигән мактаулы исемне бик хаклы рәвештә яулап алган Хәлил ага Әбҗәлиловның туына 70 ел тулды. Шул уңай белән Татар дәүләт



академия театрында артистның юбилеена багышланган кичә үткәрелде. Кичәдә атаклы артистның тормышы һәм иҗаты турында сәнгать фәннәре кандидаты Х. Кумысников доклад ясады. Х. Әбҗәлиловны якыннан белгән кешеләрдән язучы Н. Исәнбәт, ТАССРның халык артисты Х. Сәлимҗанов, РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты А. Шамуков, СССРның халык артисты Н. Якушенко истәлекләр сөйләделәр. Соңыннан опера һәм балет театры артистлары көче белән зур концерт бирелде.

## ЯҢА ЧЛЕННАР

Әдипләребез сафына ике яңа исем өстәлде. Татарстан Язучылар союзының 1966 елның беренче декабрендә үткәрелгән правление утырышында яшь шагыйрьләрдән Равил Фәйзуллин һәм Радиф Гатауллин СССР Язучылар союзына член итеп алындылар.

## ТӨЗӘТҮ

Журналыбызның 1966 елгы 11 санындагы (132 бит. өстән 30 нчы юл) «Гогольнең» дигән сүзне «Гюгоның» дип укырга кирәк.

*Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый.*


Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*


□ □ □



Җаваплы редактор **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**



Производствога бирелде 15/XI-1966 ел. Басарга кул куелды 9/I-1967 ел. ПФ 05006. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 57 300 экз. Заказ Н-1641. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1967 ел.




# КИЕК КАЗЛАР

*МАРС МАКАРОВ*
музыкасы

*ХӘСӘН ТУФАН*
сүзләре

Яңгырларда-явымнарда,
Давылларда-җилләрдә
Киек казлар кыйгылдаша
Мин белмәгән телләрдә.

Киек казлар кыйгылдаша,
Моңаялар, күрәсең, {2 кат
Янгырларга-явымнарга
Чыланалар, күрәсең!



Киек казлар кыйгылдаша,
Җырлашалар микәнни?
Туган илләр кала бит дип,
Елашалар микәнни?

Киек казлар кыйгылдаша,
Сау бул, якташ, диләрдер; {2 кат
Әллә кайтыр, әллә кайтмас
Безнең башлар, диләрдер.

Безнең дә бит шулар сыман
Киткән еллар бар иде.
Кыйгак-кыйгак, илем ерак,
Дигән чорлар бар иде.

Кыйгылдашып болытларда
Мин белмәгән телләрдә. {2 кат
Киек казлар китеп бара
Мин күрмәгән илләргә.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

*Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал*

# КАЗАН УТЛАРЫ

*(Огни Казани)*

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

Индекс 73210